ЕЛЛАР... САТЫЛА?

Лаеклы ялга чыкканда җитеп бетмәгән стажны сатып алырга мөмкин

> 6

КИЛӘЧӘК МӘЧЕТЕ

Булачак җәмигъ мәчет корылмасына нинди мәгънә салыначак?

> 7

СӘНИФӘ РАНГУЛОВА:

«Бер үкенечем калды»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 100 (28873) | Җомга | 15 июль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

kazansummit.ru

ХӘЛӘЛ КИЛЕШҮ

РОССИЯДӘ ИСЛАМ БАНКИНГЫН ЗАКОНЛАШТЫРЫРГА ҖЫЕНАЛАР

Россиядә шәригать кануннарына нигезләнеп эшли торган банкингны закон нигезендә кабул итәргә җыеналар. Бу хакта тиешле закон проектына сылтама белән «Коммерсантъ» газетасы хәбәр итә. Әлегә яңалыкны Чечня, Дагыстан, Башкортстан һәм Татарстанда сынап карарга ниятлиләр. Татарстанда ислам финанслары юнәлешендә инде берничә ел эшли торган оешмалар бар. «ВТ» аларның тәҗрибәсен өйрәнеп, әлеге юнәлешнең нечкәлекләрен, бүген һәм киләчәктә ни дәрәҗәдә актуаль булуын ачыкларга тырышты.

> 16

Ишетми калмагыз

Россиянең барлык хакимият органнары социаль челтәрләрдә рәсми сәхифәләрен алып барырга тиеш. Президент Владимир Путин бу җәһәттән тиешле законны имзалаган. Документ хокукый мәгълүматлар рәсми порталында басылып чыкты.
Сәхифәләрдә хакимият органнарының конкрет эше яктыртып барылачак. Шул ук вакытта дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалар да үзләренең битләрен булдырачак. Законга аңлатмада билгеләп үтелгәнчә, сайтлар булдыру таләбе искергән. Алар халык белән онлайн аралашу өчен кулай түгел.

Владимир Путин Пенсия фондын һәм Социаль иминиятләштерү фондын бердәм Социаль фондка берләштерү турында законга кул куйган. Шулай итеп, яңа фонд берьюлы ике оешма эшен алып барачак. Аның киләсе елның 1 гыйнварыннан эшли башлаячагы көздә тотыла. Күчеш чоры 2 ел тәшкил итәргә мөмкин. Берләштерү халыкка социаль хезмәтләр алуны җиңеләйтәчәк һәм өстәмә уңайлыклар тудырачак. Әйтик, клиентларга хезмәт күрсәтүнең бердәм офислары булдырылачак. Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгыннан белдерелгәнчә, фондларны берләштерү нәтиҗәсендә экономияләнгән акча пенсияләрне арттыруга тотылачак.

Татарстан Министрлар Кабинеты урманнарга керү чикләнгән районнар исемлеген киңәйтте. Премьер-министр Алексей Песошин бу җәһәттән тиешле карарга кул куйган. Шулай итеп, хәзер исемлеккә Аксубай, Әлки, Апас, Югары Ослан, Биектау, Кайбыч, Питрәч районнарыннан һәм Казаннан тыш, Лаеш, Арча, Әтнә, Балтач, Саба, Теләче, Нурлат, Алабуга, Мамадыш, Тукай, Менделеевск, Минзәлә, Актаныш, Яшел Үзән, Чүпрәле, Әгерже, Чистай, Алексеевск, Яңа Чишмә, Түбән Кама, Зәй, Сарман, Мөслим, Әлмәт, Азнакай, Лениногорск, Бөгелмә, Ютазы һәм Баулы районнары да кертелгән.
Чикләү 8 июльдән башланып, 21 көн дәвам итәчәк. Аны кертүнең сәбәбе – урманнарда янгын куркынычы зур булу.

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы (ВОЗ) барлык илләрне битлек режимына кире кайтырга өнди. Коронавирусның яңа дулкыны башлануга бәйле бу. ВОЗ директоры Тедрос Аданом Гебреисус әйтүенчә, «омикрон»ның яңа штаммы бөтен дөнья буйлап тарала һәм чирләүчеләр саны көннән-көн арта. Инфекциянең көчәеп китүе сәламәтлек саклау системасына һәм табибларга зур йөк булып төшә. Ковидтан үлем-китем очраклары үсү дә күзәтелә икән.
Сүз уңаеннан, кичә Россиядә 4 июньнән соң беренче тапкыр чирләүчеләр саны күбәеп, тәүлегенә 4 меңнән узган. Мәскәүнең ковидка каршы оператив штабы белдергәнчә, инфекция йоктыру очраклары алдагы атнадагыга караганда 57 процентка арткан.

Районнарда ни хәлләр?

Саба

Саба районы ЗАГС бүлеге мәгълүматларына караганда, 2022 елның беренче яртыеллыгында районда барлыгы 36 пар никахларын теркәгән. Бу узган ел күрсәткече белән чагыштырганда 56 процентка кимрәк. Язылышучыларның 86 проценты никахларын беренче тапкыр теркәгән. Дүрт ир-егет һәм 7 хатын-кыз кабаттан язылышкан. Иң яшь кияүгә 18 булса, иң яшь кәләшкә – 19 яшь. Ә иң өлкән кияүгә исә (беренче тапкыр өйләнгән) – 62, иң өлкән кәләшкә – 47 яшь.
(«Саба таңнары»)

Әтнә

«Туган ягым» паркында «Babi Boom» дип аталган бәйрәм узды. Килгән кунаклар бала арбалары парадын да карап хозурланды, 8–10 айлык сабыйларның мүкәләп ярышуын да күзәтте. Беренче генә мәртәбә уздырыылганга, оештыручылар, катнашучы булырмы икән, дип шикләнгән иде. Юкка булган икән. Берсеннән-берсе үзенчәлекле итеп бизәлгән арбалар белән килде катнашучылар. Тик Бәрәзә авылында яшәүче Галләмовлар гаиләсенә парадта тиңнәр булмады. Сабыйларның мүкәләп ярышуы да үзе бер шоуга тиң иде. Ярышта, әнисенең кулында телефон күргәч, мүкәләп барган җиреннән тәпиләп үк киткән Аишә исемле сабый җиңде.
(«Әтнә таңы»)

Яшел Үзән

Калуга шәһәрендәге «Үзәк» спорт сараенда спорт гимнастикасы буенча Россия Кубогы узды. Ярышларда берьюлы биш олимпия чемпионы, шулай ук Әрмәнстан һәм Белоруссия спортчылары катнашты. Шәһәрнең 1 нче олимпия резервы спорт мәктәбе укучысы Мария Минаева иң дәрәҗәле саналган – күп төрле ярышларны берләштергән дисциплинада бронза медаль яулады. Шулай ук Мария ирекле күнегүләрдә һәм төрле биеклектәге борысларда да ике бронза медальгә ия булды. Яшь спортчы Татарстанның атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәрләре Гөлнара Әхмәтҗанова һәм Александр Артамоновта шөгыльләнә.
(«Яшел Үзән»)

Чистай

Чистайда гомер кичерүче Евдокия Карповага 100 яшь тулды. Бу көнне ул якыннары, танышларыннан гына түгел, җирле хакимият вәкилләре, җәмәгать оешмалары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм милләтара мөнәсәбәтләр бүлеге җитәкчесеннән дә котлаулар кабул итте. Йөзьяшәр әби Балык Бистәсе районының Осиновка авылында туа. Бөек Ватан сугышы башланганда аңа нибары 19 яшь була. Башка кызлар белән бергәләп Евдокия да Казан артына эшкә китә. «Нарат урманы кистек, судан бүрәнәләр чыгардык. Бик авыр булды: ашарга юк, коры идәндә йокладык», – дип искә ала ул сугыш елларын.
Сугыштан соң Евдокия әби авылларына бәрәңге алырга дип килгән Григорий белән танышып, гаилә кора. Биш бала тәрбияләп үстерәләр. Бүген аның ун оныгы, унтугыз оныкчыгы бар.
(«Чистай-информ»)

ЯШЬЛӘР ҖЫЕЛГАН ҖИРДӘ

tatarstan.ru

Ел азагына таба Казаныбыз кайнап торган яшьләр башкаласына әвереләчәк. Ник дигәндә, Ислам хезмәттәшлеге оешмасының (алга таба – ИХО) яшьләр башкаласы статусында Казанда күпсанлы халыкара чаралар узачак. Алар октябрь, декабрь айларына планлаштырылган. Атна уртасында Рөстәм Миңнеханов бу уңайдан планлаштырылган чараларны әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты утырышын уздырды.

Исегезгә төшереп үтәбез: узган ел Ислам хезмәттәшлеге оешмасының яшьләр форумы Идарәсе утырышында Казанга «ИХОның Яшьләр башкаласы – 2022» статусын бирү турында карар кабул ителде. Төрле илләрдә әлеге статуска Истанбул (Төркия), Шираз (Иран), Путраҗая (Малайзия), Фес (Марокко), Доха (Катар) лаек булган иде.

Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, «Казан – ИХОның Яшьләр башкаласы» программасы кысасында быел башкалада халыкара чаралар планлаштырылган. Аларның кайберләре уңышлы гына үткәрелде дә инде. Хәтерләсәгез, март аенда Мәскәүдә ИХОның яшьләр башкаласы буларак, Казанны инаугурацияләү тантанасы узды, башкалада Коръән уку бәйгесе үтте.

Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, ИХО илләренең яшьләр эшләре һәм спорт министрлары катнашында узачак Глобаль яшьләр саммиты да мөһим вакыйга булырга тиеш. «Бу – Ислам хезмәттәшлеге оешмасының яшьләр башкаласы программасы кысасында иң мөһим халыкара чара. Шуңа күрә безгә аны тиешле дәрәҗәдә уздыру мөһим. Әлеге саммитны зур әһәмиятле федераль проект буларак кабул итәргә кирәк», – диде Татарстан Президенты.

Татарстан яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов сүзләренә караганда, глобаль яшьләр саммиты 27–30 август көннәрендә Казанда узачак. Анда, ИХО илләренең яшьләр эшләре һәм спорт министрлары, ИХО илләренең Илчеләре, халыкара оешмалар җитәкчеләре, шулай ук Глобаль яшь дипломатлар форумында катнашучыларны да исәпкә алып, барлыгы 50 илдән 200 делегат катнашыр дип көтелә. Саммит кысасында яшьләр миграциясе, мәдәни хезмәттәшлек, социаль лифтлар, яшьләр эшкуарлыгы кебек актуаль мәсьәләләр буенча фикер алышулар да планлаштырыла.

Гомумән алганда, быел Казанда Яшьләр башкаласы статусында барлыгы 10 халыкара чара планлаштырылган. Инаугурация тантанасыннан һәм Коръән уку бәйгесеннән тыш, ИХО илләренең Киберспорт буенча халыкара яшьләр чемпионаты (8–10 октябрь), Заманча мөселман сәнгате халыкара яшьләр фестивале (10–15 октябрь), Халыкара яшьләр фәнни конгрессы (1–5 ноябрь), Россия – Балкан яшьләр форумы (11–16 декабрь), «Россия – Ислам хезмәттәшлеге оешмасы» халыкара яшьләр форумы (11–16 декабрь), шулай ук «Казан – ИХО илләренең яшьләр башкаласы» программасын ябу тантанасы һәм «ИХО илләренең лидерлары» халыкара премиясен тапшыру тантанасы (15–16 декабрь) узачак.

Моннан тыш, Татарстанда хәзерге заман мөселман яшьләре тормышы турында документаль фильм концепциясе дә эшләнгән. Август – ноябрь айларына билгеләнгән белем бирү стажировкалары исә Россия һәм ИХО илләре арасында халыкара хезмәттәшлекне ныгытырга ярдәм итәр дип көтелә. «Барлык чаралар буенча да актив әзерлек эше алып барыла», – диде Тимур Сөләйманов.

Иң яхшылар ачыкланды

Татарстанның иң яхшы хезмәт һәм товарлары билгеле. Аларны ачыклауны максат иткән бәйгедә быел 157 товар җитештерүче катнашкан. Алар 333 төрле товар һәм хезмәт тәкъдим иткән.

Билгеле булганча, «Татарстанның иң яхшы товар һәм хезмәтләре» – республика җитештерүчеләре арасында уздырыла торган иң дәрәҗәле бәйгеләрнең берсе. «Россиянең иң яхшы 100 товары» бәйгесенең төбәк этабы булып тора. Татарстанда узган бәйге быел да «Азык-төлек товарлары», «Халык өчен сәнәгать товарлары», «Җитештерү-техник билгеләнештәге продукция», «Хезмәтләр», «Халык һәм сәнгать һөнәрләре эшләнмәләре» дигән биш төрле номинациядә үтте.

«Бәйгедә катнашучыларның биштән берен кече һәм урта эшмәкәрлек тармагы оешмалары тәшкил итә. Аларның саны елдан-ел арта. Шунысы куандыра. Чикләүләр аркасында илдә катлаулы икътисади вазгыять урнашуга карамастан, Татарстан оешмалары бәйгедә актив рәвештә катнашты һәм үзләрен югары сыйфатлы товар һәм хезмәтләр тәкъдим итүче, көндәшлеккә сәләтле җитештерүче буларак күрсәтте», – ди Татарстанның стандартлаштыру үзәге җитәкчесе, «Россиянең иң яхшы 100 товары» программасының сыйфат буенча төбәк комиссиясе рәисе Фәрит Туктаров.

Бәйгегә килгән эшләрне бәяләгән белгечләрнең сүзләренә караганда, оешмалар бүгенге катлаулы шартларга да яраклаша алган. Биредә катнашкан оешмаларның 70 процентының сыйфат менеджменты турында сертификаты бар, алар җитештергән продукция лабораторияләрдә даими рәвештә тикшерү уза. «Бу исә аларның сыйфатлы, көндәшлеккә сәләтле товар җитештерергә омтылулары турында сөйли», – ди белгечләр.

Бәйге нәтиҗәләре буенча 129 лауреат, беренче дәрәҗәдәге 112 дипломант һәм икенче дәрәҗәдәге 75 дипломант билгеләнгән. Җиңүчеләрнең исемлеген «Татарстан дәүләт төбәк стандартлаштыру, метрология һәм сынаулар үткәрү үзәге» федераль бюджет учреждениесе сайтында табарга мөмкин. Алар ел ахырында бүләкләнәчәк. Хәзерге вакытта «Россиянең иң яхшы 100 товары» программасының федераль этабында катнашуга гаризалар кабул итү башланган.

НӘТИҖӘЛЕ ЭШЛӘДЕЛӘР

ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИН ДЕПУТАТЛАР ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ ЙОМГАК ЯСАДЫ

Дәүләт Советында язгы сессия тәгәлләнде. Сессиянең соңгы утырышыннан соң парламент Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин матбугат конференциясе үткәрде. Анда Дәүләт Советының беренче яртыеллыктагы эшенә йомгак ясалды.

«Язгы сессия киеренке, вакыйгаларга бай булды, – дип билгеләп үтте Фәрит Мөхәммәтшин, матбугат конференциясен ачып. – Асылда бу гомуми вазгыятькә, илебезгә кертелгән санкцияләргә бәйле. Алар, әлбәттә, республика икътисадында да чагылыш тапты. Законнарга халыкны һәм бизнесны саклау-яклауга юнәлдерелгән үзгәрешләр кертү Дәүләт Советының яңа кыенлыкларга җавабы булды.

Язгы сессиядә Дәүләт Советы барлыгы 5 утырыш үткәргән. Депутатлар 140тан артыграк мәсьәлә караган. 40тан күбрәк закон һәм 160тан күбрәк карар кабул ителгән. Законнарның күпчелеген (31) Дәүләт Советы депутатлары, 2сен – Татарстан Президенты, 4ен – Дәүләт Советы комитетлары, 10ын – Министрлар Кабинеты, 1сен Казан шәһәр Думасы керткән.

Президиумның 5 утырышы үткәрелгән, 24 мәсьәлә каралган, 42 карар кабул ителгән. Дәүләт Советы комитетлары беренче яртыеллыкта 50дән артыграк утырыш уздырган, 200дән күбрәк мәсьәләне карап тикшергән.

Хәзер инде депутатлар сентябрь аенда гына утырышка җыелачак. Ләкин «парламент каникулы»н чын мәгънәсендә каникул дип әйтеп булмаячак, чөнки депутатлар барыбер үзләренең округларында эшләүне дәвам итәчәк. Сайлаучылар белән күп очрашулар үткәрергә туры киләчәк. Фәрит Мөхәммәтшин билгеләп үткәнчә, республика Хөкүмәте белән 2023 елга һәм планда каралган 2024–2025 еллар чорына республика бюджетын формалаштыру эше алып барыла да инде.

Дәүләт Советы Рәисе язгы сессия йомгакларына тукталып, килеп туган шартларда депутатларның, нинди генә партиядән булуларына карамастан, бик бердәм эшләүләрен искәртте. «Партияләр күп, ә ил – бер генә», – дип искә төшерде парламент башлыгы Россия Президенты Владимир Путин сүзләрен. Фәрит Мөхәммәтшин шулай ук Дәүләт Советының төбәкләр парламентлары арасында беренчеләрдән булып Владимир Путинның Луганск һәм Донецк халык республикалары территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрүгә бәйле гамәлләрен хуплавын, тиешле мөрәҗәгать кабул итүен искәртте.

Татарстанның күпмилләтле халкы Донбасстан мәҗбүри күченеп килүчеләргә төрле яклап ярдәм күрсәтә. «Авыр хәлдә калучыларга ярдәм итү теләге, мәрхәмәтлелек кешеләребезне берләштерде, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Республикадан 15 йөк машинасы белән гуманитар ярдәм юлланды инде».

Дәүләт Советы Рәисе, парламентта каралган иң әһәмиятле 5 мәсьәлә турында журналистлар соравына җавап биреп, күбесенең социаль (кризиска каршы) юнәлешле булуын билгеләп үтте. Аерым алганда, халыкка адресле социаль ярдәм турында республика законына үзгәрешләр кертелгән. Алар нигезендә социаль ташламалар алучылар саны арткан. Язгы сессия чорында шулай ук республика бакчачыларына дәүләт ярдәме чараларын күздә тоткан закон кабул ителгән.

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, эшмәкәрләргә ярдәм итүгә зур игътибар бирелгән. Парламентчылар калдыкларны утильләштерү буенча инвестицион проектларны тормышка ашыручы оешмалар табышына салым ташламаларын билгеләгән закон проекты һ.б. кабул иткән.

Парламент Рәисе сүзләренә караганда, гади халыктан, иҗтимагый берләшмәләрдән алынучы мөрәҗәгатьләр саны да кимеми. Беренче яртыеллыкта депутатлар барлыгы 6,3 меңнән артыграк мөрәҗәгатьне караган. Күбесе Дәүләт Советы рәсми сайтының интернет-кабул итү бүлеге аша алынган. Берсе дә игътибарсыз калдырылмаган.

Республиканың югары вазыйфаи заты атамасын үзгәртү һәм Татарстан Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында сорау да журналистлар игътибарыннан читтә калмады.

Фәрит Мөхәммәтшин билгеләп үткәнчә, Дәүләт Советының бу юнәлештәге эше дәвам итә, үзгәрешләр регламентта билгеләнгән срокта кертеләчәк. Шул ук вакытта, Дәүләт Советы Рәисе басым ясап әйткәнчә, Конституция – бер бөтен документ, һәм җирле үзидарә турында федераль законга төзәтмәләрне исәпкә алып кына аңа үзгәрешләр кертергә мөмкин булачак. Ә Дәүләт Думасында бу закон беренче укылышта гына кабул ителгән әле. Парламент каникулыннан соң Дәүләт Советының эш төркеме яңадан җыелачак.

«Федераль закон чыгаручы төбәкләр башлыкларына рәттән ике тапкырдан күбрәк срокка сайлану хокукы бирә. Татарстанның республика законына мондый үзгәрешләр кертү планы юкмы?» – дип кызыксынды журналистлар. Фәрит Мөхәммәтшин мондый планның булу ихтималын әйтте. «Әйбәт, уңышлы эшли, үзенә карата дәгъвалар юк икән, сайлаучылар канәгать икән, нигә әле бу кешене чикләргә? – диде ул. – Беренче-икенче срокта кеше тәҗрибә һәм абруй туплый гына әле. Һәрхәлдә, карарны Дәүләт Советы кабул итәчәк».

Матбугат конференциясе ахырында Фәрит Мөхәммәтшин республикадагы вакыйгаларны оператив һәм дөрес яктыртулары өчен журналистларга рәхмәт белдерде.

tatarstan.ru

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Мәскәүдә эш сәфәрендә булды. Республика парламенты башлыгы Россия Федерациясе Советында берничә очрашуда катнашты.
Россия сәнәгатьчеләр һәм эшмәкәрләр берлеге президенты Александр Шохин белән очрашуда санкция басымы шартларында импортны алыштыру һәм сәнәгать предприятиеләрен үстерү мәсьәләләре турында фикер алыштылар. Россия Президенты бүләкләрен тапшыру тантанасында исә Фәрит Мөхәммәтшинга иҗтимагый әһәмиятле чараларны әзерләүгә һәм уздыруга керткән өлеше өчен Россия Федерациясе Президентының Рәхмәт хаты тапшырылды.

Халык кәефе

Дилә НИГЪМӘТУЛЛИНА, җырчы:
– Җәйнең ямен күреп калырга тырышабыз. Башта каен җиләге җыйдым, хәзер җир җиләге өлгерде. Уфага чыгып ясарга чакырдылар, шунда барышым. Җәй аен бик яратам. Рәхәтләнеп ял итеп алабыз. Әлегә иремнең әти-әнисе белән ике арада йөрибез. Алар Казаннан ерак яшәми. Тиздән Балтач районына кура җиләге җыярга кайтырмын дип торам. Җиләкләрне кышка суыткычта саклыйбыз. Шулай итеп витаминнар әзерлибез. Кызым Сәфинә бер айга лагерьга китте. Ул диңгез буенда ял итә.

Фидания ЛЕРОН, укытучы:
– Аллага шөкер, җәем бакчада уза. Оныкларым, улым Бәхтияр белән мәш киләбез. Быел инде тавыкларыбыз юк. Яшелчә, җиләк-җимеш үстердек. Бакча уңышы сөендерә. Кыярны күптән ашыйбыз инде. Борчак өлгерде. Ләбиб абыегыз хаҗда бит әле. Күңел белән аның кайтуын көтәбез инде. Ул хаҗга барам дигәч, борчылган да идем. Башта, ничек барырсың, дип тә әйттем. Әмма аның теләге зур иде. «Аллаһы Тәгалә ничек язган, шулай була», – диде ул. Мин башка берни дәшмәдем. Кан басымы да уйный бит. Шөкер, бар да яхшы булды. 18 көнгә китте бит. Барыбыз өчен дә догалар кылган. Махсус көннәрдә әрвахлар өчен дә укыган. Аның әнисе, минем әтием сөенеп ятадыр. 19 июльдә кайтырга тиешләр. Әлегә Кызыл диңгез буенда ял итәләр. Исән-сау гына йөрсен!

Эльмира ГАЯНОВА, эшмәкәр:
– Шәһәрдә бик эссе. Сулар һава калмагач, Зәй районындагы йортыбызга кайтып киттек. Рәхәтләнеп авылда яшибез әле. Быел тавыклар да алдык. Мунча җиткереп ятабыз. Бакча тулы сый-нигъмәт. Эшкәртеп кенә өлгер. Кыяр да тозлый башладык инде. Үз бакчабыздан помидорны күптән ашыйбыз. Җиләк кайнатмалары да ясап куйдык. Шәһәргә кайтасы да килми.

Айгөл ҖИҺАНШИНА, фельдшер:
– Бу арада эшебез бик күп. Авылга кайтучылар да байтак. Кемнеңдер баласы авырып китә, күп кеше кан басымыннан зарланып килә. Бөҗәк тешләгәннән соң мөрәҗәгать итүчеләр дә артты. Хәзер черки тешләсә дә, ул урыннар шешеп чыга. Шуңа да һәркем кул астында аллергиягә каршы дарулар тотсын иде. Әлегә ял итәргә китә алмадым. Август аена дип планлаштырып торам. Кырымны күреп кайтасыбыз килә.

Миләүшә ФАЗЛЫЕВА, декреттагы әни:
– Быел олы кызым 11 нче сыйныфны тәмамлады. Баллары начар булмады. Теләгән уку йортына керә алырлык итеп җыйган иде. Әмма улым сайлаган һөнәрне үзләштерергә теләүчеләр бик күп икән. Укырга керә алса ярый инде, дип кайгырып торабыз. Җитмәсә, документын да бер генә урынга тапшырган идек. Кечкенәләрен 11 нче сыйныфка калдырмаска дип уйлыйбыз. БДИ дигәннәре бик авыр әйбер икән. Белем ягыннан әйтмим, психологик яктан баланы бик бетерә. Сәламәтлекләрен какшата. Элеккеге имтиханнарга кире әйләнеп кайту мөмкин түгелме икән? Мәгариф министрлыгы әнә шул хакта кайгыртсын иде.

Гөлия ГАБИТОВА, тәрбияче:
– Улымны армиягә озаттык. Әйтерсең, йөрәгем аның белән китте. Илләр дә тыныч түгел бит. Бер теләк белән генә яшим инде хәзер. Улым исән-сау гына хезмәт итеп кайтсын иде. Тормыш дәвам итә. Шуңа да моңаеп утырырга вакыт юк. Кызым Казанга укырга керде, кечкенәсе мәктәптә әле. Тиздән эшемдә нәниләр төркемендә эшли башлыйм.

Әйтеп кенә бактым

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Шулай ясаганнар инде

Гөлгенәнең йөрешләре дә кешечә түгел кебек тоелып китә. Гел каядыр ашыккан кебек алга сөрлегеп атлый ул. Кайчак: «Кая чабасың инде тагын?» – дим.

– Эш күп, Риман абый, эш күп.

– Үлгәч тә өч көнлек эш кала, диләр бит!

Ә Гөлгенә: «Үләргә вакыт юк әле», – дип елмаеп җибәрә.

«ВТ» кызлары барысы да тырыш, барысы да өлгер, берсен генә аерып күккә чөясе килми. Тик кызлар үзләре Гөлгенәне аерым куялар. Кеше хәленә керергә, кемгәдер ярдәм итәргә һәрвакыт әзер торучылар күп микән ул? Җәмгыятьтәге үзгәрешләр кешеләрнең үз-үзләрен тотышларына да шактый ук йогынты ясады, без үз кабыгыбызга бикләнеп яши башладык кебек. Беренче урында – үзең. Бу, бәлки, замана үзгәрешләре китереп чыгарган саклану инстинктыдыр. Шуңа күрә кемнедер гаеплисе дә килми. Чөнки СССР дигән зур илдә без иртәгәсе көн өчен артык кайгырмадык, партия сызган юлдан алга атладык. Ул заманда күпчелек кешенең тормыш дәрәҗәсе дә бер төрлерәк иде. Шуңа күрә бер-беребезгә күбрәк игътибарлы булганбыздыр да. Бүгенге җәмгыятьтә исә һәркем үз урынын табарга тиеш, моның өчен көрәш бара. Эгоизм хисләренең артуы шуның белән бәйледер дә, бәлки.

Кайчак Гөлгенә Шиһапова бу җәмгыятьтә очраклы кеше кебек тә тоелып китә. Беркөнне: «Риман абый, кемгәдер ярдәм итә, берәр яхшылык эшли алсам, миннән дә бәхетле кеше юк», – дип әйтеп шаккатырды ул мине. Кешегә күңелен ярып бирерлек кешеләр бүген дә бар ул, әмма безнең Гөлгенә кебекләр артык күп түгелдер дип беләм.

Күптән түгел Казан урамнарының берсендә юл аркылы чыгарга аптырап торган сукырны күрә ул. Андыйларның «юл күрсәтә» торган таягы була икән, әмма бу таяк, ни сәбәпледер, үзе юлдан язган. Сукыр кеше янышнан минутына әллә ничә дистә кеше узып китә бит инде, әмма аңа игътибар итүче юк. Ике кызын иярләп үзе дә каядыр ашыккан Гөлгенәбез моны күреп ала да җиңеннән тотып туктата. Шуннан юл аркылы чыга башлаган бер кызны чакырып китерә дә, сукыр кешене җитәкләп, урамның икенче ягына чыгарып куюын үтенә. «Якында гына яшәсә, өенә кадәр үк илтеп куя алмассыңмы икән?» – дип тә өсти. Күрәсең, теге кыз да миһербанлы булып чыккан, Гөлгенә аларның җитәкләшеп баруларын күздән югалганчы карап кала.

Бер уйлаганда, бу вакыйгада ис китәрлек әллә ни юк та кебек. Әмма мин үземне Гөлгенә урынына куеп карыйм да, ашыккан җиремнән туктап, әлеге сукырга ярдәм итәрмен микән дип шикләнеп куям.

Без редакциядә Гөлгенә белән чәй эчеп, «гайбәт сатып» утыргалыйбыз. Кайчак аның чәй эчәргә дә вакыты булмый. Әмма чәй ясап куя да: «Риман абый, син эчә тор, минем ашыгыч эш бар әле», – дип чыгып йөгерә. Бераздан әйләнеп кайта үзе: «Тәмле булдымы, тагын ясыйммы?» – ди. Һәрвакыттагыча: «Чәй эчкән бар ла ул…» – дип шаяртып, рәхмәт әйтәм. Беркөнне: «Нигә шундый соң син?» – дип сорыйм.

– Нинди?

– Кеше өчен өзелеп торасың.

– Шулай ясаганнар мине, Риман абый. Әтием Мансур да шундый иде. Авыл урамында кемне күрсә дә, туктатып хәлен сораша, кирәк икән, ярдәм кулы суза торган булган.

Гөлгенәбез «ВТ» битләрендә төрле язмышлы кешеләр турында язмалар чыгарып бара. Аңа телефоннан да шалтыраталар, янына да киләләр. Шуларның ачы язмышлары турында сөйләгәндә, күз яшьләрен агызып елап та җибәргәли икән Гөлгенәбез. Моны миңа булмәдәш кызлары әйтте.

Ярдәм итеп яши Гөлгенә, тиешле оешмаларга шалтырата, хастаханәләрне дә белешә, катлаулы операция өчен акча җыярга да булыша. Шушы максат белән, артистларны күндереп, концертлар да оештыра. Коридорда очратып эндәшсәң, ул иң элек: «Нәрсә, Риман абый, берәр ярдәм кирәк мәллә?» – диячәк. Шулай ясаганнар инде Гөлгенәне.

Бүгенге заман күзлегеннән караганда, берас сәер дә тоелып китәсең син, сеңлем. Ә икенче яктан, бәндә баласы үзара ярдәмләшеп яшәргә тиеш. «Тиеш» дигән мондый закон юк үзе, әмма ул – безнең күңелләрдә, һәм матур хисләрне бикләп тотмыйк. Шулай бит, Гөлгенә?!

БЮДЖЕТ КАГЫЙДӘСЕ

Бу юлларны язар алдыннан автор тормыш дәрәҗәсе ягыннан илләрнең рейтингын карады. Без күптән түгел генә язган идек: табигый байлыклар буенча Россия дөньяда тиңсез рәвештә беренче урынны тота. Шулай булгач аңлашыла инде: күз илне рейтингның иң югары баскычыннан ук булмаса да, беренче унлыктан, һич югында икенче дистәдән эзли. Россия G20 илләренә керә, ягъни икътисады зур булган беренче егермелек сафында. Бу үзе үк искәртә: тормыш дәрәҗәсе икътисадның зурлыгына якын килергә тиеш. Дөрес, табигый байлыклар һәм икътисад зурлыгы автомат рәвештә матди байлык һәм тормыш сыйфатын гарантияләмиләр. Әйтик, Кувейт – нефть яңгырында коенучы бәләкәй ил – 2021 ел башында исемлекнең 55 нче баскычында гына. «Кара алтын» лидеры Согуд Гарәбстаны 31 урынны гына били. Чехия, мәсәлән, 22 урында, Литва – 19да, Эстония – 11дә. Кувейтны Эквадор, Коста-Рика, Уругвай кебек Латин Америкасы илләре байтакка узып киткәннәр. Россия 2021 ел башында, санкцияләр кертелгәнче, тормыш дәрәҗәсе рейтингында – 67 урында. Чагыштырыгыз: Марокко – 64тә, Пакьстан – 61дә, Румыния – 40та. 2022 ел рейтингы Россияне бөтенләй түбәнгә алып ташлаган, 90 нчы урын белән канәгатьләнгәнбез. Чөнки кесәдә бер дә акча тормый, хезмәт хакы бик тиз парга әйләнә. Моңа бик артык гаҗәпләнмибез дә инде. Санкцияләр рейтингындагы беренче урын безгә тормыш дәрәҗәсенең түбәнге баскычын тәэмин итә. Илнең тормыш өчен әһәмиятле иң гади кирәк-яракларны да үзе җитештерә алмавына Федерация Советы Рәисе Матвиенко ханым да торып-торып гаҗәпләнә. Югары технологияләр турында сүз дә алып бармыйбыз инде. «Российская газета»ның чәршәмбе санында «Почему России нужны собственные технологии для производства СПГ» дигән язма бар, ягъни ил табигый байлыклар чыгару технологияләренә дә инвестицияләр ясамаган, тулысынча чит илләрдән бәйлелектә яшәгән. Сер түгел: Россиянеке дип саналган технологик продуктлар да тулысынча диярлек чит ил комплектлаучыларыннан тора һәм хәттә җитештерелүе дә чит илләрдә. Продуктка исемне генә Россия бирә, чөнки инвестор – Россиядән. Артта калган Африка иле Руанда, мәсәлән, үз элемент базасында үз смартфоннарын җитештерә, галәмгә ясалма иярченнәр дә чыгара. Без ничек бу көнгә калдык дигән сорауга җавап эзлик әле.

Санкцияләр шуны күрсәтте: Россия чынлап та бик куәтле финанс державасы булган. Көнбатыш илләрендә бикләнеп калган гигант дәүләт резервлары, олигархларның әллә бер триллион, әллә ике триллионлык түндырылган активлары шул хакта сөйли. Ул акча ил икътисадында әйләнсә, югары технологияләрне үстерүгә хезмәт итсә, илдә бөтенләй башка хезмәт хаклары, бөтенләй башка тормыш дәрәҗәсе булыр, державалар безнең белән сөйләшкәндә, авызларын бик үлчәп кенә ачарлар иде. Санкцияләр турында сүз дә була алмас иде. Әмма без иң тук елларда мәгарифне оптимальләштердек, хастаханәләрне яптык, галимнәрне ач паекка утырттык… Әйе, әйе, бар иде ул 25 миллионлык югары технологияле эш урыны турында карарлар һәм вәгъдәләр, технологик ыргылыш турында матур сүзләр. 24 февральдән соңгы вазгыять безне күктән җиргә тартып төшерде: югары технологияле линияләр түгел, кәгазь һәм буяу кебек элементар продуктлар җитештерүче цехлар да җитәрлек түгел. Мондый хәл туунның сәбәпләре күптөрле, билгеле. Без берсен – иң мөһимен генә алып карыйбыз. Ул бюджет кагыйдәсе дип атала. Беренче тапкыр Россиядә 2004 елда шундый кагыйдә кертелде: табигый байлыклар (нигездә, нефть) сатудан кергән акчаны тулысынча ашап бетермәскә, ә «кара көн»гә саклау өчен зур капчыкка салып, авызын бәйләп куярга. Болай начар кагыйдә түгел ул үзе. Бар чагында бүредәй, юк чагында шүредәй дигән принцип белән дә яшәргә ярамый. Капитализмда циклик кризислар кабатланып торуын һәркем белә. Менә шундый кризис вакытында капчык авызын чишәсең дә давыл узганчы рәхәтләнеп яшисең. Нефть һәм газ сатып көн күргән илләрнең барысында да бар шундый кагыйдә. Норвегия артык акчаны үзенең суверен фондына салып тота, Катарның да суверен фонды бик бай. Әмма ул фондлардагы акча тик ятмый, төрле проектларда катнаша һәм зур гына табыш китереп үрчи. Россия башта Стабилизация фонды дигән фондта саклады капиталын, аннан соң Резерв фонды һәм Милли байлык фондлары барлыкка килде. 2004 елда нефть бәясе 20 доллардан артса, арткан табыш махсус фондка күчерелде, 2006 елда 27 долларлык баррельне чик итеп алдылар, 2008–2009 елгы кризислардан соң планка 40–50 долларга кадәр күтәрелде. 2021 елда «кара алтын» бәясенең 43,3 доллардан арткан өлеше киселеп, резервка салынды. Нефть бәясе 60 доллар булса да, 160 доллар булса да, бюджетка әҗер 43,3 доллардан гына керә иде ягъни. Акчаның саклауга куелган өлеше чит ил банкларына ыргытылды. Олигархлар да чимал табышын офшорларда саклауны кулайрак күрделәр. Илдәге югары технологияләргә акча инвестицияләнми диярлек иде. Күрәбез бит инде: хәттә нефть һәм газ чыгару технологияләренә дә акча табылмаган, аларын да чит илдән алуны сөйгәннәр. Кризис вакытларында Милли байлык фондыннан бары тик инфраструктур проектларга гына бераз акча бүленә иде. Ул кадәресе дә ярады, әлбәттә. Әмма нигездә нефть табышы чит илләрдә сакланды һәм шул илләр икътисадына эшләде. Федераль хөкүмәт бюджет дефицитлы булганда да, профицитлы булганда да ни өчендер әҗәт кәгазьләре – облигацияләр сата иде. Милли байлык фондына исә бик сак каралды. Ул саклык печән өстендәге эт принцибын хәтерләтә иде: үзебез дә ашамыйбыз, халыкка да бирмибез. Нефть бәясе югары булып, доллар күп кергәндә, Финанс министрлыгы валюта сатып ала һәм аны чит ил банкларына саклауга озата иде. Нефть түбәнгә китеп, валюта агымы саекса, ясалма рәвештә доллар курсын күтәреп, резервларны саклау ягын карадылар. Болай эшләгәндә, долларда резервлар кимесә дә, сумда арта иде. Бюджет сумда тотыла бит, шуңа күрә казна акчага тилмермәде. Акчага бер генә субъект коргаксый иде андый чакларда, ул – халык. Схема белән танышкач, әйтә алабыз: Россия халкы беркайчан да «кара алтын»ның 40–50 доллардан арткан бәясеннән әҗер күрмәде. Асылда ил нефтьне һәрвакытта да шул бәядән генә сатты, акчаның арткан өлешен «дус булмаган илләр» файдалана иде. 24 февраль вазгыятьне үзгәртте. Бердән, читтә сакланган акча бикләнде һәм аларны бюджетка кире кайтару хәзер инде өметсез. Шул сәбәпле нефть акчасының артык өлешен читкә куу мәгънәсезгә әйләнде. Бюджет кагыйдәсе җимерелә башлады. Хәзер валюта күп, артык өлешен инвестицияләргә дә тотып булыр шикелле, әмма безгә технологияләр дә, технологик җиһазлар да бирмиләр. Киң куллану товарларын да бик сыгып кына кертәләр. Хәзер инде бюджет кагыйдәсе түгел, җелекне долларның фантикка әйләнүе сыга. Без һаман да чималны, бәясе күпме булуга карамастан, бушка диярлек сатабыз. Көнбатышлылар хәзер Россия нефте бәясенә «түшәм» куярга азапланалар. Игътибар итсәгез, «түшәм»нең бюджет кагыйдәсе чигендә булуын күрер идегез.

Милли байлык фондын, Резерв фондын ил эчендәге технологик проектларга тотып була идеме? Әгәр дә булса, без бүген сөт янсә сок салырга савыт эзләп интекмәс идек бит. Теоретик яктан күз ташлаганда, артык чимал акчасын ил эчендәге инвестицияләргә тотып була һәм шулай кирәк тә иде. Әмма тормыш чынлыгы шундый: бизнес та, рәсми даирәләр дә ил икътисадына ышанмадылар. Олигархлар көннәрдән бер көнне хакимиятләр байлыкларын тартып алыр дип курыктылар. Ахыр чиктә ул байлыкларның төп өлеше, чынлап та, тартып алынды, әмма конфискацияне Россия хакимиятләре түгел, глобаль капитализм хуҗалары тормышка ашырды. Хакимиятләр исә күреп тора иде: акчаны инвестицияләргә дип бүлдеңме, урлана. Федераль хөкүмәт газетасы соңгы санында хәбәр итә әнә: Хисап палатасының хисабыннан соң 2021 елда ун җинаять эше ачылды, ди. «Дәүләт сатып алуы» дигән механизм аша бик күп акча урлана. 35 триллион сум әйләнә икән ул тәгәрмәчтә. Урланган 1 триллион сум сизелми дә диярлек.

Илдә хәзер башка вазгыять формалашты. Югары даирәдә хәрәкәт иткән бик күп шәхесләр кулга алына. Чубайс кебекләр читкә качып өлгерде. Үз технологияләребезне булдыру, үзең җитештерү хәзер исән калу дәрәҗәсендә әһәмиятлегә әйләнде. Элеккечә исраф итеп, элеккечә урлап яшәп булмый башлады. Я үсеш юлына басасың, я һәлак буласың. Бу дилемма ничек хәл ителер, алдан әйтү кыен. «Өф» итүгә җимерелеп төшә торган бутафор проектлар заманы узды. Монысы анык билгеле.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

ЯЛГА КИТТЕЛӘР, ӘММА ЯЛ ИТМИЛӘР

ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫ ЯЗГЫ СЕССИЯНЕ ТӘМАМЛАДЫ

Кичә парламентыбыз 33 нче утырышын уздырып, язгы сессияне төгәлләде. Һәр утырыш башында республика бюджетына кагылышлы закон проектын тикшерү табигый инде ул, кесәсен капшап карамыйча, кеше дә эшкә тотынмый бит.

Татарстан да үз казнасын барлап куйды. Быелга һәм 2023–2024 елгы план чорына нинди өметләр баглыйбыз соң? Финанс министры Радик Гайзатуллин чыгышыннан аңлашылганча, бюджетның керем өлеше, 55,1 млрд сумга артып, 355,2 млрд сумга җиткән. Әле ел ахырына тагын 40 млрд сумга артуы бар икән. Бездә казна нигездә нефть табу һәм эшкәртү хисабына тулылана, шулай ук предприятие һәм салым түләүче сәүдә оешмалары да «изге эш»кә үз өлешен кертә. Инде федераль казнадан да шактый акча керәчәген әйтсәк, борчылырга әллә ни сәбәп юк. Федераль үзәк бюджет кытлыгын (быел ул 37 млрд чамасы) капларга да булыша. Алдагы ике елга бу сан 21 һәм 20 млрд сум булыр дип фаразлана. Акча тирәсендә хәзергә менә шул, закон проектын тикшергәндә бәхәс тә чыкмады.

Ә менә Әлки районындагы Сихтермә-Хузангай авылының исемен үзгәртүгә кагылышлы закон проекты депутатларны дулкынландырды. Халык фикерен исәпкә алып аны «Сихтермә» дип кенә калдырмакчылар икән. Депутат Ркаил Зәйдулла уенча, нигә Хузангай сүзен алып ташларга? Мәсәлән, бездә Тукай-Кырлай бар бит! Петр Хузангай да – чуашның атаклы шәхесе, халык шагыйре, тәрҗемәче. Чувашстанның Язучылар берлеге җитәкчесе, СССР Язучылар берлеге әгъзасы булган кеше. Аны, милләтчелектә гаепләп, төрмәгә дә япкан булганнар, аннан соң аклаганнар. Ркаил Зәйдулла фикерен депутат Илдар Шамилов та хуплаган иде. Әмма башка депутатлар, авыл халкы фикерен беренче урынга куярга кирәк, диделәр. Шуның өстенә Петр Хузангай исеме мәктәпкә, авыл урамына бирелгән. «Сихтермә» дигән чуаш сүзе исә шомырт агачыннан ясалган асылмалы бишек дигәнне аңлата. Парламент Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да халык фикерен хуплый. Депутат Хафиз Миргалимов: «Мәсьәлә гади түгел», – дип сүз башлап, шактый эчкә кереп китте. Аңа татар авылларының исемнәрен килбәтсез бозып әйтүләре ошамый иде. Ул юнәлештә үзебезгә дә эшләргә кирәк әле. Сүз бирелүдән файдаланып, темадан читкә дә китеп алды Хафиз иптәш. Татарстанга Геннадий Зюганов килүе, бездәге тормышка гаҗәпләнүе, Россиянең башка төбәкләре Татарстаннан үрнәк алырга тиеш, дип әйтүләрен рухланып сөйләде дә шул ук күтәренке рух белән Сихтермә авылы егете, сәясәтче, Россия Думасында КПРФ депутаты булып торган Иван Казанковны телгә алды. Иван Ивановичны бездә күп кеше беләдер, һич югы ул җитәкләгән «Звенигово» авыл хуҗалыгы кооперативы күпләргә таныштыр. Ул әле Әлкидә Хузангай хуҗалыгын да «чәчәк аттырды», авыл җирендә хәтта офтальмология поликлиникасы да төзетте. Насыйп итсә, шул якларны урап, Хафиз Миргалимов әйтмешли, «халык предприятиесе»н кайтам әле. Халык предприятиесе димәктән, дәүләттән бер тиен кредит алмыйча бик уңышлы эшләп килүче, халыкка 70 мең сумга хәтле айлык хезмәт хакы түләүче андый предприятиеләр илдә нибары 12 генә икән. Хафиз иптәш хуҗалык итүдә шундый предприятиеләр моделен кулланырга тәкъдим итте. Әмма депутатларыбыз хәзергә дәшмәде. Боларны сүз уңаеннан гына әйттем һәм «әйттем исә кайттым» дип котыла торыйм.

Фәрит Мөхәммәтшин федераль законнарга кагылган берничә закон проектына берьюлы тавыш бирергә тәкъдим итте. Монысы бушка дигәндәй вакыт үткәрмәс өчен әйбәт инде. Ә менә Россия Хөкүмәте Рәисе Михаил Мишустинга юллайсы мөрәҗәгать игътибарга лаек дип уйлыйбыз. Мөрәҗәгатьне парламентның Социаль сәясәт комитеты һәм «Мәрхәмәт – Милосердие» хатын-кызлар төркеме әзерләгән.

Асылы болайрак: авыл җирендә һәм шәһәр тибындагы бистәләрдә даими яшәүче хатын-кызларыбызга өченче бала тугач федераль бюджеттан бер тапкыр түләнә торган акча бирергә кирәк. Аның күләме 100 мең сум булырга тиеш. Моңа хәтле пособие беренче, икенче бала тапканнарга бирелә иде һәм «Мәрхәмәт» төркеме җитәкчесе Алсу Нәбиева әйтүенчә, мондый кызыксындыру чарасы яхшы нәтиҗә биргән. Ә акча Татарстан бюджетыннан бирелә иде. Хәзер депутатлар туучы балалар санын арттыру буенча Татарстан тәҗрибәсен федераль дәрәҗәгә күтәрмәкчеләр һәм пособие дә ил казнасыннан булса яхшы диләр.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Депутатлар «Мәрхәмәт-Милосердие» хатын-кызлар төркеменең Россия Хөкүмәте Рәисенә күпбалалы аналарга кагылышлы мөрәҗәгатен хуплады.

Бу мәсьәләне тикшергәндә кайбер депутатлар мөрәҗәгатькә «дүрт һәм аннан да күбрәк бала табучы аналарга» дигәнрәк сүзләр өстәргә тәкъдим иткәннәр иде. Фәрит Мөхәммәтшин да: «Шулай үзгәртсәң, бәлки хатын-кызларыбыз өч бала тапканнан соң туктап калмаслар», – диебрәк шаяртып куйды. Депутат Марат Галиев исә ашыкмаска киңәш итте. Чөнки балалар саны буенча акча бирү өчен аның күпмегә төшәсен чамаларга кирәк, ә бу – кыен эш. Ничә бала туасын хет якынча чамаламыйча федераль бюджеттан өстәмә акча сорап булмый бит. Марат Галиев фикере белән барысы да килеште һәм мөрәҗәгать Алсу Нәбиева укыганча кабул ителде.

Парламент утырышында Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты үзенең ярты еллык эшчәнлегенә йомгак ясады. Бу үзенә күрә бер яңалык иде һәм парламент Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин мондый тәҗрибәне киләчәктә дә дәвам итү ягында.

Парламент эшчәнлегенә ярты елга, бер елга хисап тотканда, аерым комитетларны да тыңлау бик кирәктер ул. Кемнең ничек эшләгәнен башка депутатлар да, халык та белсен дип әйтүебез. Ә Шакир Яһудин җитәкләгән комитет аерым игътибарга лаек. Исеменнән үк күренгәнчә, ул – закон чыгару эшенә иң якын комитет. Узган ярты еллыкта ул 49 утырыш уздырган, 290 мәсьәлә тикшергән. 36 закон проекты каралып, берсе дә кире кагылмаган, ягъни закон төсен алган. Иң әһәмиятлесе – барлык закон проектларын да депутатлар үзләре эшләгән. Бу урында Фәрит Мөхәммәтшин тарафына бер «комплимент ыргытып аласы» килә. Моннан берничә ел элек ул һәр комитет каршында иҗтимагый экспертлар Советы оештыру тәкъдиме белән чыкты. Тәкъдим итеп кенә калмады, аларны оештыруда үзе турыдан-туры катнашты.

Экспертлар советлары үзләрен аклыйдылар. Һәр иҗтимагый советта ун-унбиш кеше бар. Алар яшәешебезнең төрле тармакларында эшлиләр. Үз өлкәләренең яхшы белгечләре. Һәм иҗтимагый совет әгъзалары буларак, бер тиен дә акча сорамыйча, законнар язуда катнашалар.

Утырыштагы «Хөкүмәт сәгате»ндә Татарстанның экология һәм табигый ресурслар министры Александр Шадриков чыгыш ясады. Бик мәгънәле, уйландыра торган иде аның чыгышы.

Безгә 4 федераль проектны тормышка ашыру өчен Россия казнасыннан 4,5 млрд сум акча бирелгән иде. Министр шул дүрт проектның берсен аеруча әһәмиятле дип саный. Ул «Иделне савыктыру» («Оздоровление Волги») дип атала. Идел суының бик пычрануы турында сүзләр инде күптән ишетелә. Соңгы ярты гасыр эчендә Куйбышев сусаклагычы зонасында гына да 100 гектар мәйданда 4 млн кубометр пычрак ләм җыелган икән.

Идел суын пычратуга Түбән Кама сусаклагычы да үз өлешен кертә. Сусаклагычта су күтәрелгәндә бихисап нефть торбалары күмелеп калган һәм череп яталар. Тагын санап китсәң, зур сулар төбендә әле кайчандыр баткан 75 судно «көн яктысын күрергә» тилмереп ята ди.

Министр сулыкларның пычрануында авыл хуҗалыгы предприятиеләре өлеше бик зур булуын да әйтте, хәтта «төп фактор» дип атады.

Су пычрану ул – безнең сәламәтлеккә зур зыян дигән сүз. Идел бассейнында 60 млн кеше яшәвен әйтсәк, Россия халкының өчтән берәнә куркыныч яный дигән сүз. Идел буен Россия сәнәгать предприятиеләренең – 45, авыл хуҗалыгы предприятиеләренең 50 проценты сырып алган. Шушы саннарны укыгач, киләчәгебез турында үзегез уйланыгыз. Әле бездә Иделдән башка да пычранып беткән күпме елга-күлләр бар.

«Иделне савыктыру» проектына килсәк, аның максаты – илнең төп артериясе пычрануын һич югы 3 мәртәбә киметү.

Су кеше тормышында аерым урын алып тора, ул – яшәү чыганагы. Моны һәркем аңлый, ә Идел суы ага тора, пычрана тора.

Бу мәсьәләнең бик четерекле икәнен Фәрит Мөхәммәтшин дә аңлый, шуңа күрә әлеге темага кат-кат әйләнеп кайтырбыз, диде. Ә Экология министрлыгына җаваптар эшләргә, федераль бюджеттан килгән акчаны вакытында тулысынча үзләштерергә кирәк, диде.

Шулай итеп парламентта җәйге ял игълан ителде. Әмма бу, парламент Рәисе әйтмешли, ял итәргә дигән сүз түгел. Заман чакыруларына вакытында җавап бирер өчен эшләргә дә эшләргә кирәк. Быел киләсе ел бюджетына да башка елларга караганда бик иртә тотынганнар. Депутатларны үз округларына ешрак чыгарга чакырды Фәрит әфәнде. Аның уе – төрле дәрәҗәдәге депутатлар белән бергә эшләүне җайга салу, алай гына да түгел, яңа баскычка күтәрү. Шуңа күрә депутатлар белән хушлашмыйбыз, күңелле, матур яллар да теләмибез. Хәер, эшлисе килгәне болай да эшли инде аның. Ә соңгы утырышта депутатлар саны тиешле йөз урынына җитмеш тирәсе генә иде бугай.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Язучы сүзе

Тигезлек

Уч төбе күккә караган, анда сэнсей су белән тулы касә утыртып куя һәм миңа төрле хәрәкәтләр ясарга куша. Мин ясыйм, су түгелә. Ә суны түкмәскә кирәк. Ул хәтта дулкынланмаска да тиеш. Тигезлек булырга тиеш. Тиешен тиештер дә бит, тик тиз генә өйрәнеп буламыни? Мин тырышам. Килеп чыкмый. Соңыннан үзем генә калганда да күп тапкыр шөгыльләнәм. Нәрсәнедер бер тапкыр дөрес эшләргә телисең икән, аны мең тапкыр кабатларга кирәк. Мин кабатлыйм. Тигезлек булырга тиеш, дим. Касәне уч төбендә йөртү килеп чыга. Тән авырлыгын бер аяктан икенчесенә күчерү дә әйбәт бара. Су селкенеп тә карамый. Бу мөһим икәнен дә беләм. Синең хәрәкәтләрең көндәшең өчен сизелмәслек булырга тиеш. Әгәр син тән авырлыгын уң аягыңнан сулына сиздереп күчерәсең икән, уң аягыңны күтәреп һөҗүм итәчәксең. Дәгъвачың моны күреп торачак. Әгәр синең һәр хәрәкәтең сыгылмалы һәм тигез икән, дәгъвачың нәрсә котәргә дә белмәячәк. Барысын да аңлыйм. Шуңа тырышам. Ә сэнсей тагын да катлауландыра. Ул хәзер хәтта сикергән очракта да суның чайпалмавын тели. Инь-янь тигезлеге булырга тиеш, ди. Ә алай булмый. Бик озак изалангач, мин: «Шайтаныма олаксын тигезлегең», – дип ары китәм. Ләкин…

Тигезлектән ары китеп булмый икән. Инь-янь дип аталса да, яхшылык – явызлык яки ак – кара диелсә дә, тигезлек ул – һәрвакыт тигезлек. Һәм ул бар. Ул – безнең теләкләрдән, ихтыярдан башка яши ала торган бәйсез төшенчә. Гомеремнең төрле чакларында я кылтаебрак китсәм, я төшенкелеккә бирелә башласам, яшьлегемнең шушы мизгелләре калкып чыга да мине сэнсей тавышы белән: «Тигезлекне сакла!» – дип кисәтә. Һәм мин рухым төпкелендә яткан көчләрне җыеп кабат үз хәлемә кайтам.

Тигезлек дигәч, кечкенә чакта күңелгә сеңдерелгән коммунизм идеяләре дә күз алдына килә әле. Кешеләрнең барысы да тип-тигез, дигәнрәк караш яши иде бит. Мин хәзер беләм инде: кешеләр тигез түгел, алай була алмыйлар да. Мин эшләгәнне башкалар эшли алмый, башкалар эшләгәнне мин булдыра алмыйм. Шулай булгач, нинди тигезлек ди инде?! Кешеләр тигез түгел. Ләкин моны трагедия яки кемнәрнедер кимсетү дип тә кабул итәргә ярамый. Кулымдагы бармакларым да тигез түгел, тик аларның һәркайсы – үз урынында. Бу очракта тигезлек – икенчел төшенчә. Кешеләрнең тигезлеге түгел, үз урынында булуы мөһим.

Ләкин тигезлек бар. Без яшәгән дөнья үзе бер тигезлек – ул барысын да тигезли, һәркемне үз урынына бастыра, утырта яки яткыра… Һәм һәрбер кеше үзенең һәр гамәле өчен җавап бирә. Үзе җавап биреп өлгермәсә – балалары, нәсел-нәсәбе… Шуңа күрә, ни генә кылсаң да: «О, мировой кабахәтлек эшләдем, беркем дә сизмәде…» – дип сөенергә кирәкми. Чөнки гади генә, бер каптырмалы гына җан иясе булсаң да, син – галәмнең бер өлеше. Әгәр үзең беләсең икән, димәк, аны бөтен галәм белә. Бары тик дәшми генә. Кайчагында дәшми…

Кешенең кылган һәр гамәле үзенә әйләнеп кайта. Гади генә нәрсә инде менә… Әгәр син кышын матур булып күренергә теләп, ярым ялангач йөрисең икән – салкын тидерәсең. Әгәр җәйге кайнар кояш астында озак итеп ялангач ятасың икән – тәнеңнең тиресе янып чыга. Әгәр син каршы искән җилгә төкерәсең икән, ул үзеңнекен үзеңә кайтара. Тормыш, гомумән, каршыга искән җил шикелле: син аңа нәрсә бирәсең, ул сиңа шуны бирә.

Менә без хәзер мөлкәт туплау, яшәү шартларын яхшырту дип чабабыз бит инде. Җитми безгә, мөмкинлекләр ачылганда бигрәк тә. Барысын да алып калырга тырышабыз, берни дә кулдан ычкынмаска тиеш дип уйлыйбыз. Күп очракта берни белән дә исәпләшеп тормыйбыз, үз ихтыяҗларыбызны канәгатьләндерергә тырышкан кебек тоелабыз. Зур сарайлар, затлы машиналар, күп акча… Ә кирәкме соң алар? Менә шулар синең гаилә мөнәсәбәтләреннән дә, балаларың белән аралашудан да, дусларың белән гомер уздырудан да кыйбатракмы? Төгәл әйтеп булмый. Чөнки мин дә акча – мөлкәт – дан өчен чукынган җәмгыятьтә яшим. Ни генә дип әйтсәм дә, хаталанырмын кебек. Әмма…

Мин кайчагында бик бай кешеләрне кызганам. Алар бөтен нәрсәне сатып ала. Мин менә Ходай биргән елга, күл, урманнар белән хозурланам. Ә аларның үз елгаларын, үз күлләрен булдырасы килә. Үз урманнарын. Бассейн инде шундый, парк искиткеч… Тик берсе дә күл дә, урман да түгел. Җенси нәфесләре котырып киткәндә, кызлар чакыралар. Шундый матур кызлар инде, бөтен размерлары туры килгән… Тик мәхәббәт түгел. Менә шул нык бай абзыйлар табигыйлектән мәхрүмдер кебек тоела. Күл түгел, урман түгел, мәхәббәт түгел… Бар да ясалма. Ходайның үзеңә атап бирелгән хозурлыкларын күрү сәләтеннән мәхрүм кешеләр үзләренә үзләре хозурлык тудырырга омтыла, үзләренә һәм якыннарына Ходай булырга маташалар. Берни дә әйтеп булмый монда… Аллага табынучылар Ходай биргән мөмкинлекләр белән яши, акчага табынучылар – акча биргән мөмкинлекләр белән.

Тигезлек бар…

Ул тигезлек җанда булырга тиеш. Шуңа ирешкәндә генә кеше бәхетле була аладыр. Күңел тынычлыгы инде ул. Күңел тынычлыгы оҗмахның бер төре бугай.

Ә теге сэнсейны мин әле дә сагынам. Касәне учларыма алам да төрле хәрәкәтләр ясап карыйм. Тик хәзер мин бүтән инде. Һәм ул касәдә дә су түгел, ул касәдә хәзер – минем җаным. Нинди генә кискен адымнар ясасам да, мин аны түкмәскә, чайпалдырмаска тырышам. Касә тигез, җан тыныч булырга тиеш. Тормыш кануны шундый.

Ә мин сезгә тигезлек телим. Касәләрегез бик чайпалмасын…

Марат КӘБИРОВ

СТАЖ САТЫЛА. КЕМ АЛА?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Лаеклы ялга чыкканда җитеп бетмәгән стажны сатып та алып була. Соңгы арада әнә шундый хәбәр таралды. Халык арасында бу уңайдан фикерләр икегә бүленде. Берәүләр моны имеш-мимеш итеп кенә кабул итте. Икенчеләр исә, акчага сатып алынган стаж белән лаеклы ялга чыгудан ни мәгънә, дигән фикердә.

Эш стажын, дөрестән дә, сатып алып буламы? Күпләрне борчыган шушы сорауларга ачыклык кертү өчен Татарстан буенча Россия Пенсия фонды бүлеге җитәкчесе Эдуард Вафин белән элемтәгә кердек.

Билгеле булганча, бүген лаеклы ялга чыгу өчен пенсия яшенә җитү генә аз. Моның өчен билгеле бер күләмдә эш стажы тупланган, фәлән кадәр шәхси пенсия коэффициенты җыелган булырга тиеш. Әйтик, быел лаеклы ялга чыккан кешенең ким дигәндә 13 ел эш стажы, 23,4 пенсия коэффициенты тупланган булырга тиеш.

Аларның кайдан җыелганын һәркайсыбыз белә. Эш бирүче хезмәткәре өчен Пенсия фондына акча күчерә, шәхси эшмәкәрләр исә булачак пенсиясен үзләре кайгырта. Алар Пенсия фондына үзләре акча күчереп бара. Эш стажы белән пенсия коэффициенты дигәнең әнә шуларга нигезләнеп исәпләнә дә инде.

– Әгәр кеше пенсия яшенә җиткән, әмма лаеклы ялга чыгу өчен аңа алда телгә алынган күрсәткечләр җитеп бетмәсә, ул лаеклы ялга биш елга соңрак чыгачак. Шушы вакыт эчендә эшләп, җитеп бетмәгән эш стажы белән тиешле коэффициентларны җыеп та бетерә ала. Эшләмәүче кешеләр, чит илдә хезмәт куючылар, «һөнәри табышка салым» дигән махсус салым тәртибеннән файдаланган физик затларга җитеп бетмәгән эш стажын сатып та алырга мөмкин, – ди Эдуард Вафин.

Мисал өчен, киләсе елда лаеклы ялга чыгу өчен минималь стаж күләме 14 ел тәшкил итәчәк. Фәлән абзый хезмәт урынында 13 ел эшләгән дә, бүген эшсез икән дип күз алдына китерик. Аның менә шушы лаеклы ялга чыгу өчен җитеп бетмәгән бер ел стажны сатып кына да алу мөмкинлеге бар. Моның өчен ул Пенсия фондына гариза язып, шушы бер ел өчен тиешле акчаны түләп, үзенә кирәкле стажны сатып ала. Шул ук вакытта аңа пенсия коэффициенты да өстәләчәк.

«Лаеклы ялга чыгу өчен кирәкле стаж минималь хезмәт хакы күләме (МРОТ)х22%х12 формуласы буенча исәпләнә. Быел минималь хезмәт хакы күләме 13890 сум тәшкил итә. Шуңа күрә лаеклы ялга чыкканда җитеп бетмәгән бер еллык эш стажын бүген 36669,60 сумга сатып алырга мөмкин. Бер ел стаж белән беррәттән бу акчага кешегә якынча 8 пенсия коэффициенты да өстәләчәк», – дип ачыклык кертте Эдуард Вафин «ВТ» хәбәрчесенә.

Бу урында шунысын да искәртергә кирәк: сатып алынган стаж гариза язган көннән исәпләнәчәк. Тиешле сумманы тулысынча түләмәгән очракта, эш стажы да күчерелгән акча күләменә карап кына исәпләнәчәк.

Беренче карашка шактый кызык, хәтта бераз сәеррәк тоелган бу мөмкинлекнең тагын бер үзенчәлеге бар. Гамәлдәге закон билгеле бер күләмдәге эш стажын гына сатып алырга рөхсәт итә. «Быел, әйтик – 6,5 елга кадәр, киләсе елда – күп дигәндә 7 ел, 2024 елда 7,5 елга кадәр генә җитеп бетмәгән эш стажын сатып алырга мөмкин», – диде Эдуард Вафин. Җаным күпме тели, шуның кадәр стаж сатып алып була икән дип тынычланырга кирәкми, кыскасы.

167 нче номерлы федераль законның 29 маддәсе нигезендә кеше башка физик зат өчен дә эш стажы сатып алырга хокуклы. Әгәр кеше үзе өчен иминият кертеме түләргә уйлый икән, ул паспорт һәм СНИЛС белән Пенсия фондының клиент хезмәтенә мөрәҗәгать итәргә тиеш. Башка кешегә мондый «бүләк» ясаганда, үзеңнең генә түгел, кертем ясалачак кешенең дә паспорты белән СНИЛСы кирәк булачак. «Исегезгә төшерәм: иминият взносын ел саен 31 декабрьдән калмыйча түләргә кирәк. Тиешле сумманы берьюлы да, берничә айга бүлеп тә түләргә мөмкин», – дип искәртте Пенсия фонды җитәкчесе.

Сүз уңаеннан, бу көннәрдә белгечләр ил халкының җитеп бетмәгән эш стажын сатып алуга нинди мөнәсәбәттә булуын ачыклаган. «Комсомольская правда» басмасы сайтында уздырылган сораштыру нәтиҗәләреннән аңлашылганча, бу мөмкинлектән файдаланырга теләүчеләр бармак белән генә санарлык икән.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

РОССИЯ ХАЛКЫ СТАЖ САТЫП АЛЫП, ЛАЕКЛЫ ЯЛГА ЧЫГАРГА РИЗАМЫ?*



30% – юк, үземнең эш стажым җитәрлек.

24% – юк, бу бик кыйимматкә төшә.

18% – җитмәгән стажны эшләп, җыеп бетерәчәкмен.

13% – җавап бирергә кыенсынам.

10% – сатып алыр идем, ник дигәндә, бик озак еллар рәсми рәвештә теркәлмичә эшләдем.

5% – мин бөтенләй эшләмим, шуңа стажны сатып кына алыр идем.

* сораштыруда 7,4 мең кеше катнашкан.

КИЛӘЧӘК МӘЧЕТЕ

БАШКАЛАНЫҢ ҖӘМИГЪ МӘЧЕТЕ НИНДИ БУЛЫР?

Узган атнада Казандагы җәмигъ мәчет проектына конкурс нәтиҗәләре билгеле булды. Анда Татарстанның атказанган архитекторы Айвар Саттаров һәм «Гинзбург Архитектс» архитектура-реставрация бюросы проектлары җиңде. Алга таба нинди эшләр көтелә? Булачак мәчет корылмасына нинди мәгънә салыначак? Урыны дөрес сайланганмы, проект нидән гыйбарәт булачак? Бу һәм башка мәсьәләләргә ачыклык кертәбез.

Җиңүче проект авторларының берсе (сүз уңаеннан, аның Кол Шәриф мәчете архитекторы икәнлеген дә искә төшереп узыйк), архитектор **Айвар САТТАРОВ** фикеренчә, һәрбер архитектура корылмасы киләчәккә юнәлтелә. Шуңа күрә аны бүген кабул итмәскә дә мөмкиннәр. Ул иҗат иткән «Нух пәйгамбәр көймәсе» фәлсәфәсе нидән гыйбарәт? Без шул хакта сөйләштек.

:: Айвар абый, Казанның архитектурасына нинди бәя бирәсез?

– Соңгы ике дистә елда Казан бик үзгәрде. Ул – чиста, матур шәһәр. Әлбәттә, архитектор буларак, миңа кайбер биналар әллә ни ошамый, ә тулаем алганда, аңа яхшы бәя бирергә була. Казанга заманча ямь кертә башлады.

Соңгы елларда ике зур бинага конкурс игълан итү генә дә бездә архитектура хәрәкәте барлыгына дәлил. Мәсәлән, Камал театры бинасына конкурс игълан ителгәч, билгеле шәхесләр, архитекторлар килде. Алар билгеләп үткәнчә, мондый конкурслар – Россия күләмендә дә сирәк күренеш. Булачак бина проектына конкурс игълан итү – Татарстанның абруен күтәрә торган гамәл. Әйтик, совет заманында бернинди конкурс булмады. Нәтиҗәдә ул чорда төзелгән корылмаларның, мәсәлән, «Татарстан» кунакханәсенең (бәлки заманында алдынгы булып күренгәндер инде) бер матурлыгы да юк. Алар шәһәр йөзен бизәми. Ә архитектура ул сокландырырга, мәгълүмат бирергә һәм горурлык хисе уятырга тиеш. Яхшы архитектура үрнәге шул калада яшәүчеләрнең абруен бермә-бер күтәрә. Чит ил кешеләре архитектура буенча монда яшәүчеләргә бәя бирә. Хәтерләсәгез, «Чудо России» дигән конкурс булды. Анда эләккән объектлар арасында Кол Шәриф бердәнбер заманча корылма иде. Миңа калса, бу күп нәрсә турында сөйли.

:: Шәһәргә тагын да ямь бирәчәк бина – җәмигъ мәчет. Аның турында иң беренче хәбәр чыккач, сайланган урыны иң күп бәхәсне уятты. Сезнеңчә, җәмигъ мәчетнең урыны дөрес сайланганмы?

– Мин баштан ук мәчет Казансу елгасы буенда урнашырга тиеш дип әйткән идем. Аны «Гаилә» үзәге белән «Ривьера» күңел ачу үзәге арасында дип күзалладым. Урыны азрак үзгәртелде, әмма ул барыбер су буенда, Казан кирмәне каршында тәгаенләнде. Ниятебез чынга ашса, елганың бер ягында – кирмән, Сөембикә манарасы, җыеп әйткәндә, тарихыбыз. Елганың уң ягында соңгы елларда үсеш алган яңа шәһәрнең символы булып җәмигъ мәчет торачак.

Ни өчен су буенда, дисәгез, су – шәһәр төзелешенә зур йогынты ясаган факторларның берсе. Кол Шәриф мәчете калкулыкта урнашкан. Бу урын мәчетнең тәэсир итү көчен бермә-бер арттыра. Елга да шулай ук тәэсир итә. Бинаның су өстендәге шәүләсе аның әһәмиятен дистәләрчә мәртәбә көчәйтәчәк. Читтә салынган булса, нинди генә проект ясама, ул югалып калыр иде.

:: Сезнең проект башкалардан образлылыгы, фәлсәфиләге белән аерылып тора. Нух пәйгамбәр көймәсе дип аталгач, сез аңа коткаручы дигән мәгънәне салдыгызмы?

– Без бик катлаулы заманда яшибез. Һәр кеше сайлау алдында: телиме ул көймәгә утырырга, әллә башка юлны сайлыймы? Күңелең пакь булса, тормышыңны Аллаһы Тәгалә кагыйдәләре белән алып барырга теләсәң, көймәгә утырырга кирәк дигән фикер белән ясадым мин бу мәчетне. Бу идея кинәт килеп чыкты. Мөгаен, хәзерге тормышның хәле тәэсир иткәндер. Әгәр дә бу конкурс берничә ел элегрәк үткән булса, бәлкем андый идея тумаган да булыр иде.

:: Сезнең идеяне аңладылармы соң?

– Аңладылар дип уйлыйм. Беренче урын бирүләре шуңа дәлил. Минем әле тагын бер проект бар иде, анысы «Лалә чәчәге» дип атала. Анысы чын татар архитектурасы, традицион формада ясалган. Ә менә монысы – заманча гына түгел, киләчәктә булачак архитектура үрнәге. Минем Каһирәдә, Италия, Израильдә таныш архитекторларым бар. Аларның фикеренчә, бу – ислам дине архитектурасында яңа сүз.

Әлбәттә, аңламаучылар да булачак. Зур әйберне тулаем күрер өчен ераккa китеп кара, дигән акыл иясе. Бу корылмага чын бәяне киләчәктә бирәчәкләр.

:: Проектның киләчәген ничек күрәсез? Мәгълүм булганча, конкурста ике проект җиңде. Аларны берләштерәләрме, ике проект нигезендә яңасын эшләячәкләрме?

– Бу конкурс эшенә тотынганда, Алладан ярдәм сорадым. Хәзер инде алга таба тормышка ашыруда ярдәм сорыйм. Насыйп булса, төзелер.

Мин инде хәзер дистәдән артык мәчетнең проект авторы. Аларның һәрберсенең – үз язмышы. Кайсына гына алынсам да, үзенчәлекле булсын дигән максат куям. Шуңа күрә, кайсының яныннан үтеп китсәм дә, миңа оят түгел. Эшкә алынгач, үзеңә дә, балаларыңа да, оныкларыңа да оят булмаслык итеп эшләргә кирәк. Әлегә конкурска йомгак ясалды, алга таба нәрсә буласы билгеле түгел.

:: Булачак мәчетнең эчке төзелешен дә күзаллыйк әле.

– Аның җир асты катында 1600 машина сыйдырышлы машина куяу урыны булачак. Парковка өстендә хәләл кулланучылар өчен мәйдан. Анда кибетләр, медицина үзәге, никах үзәге, банкет залы, кафелар урнашачак. Монда тормыш кайнап торыр дип күзаллыйм. Ә инде өстәрәк ун мең кеше сыйдырышлы мәчет урнашачак. Мондый алымны күп илләрдә кулланалар. Чөнки мәчетне нинди дә булса акчага тотарга да кирәк. Аренда хакы бу җәһәттән бик зур ярдәм булачак.

:: Сезнең визит карточкагыз – Кол Шәриф мәчете. Җәмигъ мәчет төзелгәч, Кол Шәриф икенче планда калырмы?

– Һәр нәрсәнең үз урыны бар. Шуңа күрә Кол Шәриф мәчете икенче планда калмаячак. Әлеге мәчет – Казан кирмәнендә тарихи гаделлекне торгызыр өчен төзелгән корылма. Ул тарихи комплексның йөзек кашы булып тора. Яңа мәчетнең исә үз роле бар, ул – киләчәк мәчете. Кол Шәриф тарихны күрсәтсә, яңа мәчет – татар милләтенең киләчәгенә ишарә. Аңа татар милләте юкка чыкмас дигән фикер салынган.

:: Әле бит Казанда мәчетләр күбәйде дип шикаять итүчеләр дә бар.

– Архитектор буларак болай җавап бирәм. Әйтик, Каһирә шәһәрендә мең мәчет бар. Аны мең мәчет шәһәре дип тә йөртәләр. Бу биналар шәһәргә шулкадәр ямь кертә, аны әйтеп аңлатырлык түгел. Европа шәһәрләрен исә чиркәүләр бизи. Ничек кенә алсак та, калага дини корылмалар ямь кертә. Шәһәр йөзенең төп билгеләре алар. Бездә мәчетләр Казанның татар каласы булуына ишарәли.

:: Сез бик зур хезмәт башкардыгыз. Бу көннәрдә игътибар арттымы?

– Әгәр шул юлны сайлагансың икән, каршылыкларга да, битарафлыкка да әзер булырга кирәк, минемчә. Заманасы да үзенчәлекле. Хәзерге буын – кулланучылар буыны. Сәнгать тә шуңа күрә малярлар дәрәҗәсенә төшеп бетте. Ул бөтен чорда да булган.

Көймә темасына кучик... Флоренциядә Изге Мәрьям соборы (La Cattedrale di Santa Maria del Fiore) бар. Аны төзегәннәр дә, гөмбәз корырга вакыт җиткәч, булдыра алмаячакларын аңлаганнар. Шулай итеп бу бина 100 ел гөмбәзсез басып торган. Шуннан беркемгә дә билгеле булмаган Филиппо Брунеллески килеп чыга һәм гөмбәзне ясап бирәм дип ышандыра. Ясап бирә дә, әмма билгесез яшь кешенең эшен кабул итәргә теләмиләр. Таныган архитекторлар бу эшне булдыра алмагач, дистә елдан соң аны кабат чакырып алалар һәм ярдәм итүен үтенәләр. Җәмгыять иҗат кешесенең ниятен кабул итмәскә дә мөмкин. Аның өчен вакыт кирәк. Флоренциядә бит әнә Брунеллески гөмбәзенә өлгергәнче күпме вакыт кирәк булган. Өлгереп җитеп, эшләргә юл ачылгач, шул гөмбәздән ренессанс мәдәнияте башланып киткән. Мин татар халкының зирәклегенә өметләнәм. Тарихчы Альфред Бостанов бу уңайдан, безгә Грозный яки башка шәһәрләрдәге мәчетләрне сыйдырышлыгы, байлыгы белән уздырырга кирәкми, ул интеллект белән алдырырга тиеш, дип язган иде. Әгәр дә Нух пәйгамбәр көймәсе идеясе чынга ашса, ул ислам архитектурасы Мәккәсенә әвереләчәк. Мин шулай тоям.

Соңгы мисал. Гарәп Әмирлекләре. Кайчан гына ул чүл, бәдәвиләр иле булса, нефть ачканнан соң анда нинди шәһәрләр, күккә ашкан биналар калкып чыкты! Әмма ул гарәп мәдәниятеме соң? Башка илләрнең әзер проектлары, кызганыч, гарәпләр турында бернинди мәгълүмат бирми. Менә шул хатаны кабатларга ярамый.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Җиңеп чыккан ике проект белән ни рәвешле эш алып барылачак? Без бу сорауны «Игелек – Доброта» фонды җитәкчесе Илнур Рәхимовка юлладык. Фондның матбугат хезмәте юллаган җавапта мондый юллар бар: «Хәзерге вакытта ике проект та –Проект институты карамагында. Алар технологик детальләрне, бәясен, эш күләмен һәм башка мәсьәләләрне ачыклый. Төзелеш эшләре быел ук башланыр дип көтелә».

18 июль | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР» 6+
10.00, 22.50 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.00 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Ком сәгате» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Әдәби хәзинә» 6+
19.00, 20.00, 01.05 «Таяну ноктасы» 16+
23.50 «Семь дней +». Искандер Гилязов 12+
00.15 «Каравай». Народная игрушка 6+
00.40 «Семь дней +». Роза Адиятуллина 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40 «Башваткыч» 12+
09.50 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
11.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Нәҗибә Ихсанова турында телеочерк 6+
15.00 «Яңалыклар» 12+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Яңалыклар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Яңалыклар» 12+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
23.05 «Башваткыч» 12+
00.00 «Яңалыклар» 12+
00.40 «Таяну ноктасы» 16+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
04.15 «Башваткыч» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Телеканал «Доброе утро»
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.35 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Елена Панова в многосерийном фильме «СПРОСИТЕ МЕДСЕСТРУ» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 «Соломон Волков. Диалоги с Евгением Евтушенко» 12+
00.50 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер» 12+
23.55 XXXI Международный фестиваль «Славянский базар в Витебске»
01.40 Ольга Иванова, Никита Тезин, Алика Смехова, Юрий Батурин, Сергей Селин. «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ. СУДЬБА» 12+
03.20 «ЖЕНЩИНЫ НА ГРАНИ» 16+

МАТЧ ТВ
11.00, 12.35, 14.55, 16.55, 19.00 Новости
11.10, 12.40, 02.40 Специальный репортаж 12+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00, 15.00 «ПОБЕГ» 16+
15.55 Футбол. Российская Премьер-лига. Обзор 0+
17.00 «Громко». Прямой эфир
18.00, 19.05 «ИНФЕРНО» 16+
19.55 Футбол. «МЕЛБЕТ – Первая Лига». «Алания Владикавказ» – «Динамо» (Махачкала). Прямая трансляция.
21.55 Футбол. Чемпионат Европы-2022. Женщины. Прямая трансляция из Великобритании
00.00 Все на Матч! Прямой эфир
00.45 «РИНГ» 16+
03.00 Новости 0+
03.05 «Наши иностранцы» 12+
03.35 «Третий тайм» 12+
04.00 Профессиональный бокс. Эдуард Трояновский против Рустема Меметова. Трансляция из Москвы 16+
05.10 «Громко» 12+

НТВ
04.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня»
08.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» (S) 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+
16.50 «За гранью» (S) 16+
17.55 «ДНК» (S) 16+
19.50 «ПЕНСИЛЬВАНИЯ» (S) 16+
21.45»ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ» (S) 16+
00.00 «ПЁС» (S) 16+
01.55 «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «6 кадров» 16+
07.15 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.15 «Давай разведёмся!» 16+
10.15 «Тест на отцовство» 16+
12.25 «Понять. Простить» 16+
13.30 «Порча». «Неразлучники» 16+
14.00 «Знахарка» 16+
14.35 «Верну любимого» 16+
15.10 «КЛЕВЕР ЖЕЛАНИЙ» 16+
19.00 «САШИНО ДЕЛО» 16+
22.40 «Порча» 16+
23.15 «Знахарка» 16+
23.45 «Верну любимого» 16+
00.20 «Понять. Простить» 16+
01.10 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 1-я и 2-я серии 16+
02.50 «Тест на отцовство» 16+
04.30 «Давай разведёмся!» 16+
05.20 «6 кадров» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
05.05 «УЧАСТОК ЛЕЙТЕНАНТА КАЧУРЫ» 16+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 13.25, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
09.55 «ОТРЯД СПЕЦИАЛЬНОГО НАЗНАЧЕНИЯ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 16+
14.00 Военные новости 16+
14.10 «КОГДА РАСТАЯЛ СНЕГ» 16+
18.50 «Битва ставок». Документальный сериал. «Смена стратегий» 16+
19.40 «Загадки века». Док. сериал. «Моряк невидимого фронта» 12+
22.55 «БЕРЕМ ВСЕ НА СЕБЯ» 12+
00.20 «СТАРШИНА» 12+
01.45 «СЛЕД В ОКЕАНЕ» 12+
03.05 «НЕ ХЛЕБОМ ЕДИНЫМ» 16+
05.15 «Оружие Победы». Док. сериал 12+

19 июль | Сишәмбе

ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 01.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!»12+
09.00, 17.00 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР» 6+
10.00, 22.50 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ» 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.00 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Родная земля» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего…» 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «Без химии». Док. фильм 12+
21.00 «Ватандашлар» 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Самый счастливый. Асгат Галимзянов 12+
00.40 «Каравай». Золотые руки мастеров 6+
01.05 «Уроки истории». Татары в составе русского государства 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Родная земля» 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Мансур Гыйләҗев турында телеочерк 6+
15.00 «Яңалыклар» 12+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Яңалыклар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
21.00 «Яңалыклар» 12+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
00.00 «Яңалыклар» 12+
00.40 «Таяну ноктасы» 16+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Телеканал «Доброе утро»
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.35 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «СПРОСИТЕ МЕДСЕСТРУ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 «Соломон Волков. Диалоги с Евгением Евтушенко» 12+
00.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер» 12+
23.55 Торжественная церемония закрытия XXXI Международного фестиваля «Славянский базар в Витебске».
01.10 Ольга Иванова, Никита Тезин. «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ. СУДЬБА» 12+
02.55 Александр Бухаров, Елена Полякова, Денис Синявский. «ЖЕНЩИНЫ НА ГРАНИ» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 09.10, 12.35, 14.55, 16.55, 18.50, 21.55 Новости
06.05, 22.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.15, 12.40, 02.40 Специальный репортаж 12+
09.35, 00.45 «ФАНТОМ» 12+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00, 15.00 «ПОБЕГ» 16+
15.55, 17.00 «КРОВАВЫЙ АЛМАЗ» 16+
18.55 Регби. Чемпионат России. «Динамо» (Москва) – «Енисей-СТМ» (Красноярск). Прямая трансляция
20.55, 04.00 Автоспорт. Ралли-рейд «Шёлковый путь» 0+
22.45 Смешанные единоборства. UFC. Брайэн Ортега против Яира Родригеза. Трансляция из США 16+
23.45 Футбол. Российская Премьер-лига. Обзор 0+
03.00 Новости 0+
03.05 «Правила игры» 12+
03.35 «Второе дыхание. Вячеслав Фетисов» 12+
04.55 «Лев Яшин – номер один». Док. фильм 0+

НТВ
04.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» (S) 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+
16.50 «За гранью» (S) 16+
17.55 «ДНК» (S) 16+
19.50 «ПЕНСИЛЬВАНИЯ» (S) 16+
21.45 «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ» (S) 16+
00.00 «ПЁС» (S) 16+
01.55 «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.10 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Возвращение» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55 «ВЕНЕЦ ТВОРЕНИЯ» 16+
19.00 «ЗДРАВСТВУЙ, ПАПА!» 16+
22.45 «Порча» 16+
23.20 «Знахарка» 16+
23.50 «Верну любимого» 16+
00.25 «Понять. Простить» 16+
01.15 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 3-я и 4-я серии 16+
02.55 «Тест на отцовство» 16+
04.35 «Давай разведёмся!» 16+
05.25 «6 кадров» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
05.30 «КОГДА РАСТАЯЛ СНЕГ» 16+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 13.25, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
09.55 «ОТРЯД СПЕЦИАЛЬНОГО НАЗНАЧЕНИЯ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 16+
14.00 Военные новости 16+
14.10 «КОГДА РАСТАЯЛ СНЕГ» 16+
18.50 «Битва ставок». Документальный сериал. «Война на южном фланге» 16+
19.40 «Улика из прошлого». «Содом и Гоморра. Тайна греховной гибели» 16+
22.55 «В ПОЛОСЕ ПРИБОЯ» 12+
00.30 «МИГ УДАЧИ» 12+
01.35 «ПОСЛЕДНИЙ ПОБЕГ» 12+
03.05 «СЛЕД В ОКЕАНЕ» 12+
04.25 «Морской дозор». Док. фильм 12+
05.15 «Оружие Победы». Док. сериал 12+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 18–24 июль

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Атна башында мәхәббәт мәсьәләсендә башыгыз әйләнеп, ялгышлык ясап куюыгыз бар. Шуңа күрә, бигрәк тә гаиләле кешеләргә җаваплырак булырга кирәк.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Ыгы-зыгылы атна. Акча эшләү ысулын үзгәртү турында уйланырга сәбәп чыгар. Зирәклек шактый гына четерекле бер мәсьәләнең очына чыгарга ярдәм итәр.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Тормышка фәлсәфирәк карасагыз, түземлерәк булсагыз, мәңге барып чыкмас кебек тоелган планнарыгыз да тормышка ашачак!

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Эштәге тегенди-мондый үзгәрешләр сезгә тамчы да зыян китермәячәк. Ул гынамы: әйбәт хезмәт хакына өмет-ышанычлар да уятачак әле!

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Җиренә җиткереп, тырышып эшләвегезнең матур гына җимешләре күренә башлар. Абруегыз да үсеп китәр: тирәгездәгеләр үзегездән киңәш сорый башлар.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Катлаулырак атна. Иң элек үз көчегез һәм мөмкинлекләрегезгә таянырга кирәк булачак. Әмма барыбер барысы да сез теләгәнчә бик әйбәт килеп чыгачак.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Уңышлы, табышлы чор. Бүләкләргә, премиягә исәп тотарга мөмкин. Эшегездә җитәкчегез белән уртак тел табу искиткеч әйбәт төгәлләнер.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Бу атнада, килеп туган хәлне бик тиз аңлап алып, күз ачып йомганчы тиешле карарга килү осталыгы кирәк булыр. Сезнең кулдан киләчәк ул!

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Бик керемле яңа эш башлап җибәрү мөмкинлеге ачылыр. Бер туганыгыз матур гына яңалыклары белән куандырыр.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Баш күтәрми эшләү генә түгел, тиешенчә ял итә белү дә кирәк. Җәй тиз уза, һәр көненең кадерен белеп калыгыз.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Атна башында кайбер каршылыклар барлыкка килергә мөмкин. Әмма алар, энергиягезгә каршы тора алмыйча, бер-бер артлы юкка чыгачак.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Карьерагызда бик җаваплы чор. Сәламәтлеккә бәйле борчулар узганда калыр. Бердәнберегез белән мөнәсәбәтләр дә, ниһаять, җылыныр.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Россия Казначылыгы эшчәнлеген тәэмин итү үзәге» федераль казна учреждениесенең Казан шәһәрендәге төбәкара филиалы башлыгы **Хөсәенова** Әминә Сәүдәхан кызы; республикада мәгълүмат технологияләрен үстерүгә һәм камилләштерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «БАРС Груп» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Әхмәров** Тимур Марат улы; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Звениговский» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы рәисе **Казанков** Иван Иванович; Татарстан Республикасының төбәкара һәм халыкара элемтәләрен үстерүгә зур өлеш кертүе, дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Президентының Тышкы элемтәләр департаменты халыкара хезмәттәшлек бүлеге мөдире **Насыров** Илдар Рустамбек улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы башлыгы урынбасары **Билалов** Рәшит Әбрар улы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«Әлки район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе сәнгать җитәкчесе **Емельшина** Людмила Геннадьевнага, «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесенең Урта Тигәнәле авылы мәдәният йорты режиссеры **Миңнебаева** Рәисә Харис кызына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе сәнгать җитәкчесе **Сәлахетдинова** Римма Егоровнага, «Хөснулла һәм Аллаһияр Вәлиуллиннар исемендәге Саба балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү мәгариф учреждениесенең баян классы һәм теория буенча укытучысы **Фатыйхова** Раилә Габделгазиз кызына **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең «Казан эпидемиология һәм микробиология фәнни-тикшеренү институты» федераль бюджет фәнни учреждениесе директорының инновацияле үсеш буенча урынбасары, микробиология лабораториясе табиб-бактериологы **Исаева** Гүзәл Шәүкәт кызына, «Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча медицина-санитария часте» федераль казна сәламәтлек саклау учреждениесе поликлиникасы (Казан шәһәрендә урнашкан) стоматология кабинеты табибы – стоматолог-терапевты **Кашшапова** Лалә Мөстәкыйм кызына, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе поликлиникасы мөдире – гомуми практика табибы **Малыгина** Надежда Михайловнага, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор М.З. Сигал исемендәге Республика онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 11 номерлы онкология бүлекчәсе мөдире – табиб-онкологы **Рувинский** Давид Марковичка, «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең онкология бүлекчәсе табиб-онкологы **Суслова** Людмила Викторовнага, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең медицина-санитария часте стоматология бүлекчәсе табибы – стоматолог-ортопеды **Тимриева** Хәлимә Хәниф кызына, «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы «Балкыш» санаторий-профилакторие директоры **Хисаметдинов** Альберт Филүс улына, «Балтач үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының халыкка медицина хезмәте күрсәтү буенча урынбасары **Шәфигуллин** Рәшит Кәлимулла улына **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КИМЕРҮЧЕ «БҮЛӘГЕ»

Җәйнең кыл уртасына җиттек. Эшнең дә, ялның да иң кызган мәле. Шушы чорда тычкан бизгәге дә котыра, дип кисәтә белгечләр. Күпләр әлеге авыруны урманга ял итәргә, җиләк, гөмбә җыярга баргач яки бакчада йоктыра. Бу чир нәрсәсе белән куркыныч? Ул ничек күчә? Тычкан бизгәгеннән ничек сакланырга?

Табиб-инфекционист Илсөя ЗАҺИРОВА шул сорауларыбызга ачыклык кертте.

:: Тычкан бизгәге кешегә ничек күчә?

– Тычкан бизгәге, икенче төрле әйтсәк, геморрагик бизгәк – кискен вируслы инфекцияле авыру. Аны кимерүчеләр, нигездә, тычканнар тарата. Алар үзләренең төкереге, бәвеле, нәҗесе аша чирне туфракка, суга, ашау ризыкларына йоктыра. Тычкан бизгәге, нигездә, кеше организмына һава, тузан аша эләгә. Юылмаган пычрак кул белән ашау, бакчадан юылмаган яшелчә һәм җиләк-җимеш өзеп кабу, авыру таратучы җәнлеккә кагылу, калган азык-төлекне термик яктан эшкәртмичә ашау аркасында кешене аяктан ега ала. Геморрагик бизгәк тәндәге яраланган, җәрәхәтләнгән урыннар, тычканнар хуҗа булган салам, печәнгә кагылып киту аркасында да пәйда булырга мөмкин.

:: Бу чир бигрәк тә кайсы ел фасылын «ярата»?

– Тычкан бизгәге безне ел дәвамында сагалый. Аны елның фәлән фасылында гына йога ала дип әйтү дөрес түгел. Әмма геморрагик бизгәкнең иң котырган чоры җәйге-көзге чорга туры килә. Кеше аны, нигездә, авыл хуҗалыгы, урман эшләре вакытында, бакчада, урман-кырларда җиләк, гөмбә җыйганда, табигатьтә ял иткәндә йоктыра.

:: Бу чорда кемнәргә аеруча игътибарлы булырга кирәк?

– Бөер авыруларыннан интеккән, авыл хуҗалыгы, сәнәгать тармакларында эшләгән кешеләргә, бигрәк тә тракторчы, машина йөртүче кешеләргә. Ник дигәндә, тычкан бизгәген, иң беренче чиратта, нәкъ менә алар йоктыра.

:: Тычкан бизгәген йоктыруыңны нинди билгеләр буенча чамаларга мөмкин?

– Аның беренче билгеләре салкын тиюгә охшаш: 39–40 градуска кадәр температура күтәрелә, калтырата, туңдыра башлый. Кешене ютәл, баш авырту, буыннар сызлау кебек билгеләр дә борчырга мөмкин. Тычкан бизгәге йоктырган кеше авыз кибүдән дә зарлана. Андый чакта еш кына бит һәм муен кызара, тәнгә, бигрәк тә җилкә, күкрәк турысында таплар пәйда була. Тычкан бизгәге вакытында кешенең күзенә кан саварга, биле сызларга, кан басымы төшәргә дә мөмкин. Кече йомыш белән сирәк йөри башлау да – бу чиргә хас үзгә билгеләрнең берсе. Әмма иң куркынычы шул – тычканнардан, күселәрдән йоккан вирус инфекциясе кешенең бәвел системасына зыян сала. Бу исә, үз чиратында, бөерләрнең эшчәнлеген боза. Чир үзен, гадәттә, вирусны йоктырганнан соң 7–25 көн үткәч кенә сиздерә башлый. Кайбер очракларда ул 40 көннән соң гына пәйда була.

:: Тычкан бизгәге кешедән кешегә йога аламы?

– Юк, йога алмый. Шуңа күрә тычкан бизгәге эләктергән кешеләрне куркынычсыз стационарда – инфекция, терапия һәм хирургия бүлекләрендә дәваларга мөмкин. Әлеге чир белән бер тапкыр авырган кешедә гомерлек иммунитет формалаша. Аны кабат йоктыру ихтималы юк дәрәҗәсендә.

pixabay.com

ТЫЧКАН БИЗГӘГЕННӘН САКЛАНУ ӨЧЕН ТАБИБ КИҢӘШЛӘРЕ

➤Урманнарга барганда шәхси гигиена кагыйдәләрен истән чыгармагыз. Ашыйсы ризыкны, ул салыначак савыт-сабаны үләнгә, агач төпләренә куярга ярамый. Моның өчен үзегез белән махсус җәймә яки клеенка алып барыгыз.

➤Бакчага барып яшәр алдыннан андагы өйне иң элек яхшылап юып, махсус чаралар ярдәмендә дезинфекцияләп чыгарга кирәк.

➤Бакчада эшләгәндә, йорт, каралты-кура, сарай, гараж кебек урыннарны җыештырганда резин пирчәткә киярге онытмагыз. Андый эшләр вакытында аягөсте ашарга, авызга ризык кабарга да киңәш ителми. Бу кагыйдәне салам, печән өйгәндә, агач эшкәрткәндә, бакчада яшелчә, җиләк-җимеш җыйганда да истән чыгармагыз.

➤Бакчада, каралты-курада чүп җыеп яткырмагыз.

➤Йортка тычкан керә алырлык тишек-тошыкларны да томаларга кирәк.

➤Азык-төлекне дә кимерүчеләр үтеп керә алмаслык җирдә сакларга, ашар алдыннан аларны яхшылап юарга кирәк. Суны исә кайнатып эчү хәерле.

➤Табигатькә чыкканда, куаклар үсмәгән, коры җирдә тукталырга кирәк. Җәен печәнлек, салам эскертендә йоклау да киңәш ителми.

:: Авыру нәрсәсе белән куркыныч?

– Вакытында чарасын күрмәсәң, тычкан бизгәге аркасында кешенең каны агуланырга (сепсис), үпкәсе кабарырга, башына кан саварга, бөере эштән чыгарга мөмкин. Кызганыч, бу бизгәк үлем-китем очракларына китергән мисаллар да күп. Шуңа күрә чирнең беренче билгеләре күренү белән үк табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Тычканнарга ялгыш кына орынган очракта да шикләнергә җирлек бар.

Сорау – җавап

Борыны ник каный икән?

? Яшүсмер улымның әледән-әле борыны каный. Сәламәтлегеннән дә зарланмый. Борыны канаганда, мамык тыгып, чалкан ятып тора да шуның белән үтеп китә үзе. Шулай да күңелем барыбер тыныч түгел. Баламның борыны ник каный икән?

Алсу ВӘЛИЕВА. Казан

Сорауга гомуми практика табибы Фирая Ахунова җавап бирә:

– Иң элек улыгызның кан басымын тикшертегез. Кан басымы югары булган очракта борын канау, киресенчә, кешенең хәлен җиңеләйтеп кенә җибәрә. Моннан куркырга кирәкми. Борын канаганда мендәр өстенә мендәр куеп, балагызны кырынрак яткырыгыз. Башына аз гына су бөркеп яки юеш тастымал куеп, борын тишекләрен ике бармак белән 10 минутлап кысып тору ярдәм итәчәк. Әгәр дә кан килү тукталмаса, борын тишекләренә мамык куегыз. Аннан да тукталмаса, табиб чакыртырга кирәк.

Үкчәң тәртиптәме?

Җәйге чорда үкчәләребез аеруча игътибарга мохтаҗ. Үкчә тиресе еш кына тупаслана – корый һәм кытыршылана, кубалакланып ярыла башлый. Аны түбәндәге ысуллар ярдәмендә йомшартырга мөмкин:

✱1 стакан сыек сабынга яки душ геленә тоз салып бутагыз да сулы табакка салыгыз. Аякларны шунда ярты сәгать тотыгыз;

✱1 табак суга 1–2 аш кашыгы алма серкәсе яки лимон кислотасы салыгыз. Аякларны бу катнашмага 10–15 минутка тыгып торыгыз;

✱5әр кашык ромашка, шалфей, 3 кашык сары мәтрүшкәне бутарга, шуңа 1,5 литр кайнап торган су өстәргә кирәк. 10 минуттан катнашманы кайнар су салынган табакка бушатыгыз. Аякларны шунда 20–30 минут тотыгыз.

Мондый процедуралардан соң үкчә тиресен махсус щетка яки пемза белән ышкып, скраб белән дә чистартырга онытмагыз. Скрабны үзлегеңнән дә ясарга мөмкин. Моның өчен әфлисун кабыгын ваклап, зәйтүн мае өстәп бутагыз да үкчәләргә сөртегез. 20 минуттан юып төшергәч, үкчә тиресенең йомшарып, чистарып калганын күрерсез.

Киңәш-табыш

✓Ашказаны авыртканда берәр кашык кычыткан, бака яфрагы, сары мәтрүшкә, ромашка чәчәген 1 литр кайнар суда пешерергә һәм 2 сәгать җылы урында төнәтергә, 1әр стаканлап, көн буена литр ярым эчәргә.

✓Бер аш кашыгы коры мәтрүшкәгә 1 стакан кайнаган су коеп, ут өстендә кайнатып чыгарырга, аннан тагы 10–15 минут сүрән утта тотарга кирәк. Соңыннан суытып, сөзеп куела. Бу кайнатманы йокысызлыктан интеккәндә кулланырга була. Ул вакытта бер чирек стакан мәтрүшкә төнәтмәсенә бер чәй кашыгы бал салып эчү киңәш ителә. Депрессия, хәлсезлек вакытында, арыганлыкны бетерү өчен дә мәтрүшкә кулланырга була. Гади заварка чәйнегенә 1 чәй калагы мәтрүшкә, 2–3 чәй калагы яшел чәй салырга кирәк. Еш көйсезләнә торган балаларга да мәтрүшкә салып төнәтелгән чәй бирәләр.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

ИЮЛЬ – МӨМКИНЛЕКЛӘР АЕ

ҖӘЙГЕ ТУКЛАНУ СЕРЛӘРЕ

pixabay.com

Эсседә аппетит югала. Ә бу көч-энергияне суыра, тормыш ямен тоймый башлауга китерә. Шуңа күрә җәй көннәрендә ашау-эчү, тормыш итү рәвешен бераз үзгәртергә туры килә. Җәй файдалы узсын өчен, сәламәтлегебездә, буй-сыныбызда уңай чагылыш тапсын өчен нишләргә, ничек тукланырга? Белгечләр бу җәһәттән түбәндәге киңәшләрне тәкъдим итә.

Көч җыябыз

Җәй – бөтен дөнья чәчәктә утырган, хуш исләргә күмелгән чор. Нәкъ менә шушы вакытта яшелчә һәм җиләк-җимешләрнең күпчелеге сәламәтлек өчен аеруча файдалы. Шуңа күрә иммунитетны иң гади юсул белән ныгытып, ел буенча җитәрлек витаминнар туплап калырга кирәк.

Җәен авыр эшкәртелә торган ризык бик бармый. Шуңа күрә белгечләр тамак та туйсын, витамин-минерал запасы да туплансын, шул ук вакытта организмда җиңеллек тә булсын өчен тәмле салатлар әзерләргә киңәш итә. Яшелчәгә тавык ите, диңгез продуктлары, чикләвек, җиләк-җимеш һәм, әлбәттә инде, яшел тәмләткечләр кушыгыз. Ә менә туңдырма һәм салкын эчемлекләрне саклык белән генә кулланырга тырышыгыз. Эсседә суык ризык шундук тамакка бәреп, салкын тидерергә мөмкин. Җәйге матур көннәрдә ике атна буе баш күтәрми чирләп ятуны, кем әйтмешли, дошманыңа да теләмәссең... Эчемлекләргә килгәндә, сусауны басу өчен салкыны түгел, ә кайнары кирәк. Бу максатта яшел чәй бик файдалы. Аны җылы килеш тә, суытып та эчәргә була. Икесе дә сусаудан бик әйбәт коткара һәм тән температурасын төшерә.

Кыяр, алма, ташкабак...

Июль – файдалы һәм «дөрес» ашау өчен бөтен мөмкинлекләр тудырылган ай. Бакчалар, кибет киштәләре яшелчә, җиләк-җимешләр белән тулган чак. Шулардан әзерләнгән төрле ризыклар табыннан өзелмәсен. Организмны шлаклар һәм токсиннардан чистарта алар. Бигрәк тә составында суы күп булганнарына өстенлек бирегез. Әйтик, кыярга, ташкабак, алма, виноградка һ.б. Бәрәңге дә артык сыеклыкны чыгаруга ярдәм итә.

Җиләк-җимешнең файдасына зыян китермәс өчен тоз куллануны киметегез. Суны токтарлый чөнки. Бөер яки үт куыгында таш булган кешеләр аеруча сак булырга тиеш.

Эсседә кыздырылган, ысланган, майлы ризыктан баш тартырга тырышыгыз. Хәтта сау-сәламәт ашказаны өчен дә күтәрә алмаслык «йөк»кә әйләнергә мөмкин ул. Аннан килеп, суны күбрәк эчегез. Җәйге эсседә кешегә тәүлегенә 1,5–2 литр чиста су эчәргә кирәк. Гадәтие күнелегезгә ошап җитмәсә, лимон, җиләк-җимеш салып эчегез. Мондый су тәмлерәк кенә түгел, файдалырак та булачак. Смузины да онытып җибәрмәгез. Моның өчен сөт, йогырт яки табигый сокка яшелчә, җиләк-җимеш салып, блендерда болгатып кына аласы. Моның ашау арасында эчү әйбәт.

Эссе көннәрдә һич югында кичке ашны ачык һавада ашарга тырышыгыз, дип киңәш итә белгечләр. Саф һавада ризык җиңелрәк үзләштерелә бит. Шуның бик мөһим: җәен иртәнге аштан баш тартырга ярамый! Ашасаң гына көч-дәрт керә, кәеф күтәрелеп китә. Иң әйбәте – ботка һәм йомырка ризыклары. Боткага җиләк-җимеш кисәкләре өстәгез, ә йомырка тәбәсен яшелчә белән әзерләгез.

Тәмле булсын!

ТАВЫК ИТЕ ҺӘМ ЯШЕЛЧӘДӘН ҖӘЙГЕ САЛАТ

Наилә ГЫЙЛӘҖЕВА рецепты

Кирәк булачак: 350 грамм тавык филесы, 5 черри помидоры, 1 кыяр, берәр бәйләм руккола, яфраклы салат, петрушка, базилик, 2 аш кашыгы лимон согы, 3 аш кашыгы зәйтүн мае (көнбагышныкы булса да ярый), 3 теш сарымсак, тоз, төелгән кара борыч, тавык ите өчен тәмләткечләр.

Ике теш сарымсакны изеп, тоз, борыч, тәмләткечләр өстәп болгатабыз. Иткә шушы катнашманы сылыйбыз. 15–20 минут тотканнан соң, фольгага төреп, газ мичендә (180 градус) 25–30 минут пешерәбез. Помидорларны юып, икегә бүләбез. Кыярны божралап (юкарак) турыйбыз. Яшел тәмләткечләрне юып, кул белән өзгәлибез һәм барысын да тирән эчле савытка тутырабыз. Яшелчә һәм тавык итен турап салабыз. Калган бер теш сарымсакны изәбез, шуңа май һәм лимон согы өстәп, «заправка» ясыйбыз. Салатка салып, барысын бергә болгатабыз.

vk.com

АВЫЛЧА САЛАТ

Зөлфия ӘХМӘТОВА рецепты

Кирәк булачак: 2 помидор, 1 кыяр, 1 башлы суган, 1 теш сарымсак, берәр бәйләм базилик, руккола, 2 аш кашыгы зәйтүн мае, 1 чәй кашыгы серкә (9 процентлы), ярты чәй кашыгы шикәр комы, төменчә тоз, борыч.

Яшелчә һәм яшел тәмләткечләрне юып, кәгазь сөлге белән корытабыз. Помидорларны дүрт өлешкә бүләбез. Кыяр (юкарак итеп), суганны божралап турыйбыз. Базилик һәм рукколаны кул белән өзгәлибез. Тирән эчле савытка барысын бергә салып, тоз һәм борыч өстәп болгатабыз. Аерым савытта сарымсактан (изеп), зәйтүн мае, серкә һәм шикәр комыннан «заправка» ясыйбыз. Шуны салатка салып болгатабыз. Искиткеч тәмле!

Сүз уңаеннан. Үсемлек маен бераз гына җылытып салсаң, салат аеруча тәмле булачак.

Укучы хатлары

Мамык мендәрне юам

Кош-корт мамыгыннан ясалган мендәрләремә 30 еллап чамасы инде. Әмма алар хәзер дә бик яхшы хәлдә. Сәбәбе – дөрес карауда. Мин аларны өч елга бер мәртәбә кер машинасында юам. Дөресрәге, сыгам.

Иң элек мамыгын ваннага бушатам. Кайнар су агызам. Кул белән яхшылап болгатып, кер югандай җиңелчә генә ышкыйм. Суын күп итеп, мамык йөзеп йөрерлек итеп тутырам. Мамыкны иске мендәр тышларына яки берәр нинди капчыкка (бер мендәр мамыгы өчен ике капчык кирәк) тутырам. Шуннан, машинага салып, ике-өч тапкыр 800 әйләнешкә «сыгу» режимына куеп алам. Капчык тышы кибәргә тиеш. Бары тик төерчекле урыннарда гына юеш таплар калырга мөмкин. Бу эш белән җәйге эссе көннәрдә мәш киләм. Мунчасы булган кеше моны елның теләсә кайсы фасылында эшли ала. Шуннан соң мамыклы капчыкларны кояшлы урынга (балконга, тәрәзә төбенә, урамга) куям. Әледән-әле капчыкны әйләндергәләп, селкеткәләп, мамык төерләрен таркаткалап торам. Учка алып кыскач, капчык тукымасын юешләтмәсә, мамык кипкән дигән сүз. Шуннан аны, үзенең тышына тутырып, тагын киптерергә куям. Почмакларында посып калган мамык төерләрен күпертеп-таркатып бетерәм. Бу эшкә якынча ике-өч көн вакыт кирәк.

Мендәр кибеп җитмәсә, беренче төндә үк сиздерә. Шулай икән, тагын кояшка! Юганнан соң мендәрләр йомшарып, җиңеләеп китә.

Тагын бер киңәш: мамык тутырганчы, мендәр тышын юып үтүкләргә һәм эчке ягына сабын яки балавыз сылап калдырырга кирәк. Болай эшләгәндә, аннан бер бөртек тә мамык чыкмаячак.

Әлфинур НӘҖМЕТДИНОВА.
Казан

Помидор чәй содасын ярата

Томат үсентеләрен инде менә ничә ел сода белән тукландырам. Аларга ул әйбәт үсәргә, тизрәк пешәргә ярдәм итә һәм помидорга искитмәле тәм кертә.

Моның өчен эремә ясап сибәргә кирәкми: һәр төп тирәсенә берәр уч сода сипсәм, шул җитә. Су сипкәндә, эреп, үсенте тамырларын туклaндырып торачак.

Альбина ЗӘЙНУЛЛИНА.
Биектау районы

Су сибүнең – үз җае

Суны дөрес сибү дә кәбестә уңышына зур йогынты ясый. Шуңа күрә бу эшкә бик җитди карыйм. Үсентене утыртканнан соң өч атна чамасы көн саен-ике көнгә бер сибәм. Үсеп китү өчен аларга күп көч кирәк чөнки. Һәр үсенте төбенә 2 литр чамасы кояшта торган су салып чыгам. Бер көнне төбенә сипсәм, икенче көнне «яңгыр яудырам». «Яңгыр»дан соң кәбестәгә агач көле бөркім (яфракларда озак тора). Үсентеләр ярып, көчәеп киткәч, су сибүне атнасына ике тапкырга гына калдырам. Әмма инде һәр төпкә өчәр литр сибәм.

Ә менә хәзер – кучан төрә башлагач, суны ешрак һәм мулрак сибәргә кирәк. Мин үзем кәбестәләрне бигрәк тә эссе көннәрдә көн саен диярлек суларга тырышам. Су җитмәсә, кучаннар ярыла башлый.

Сания ЯКИМОВА.
Балык Бистәсе

ИҢ ЗУР ШАТЛЫК – ДОГА

Укучыларыбызны бүген ниләр борчый? Алар нинди сорауга җавап таба алмый интегә? «Иман» сәхифәсенең бүгенге чыгарылышында укучыларыбыздан килгән хатларга җавап табарга булдык.

Аларга «Әл-Мәрҗани» мәчете имамы Ансар хәзрәт МИФТЯХОВ җавап бирә.

?Мин даими рәвештә кан тапшырам. Тапшырган саен моның өчен акча да бирәләр. Мөселманга акчага кан тапшырырга ярыймы икән?

Ризван ХӘКИМОВ. Казан

– Шәригать буенча мөселманга акчага кан тапшыру рөхсәт ителми. Ул аны Аллаһы ризалыгы өчен билгеле бер кешегә ярдәм йөзеннән, бушка тапшырса, берәр кешегә ярдәме тисен дигән ният белән кан тапшыру урынына барып тапшыра икән бу бик саваплы гамәл санала. Әмма моның өчен акча алырга ярамый. Кан – кеше әгъзасының бер өлеше. Ул аны сатарга тиеш түгел.

?Соңгы арада шуңа игътибар итәм. Авылда җиләк җыеп кайткан җирдән кайберәүләр якынының каберенә сабагы белән җыйган җиләк куеп китә. Читтән караганда бик сәер. Болай эшләргә ярыймы икән?

Мамадыштан ФИРАЯ апагыз

– Кабер өстенә ризыклар, ниндидер әчемлекләр кую рөхсәт ителми. Хәтта шушы зиратта, кабер тирәсендә үскән җиләк-җимешләрне дә алып ашау рөхсәт ителми. Кабер өстенә җиләк, чәчәкләр куюга килгәндә, бәлки, аны куйган кеше кабердәге кеше аларга шатланып ята дип уйлый торгандыр. Әмма бу дөрес түгел. Кабердәге кеше шатлансын өчен аның рухына атап дога кылырга кирәк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Бу дөньяда догачы балалары, туганнары, якыннары булса, мәрхүм-мәрхүмәләр шатланып ятарлар», – дигән. Шуңа күрә аларның рухларына дога кылу яисә кабер өстенә артык зур үсми торган куак яки чәчәкләр утырту хәерлерәк. Алар мәрхүмгә тәсбих әйтеп торачак.

?Берәр әйбереңне югалтсаң, «пәри, тап» дип әйтергә кушалар бездә. Әллә чынлап, әллә шулай туры килә – гадәттә теге әйбер күп тә үтми табыла. Югалган әйберне табу өчен мондый сүзләр әйтү гөнаһ түгелме? Бәлки, андый чакта укыла торган махсус дога бардыр?

Алсу САБИРОВА. Арча

– Ислам динендә «пәри, тап» дип әйтергә рөхсәт ителми. Бу – гөнаһ. Кеше шушы сүз белән диннән чыгарга мөмкин. Чөнки ул эшне Аллаһы Тәгаләгә түгел, пәригә тапшыра, аларны үзара тиңләштерә булып чыга. Шуңа күрә бу мәсьәләдә бик сак булырга кирәк. Әгәр адәм баласы берәр төрле әйберен югалтса, Аллаһы Тәгаләдән сораса яки салават укыса, хәерле. Иншаллаһ, Аллаһы Тәгалә аңа ярдәмен күрсәтер. Ә инде «пәри, тап» ише сүзләр әйтү, Аллаһы Тәгаләдән читләшеп, ниндидер юк-бар әйберләрдән ярдәм сорауга тиң һәм ул диннән чыгуга да китерә ала.

?Бер көнне ашта булырга туры килде. Мулла укып бетергәч, йорт хуҗалары сәдака өләшә башлады. Анары ашка килгән кешеләр дә, урыннарыннан кузгалып, хәер тараттылар. Ахырдан кемнең кемгә сәдака биргәнен-бирмәгәнен дә бутап бетерделәр. Сәдаканы син миңа бирмәдең әле, дип сорап алучылар да, ашка килмәгән туганы өчен сәдака сорап алучылар да булды. Сәдаканы сорап алу дөрес түгел бугай бит? Ашка килгән кеше дә сәдака өләшергә тиешме?

Мәүлидә ВАФИНА. Әлмәт

– Сәдака тарату – ихтыяри әйбер. Чын күңелдән, Аллаһ ризалыгы өчен эшләнә торган гамәл бу. Сәдаканы теге яки бу кеше генә таратырга тиеш дигән таләп юк. Әгәр адәм баласы хәер таратырга тели икән, ул аны кайчан тели, шул вакытта өләшә ала. Хәзрәт укып бетергәннән соң килгән кунаклар да, нигезнең хуҗалары да тарата ала. Ә инде кемгәдер сәдака эләкте, кемгәдер эләкмәдә диешүгә килгәндә, ул да кешенең үзеннән тора. Сәдаканы килгән бар кешегә бирәсеме, юкмы икәнен дә ул үзе хәл итә. Сәдаканы сорап алырга да ярамый. Хәтта пәйгамбәребез дә бер хәдисендә: «Үзегезгә хәерле булган әйберне сәдака итеп таратмыйча, җыелган мәҗлесегезнең әҗер-савабына ирешмәссез», – дигән. Тагын бер хәдисендә ул: «Мәҗлестә бер-берегезгә күчтәнәчләр, бүләкләр бирешегез, шушы күчтәнәч белән дуслыгыгызны, туганлыгыгызны якынайтыгыз, туганлык, дуслык җепләрен өзмәгез», – дигән.

Идар Мөхәммәтҗанов

?Апа белән сеңел бер елны никах укыта алалармы? Ике бертуганга бер елны өйләнешергә, кияүгә чыгарга ярамый, диләр, дөресме ул?

ЭЛЬВИРА Г. Апас

– Юк, бу сүзләр дөреслеккә туры килми. Әгәр теләге бар икән, бертуганнарга бер үк елны никах укытырга, өйләнергә, кияүгә чыгарга рөхсәт ителә. Моның бернинди дә зыяны юк. Аллаһы Тәгалә никах укыту өчен үзенең бер вакытын бирә. Шуңа күрә аларның яшьләре җиткән, тиң парлар тапканнар икән, никах укытып, гаилә төзесәләр, бу – хәерле, саваплы, дөрес, шәригатебезгә туры килгән гамәл. Монда бернинди каршылык юк.

?Әнинең үлемтеккә әзерләгән әйберләре кулланылмады. Хәзер аларны ни эшләтергә икән?

Ләйлә ГАРИПОВА. Минзәлә

– Әби-бабаларыбыз, әти-әниләребез элек-электән ахирәт дөньясына кәфенлек, сәдака сыман әйберләрне алдан җыеп, әзерләп, ахирәт дөньясына күчәргә әзерләнеп яшәгән. Без дә шулай эшләргә тиеш. Бу дөньяга кайчан килгәнебезне белмәгән сыман, аннан кайчан китәсебезне дә белмибез. Үлемтекләр файдаланылмаган очракта аларны, әйтик, таратырга дип әзерләп калдырылган акчаны мәрхүмнең ашында яки башка вакытта өләшсәгез дә була. Кулланылмаган кәфенлеккә килгәндә, аны мохтаҗ кешегә бирсәң дә хәерле. Аны алырга мөмкинлеге булмаган кешеләр дә бар бит. Беребез дә мәңгелеккә килмәгән. Якты дөньядан кайчан да бер китәсе. Шуңа күрә аны үзегезгә җыеп куйсагыз да була. Аны кемгәдер бүләк, күчтәнәч итеп бирүнең дә бер зыяны да юк. Алда телгә алынганнарның берсе дә күңеленә ятмаган кеше кулланылмаган кәфенлекне мәчеткә китерә ала. «Кәфенлек алырга да акчам, мөмкинлегем юк», – дип мәчеткә ярдәм сорап мөрәҗәгать итүчеләр дә бар бит. Кәфенлекне шуларга тапшырырга мөмкин.

?Мин банкта эшлим. Күптән түгел намазга бастым. Миңа хәзер эш урынымны алмаштырырга кирәк булачакмы?

Динар ВӘЛИЕВ. Казан

– Әйе, алыштырырга туры киләчәк. Сез хәләл банкка эшкә керә аласыз. Казанда «Амаль» дигән шундый хәләл банк бар. Белемегез, мөмкинлегегез булса, үзегезне башка өлкәләрдә дә сынап карый аласыз. Әмма процентка акча бирә торган банкларда эшләү шәригать кануннары буенча яшәүче мөселман кешесе өчен тыелган, гөнаһ гамәл санала.

pixabay.com

Бәхет үзеңнән башлана

Бер зирәк карт язгы табигатькә соклана-соклана урам буйлап бара икән. Шунда, җилкәсенә зур йөк асып, көч-хәл белән атлап барган бер ир-атка игътибар иткән ул.

– Нишләп бу кадәр азапланасың? – дип сораган ул аннан.

– Балаларым, оныкларым бәхетле булсын өчен тырышам. Карт бабам бабаем бәхетле булсын дип тырышкан, бабай – әти, әти минем өчен дип тырышып, тир түгеп яшәгән. Мин үз балаларым бәхетле булсын өчен тырышам, – дип җавап кайтарган ир.

– Ә аларның берәрсе үзе бәхетле булганмы соң? – дип янә сорау биргән карт.

– Әлегә юк, ләкин оныкларым, балаларым бәхетле булыр дип ышанам, – дигән ир-ат.

– Акыллы наданны укырга өйрәтә, сукыр тычкан лачынны тәрбияли алмаган кебек, балаларың бәхетле булсын өчен иң элек үзеңә бәхетле булырга кирәк! Синең аларга ясаган иң зур бүләгең шул булыр, – дигән зирәк карт.

Тәүбә догасы

«Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Әстәгъфируллаһә, Әстәгъфируллаһә, Әстәгъфирул-лаһә тәгәлә миң күлли зәмбин әзнәбетүһү гәмдәнәү хата ән сирран әү гәлә нийәтәү үә әтүбү иләйһи минәззәм-билләзи әгләмү үә минәззәмбил-ләзилә әгләмү иннәкә әнтә галләмүл гуйүбе».

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгаләдән мине һәрбер гөнаһларымнан ярлыкавын телимен, юри кылган гөнаһларымнан, хаталык белән кылган гөнаһларымнан да, яшерен кылган гөнаһларымнан да, әшкяра кылган гөнаһларымнан да тәүбә кыламын. Әй, Аллаһ, гаепләрне дә белүчесең».

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

ИЛДУС ДАВЛЯНОВ:
«БАШНЫ БЕРАЗ ЧИТКӘ ДӘ БОРЫРГА КИРӘК»

Бүгенге «Ни хәл?» сәхифәсенең кунагы – аранжировка ясау остасы, композитор, шактый хитлар авторы Илдус ДАВЛЯНОВ. Көн дә бер җыр иҗат итү – мөмкин хәлме? Заманча татар җырларының берсе икенчесенә охшавының сәбәбе нидә? Аранжировка ясаучылар арасында көндәшлек бармы? Без әнә шулар турында сөйләштек.

:: Ни хәл?
– Хәлләр яхшы. Ашауга карап инде (*көлә*). Әллә нинди зур яңалыкларым бар дип әйтә алмыйм. Эшлибез, көнтөн иҗат итәбез.

:: Музыка, аранжировкалар белән кайчан кызыксына башладыгыз?
– Мәктәптә укыган чакта, кирәкле көйне синтезаторда уйнап, дискка яздырып сата идем мин. Нота белү юк, тыңлап кына инде. Туңдырмалык акча булгач, мәктәп баласына тагын нәрсә кирәк? Шуннан бирле синтезатор кулымнан төшмәде. Студент чакта безгә «Музыкада компьютер технологияләре» дигән фән керде. Менә шунда башланды инде... Туган районымдагы мәдәният йортында, соңыннан Башкорт драма театрында эшләгәндә дә, төп эшем белән бергә, кечкенә генә тавыш яздыру студиям бар иде. Заказлар арткач, эштән китеп, студиядә генә калдым. «Сарафан радиосы»ннан ишетеп, танылган артистлар килә башлады. Шуннан Казан җырчыларына да барып җитте бу. Җыр яздырам, дип, Уфага тикле килүчеләр берзаман бик артты. Казанга әйдәкләүчеләр дә булды. Аннан соң Уфада бәяләр дә түбәнрәк бит. Шулай итеп, 2019 елда гаиләм белән Казанга күчендек.

:: Студиядән чыкмыйсыз да кебек. Илһам һәм көчне кайлардан алып бетерәсез?
– Илһам дип... Аның килгәнен көтеп ятсаң, җырчылар чыгып кача бит. Заманы шундый бүген: агымга ияләм дисәң, җырларны берсе артыннан берсен язып, яздырып кына торырга кирәк. Җырчыларга да, популяр булыйм, дисәләр, яңа җырларны элеккеге кебек елга бер генә түгел, ай саен тәкъдим итеп торырга туры килә. Бу күренешнең уңай яклары да, тискәре яклары да бар. Иҗатчылар гел нидер эшли, кыймылдый, эзләнә, бер-берсе белән ярыша һәм бу аларны тонуста тота. Монысы яхшы инде. Тик тыңлаучылар яңа җырны тулысынча кабул итәргә, күңеленә кертергә өлгерми, тагын яңасы чыга. Шуңа да кайбер хит булырга тиешле җырлар игътибардан читтә кала.

:: Мондый тизлектә сезгә эзләнергә вакыт каламы соң?
– Җырчылар үземчә эшләргә ирек бирсәләр, эзләнәм, яңа, моңарчы ишетелмәгән стильләрдә эшлим. Ә кайбер җырчылар ничек, ни рәвешле кирәген үзләре аңлата. «Әнә бу җырчыга эшләгәнсең бит, миңа да шундыйрак кирәк», – диючеләр дә бар. Шуңа күрә кайбер чакта җырлар охшаш та була. Безнең җырчылар күбрәк бер-берсен тыңлый бит. Башны бераз читкә дә борырга кирәк инде, янача эшләргә. Шулай булганда гына үсә аласың.

:: Җырларны ничә көндә язасыз?
– Бертуктамый эшләгәндә, ике көндә әзер була. Бер көн эчендә язган чаклар да булгалый. Өч көнгә өч җыр язган да бар. Әле ул чакта Уфада идем мин, Илсөя Бәдретдинова шалтырата. Өч җырым бар, бергә эшләп карыйк әле, дип. Беренче көнне «Юри генә» җырын яздырттык. Шул арада баянчы табып, баян тавышын да өстәп җибәрдек, гитара да кушылды. Икенче көнне көйсез җыр алып килде бу миңа. Кара-каршы утырып, көен яздык. «Син үзеңне бел, яме» җыры иде ул. Булды анысы да. Ике көнгә – ике әзер җыр менә. Өченче көнне тагын коры текст күтәреп килгән. «Тиз язасың бит инде син», – ди, ышана миңа шулкадәр. Ә бит ул чакта беренче тапкыр гына эшләвебез иде. Урал Солтанов белән күршеләр идек без, аның янына чәй эчәргә кергән җирдән өченче җырга да көй табып алып чыктык. Аның әзер көйләре булган икән. «Кеше төсле булмады» җыры шулайрак иҗат ителде. Шуннан бирле шушы тизлекне саклыйбыз дияргә була. Илсөя килсә, бер көндә эшен бетереп кайтып китә инде.

Әнвәр Габдрәфыйков

:: Бу темпка безнең башка композиторлар, аранжировка ясаучылар иярә аламы соң?
– Алар миңа аптырый инде. «Әллә көненә бер җыр эшлисең инде?» – диләр (*көлә*). «Була инде», – дим. Аларны айга бер җыр язу канәгатьләндерә. Ай буе нишләп бетәргә кирәк? Бөтен нечкәлекләрен исәпкә алып эшләгән очракта да, җырың берәүгә дә кирәк булмаска мөмкин. Йә халыкка ошый, йә юк. Әлбәттә, җырның эченә кереп бетеп, һәр нотасын аңлап тыңлаучылар да бар. Ләкин тыңлаучыларның 90 процентына ул яклары мөһим түгел.

Блиц-сораштыру

– Сез иҗаттан тыш та җырчылар белән дусмы?
– Кайберләре белән дус.
– Композиторлар, аранжировка ясаучылар арасында көндәшлек бармы?
– Белмим, дөресен генә әйткәндә, берәү белән дә ярышмыймын. Үземчә эшлим. Башкаларны күзәтергә вакыт та юк. Диванда кырын ятканда карап, тикшереп ятсаң гына инде.
– Ничек ял итәсез?
– Тынычлыкта, үз уйларым белән генә калып. Гаиләм белән.
– Тормыш девизыгыз?
– Армиядә безгә: «Яхшы итеп эшләсәң, әҗерен дә күрерсең», – дип әйтәләр иде. Шул принцип буенча яшим.
– Сез хыялыймы?
– Мин күбрәк реалисттыр.
– Алай да, берәр зур хыялыгыз бармы?
– Балаларым яхшы кеше булсыннар иде. Гомумән, бар да яхшы булуын телим.

ӘҢГӘМӘНЕҢ ТУЛЫ ВАРИАНТЫ – VATANTAT.RU САЙТЫНДА

Ә СИН ТАНЫЙСЫҢМЫ?

Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Шартлар шул ук: җырчы һәм җырның исемен язып җибәрергә кирәк. Тулы, дөрес һәм беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.

*Узган атнадагы санда чыккан уенда дөрес җавапны беренчеләрдән булып Саба районының Яңа Мичән авылыннан **Сөмбелә Ибраһимова** җибәрде. Афәрин! Рәсемнәр астына без Әлфинә Әзһәмованың «Мәхәббәт булмаса дөньяда», Зөлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар репертуарыннан «Әйләнәбез гомер бакчасында» һәм Хәния Фәрхи башкаруындагы «Дусларга» җырларын яшергән идек.*

Киткән саен моңаеп, кул изәп калган, кара ярал агачлар турында бу җыр.

Әлеге җырны шаярып кына яратучы, уйнап кына сөйләшүче, юри генә көнләшүче бер кеше башкара.

Яшәү-көкрәүләргә тиң гомер һәркемгә бирелмәгәндер, ә гомер кичерүебез юкка түгелдер, ди җырчы.

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

20 июль | Чәршәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

Вниманию телезрителей! В связи с профилактическим ремонтом в среду, 20 июля, телевизионные программы канала ТНВ с 02.00 до 09.00 не транслируются.
09.00, 17.00 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР» 6+
10.00, 22.50 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ» 12+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.00 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Жырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия» 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
17.00 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «Без химии». Документальный фильм (Россия, 2020) 12+
21.00 «Соотечественники» 12+
23.50 «Соотечественники». Золотая рапира Владимира Житлова 12+
00.15 «Каравай». Творческая мастерская 6+
00.40 «Жырлыйк әле!» 6+
01.30 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

09.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
09.40 «Ачыктан-ачык « 12+
10.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
11.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның халык артисты Рөстәм Маликов турында телеочерк 6+
13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
15.00 «Яңалыклар» 12+
15.30 «Яшьләр тукталышы» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Яңалыклар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
21.00 «Яңалыклар» 12+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
00.00 «Яңалыклар» 12+
00.40 «Таяну ноктасы» 16+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
04.15 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның халык артисты Рөстәм Маликов турында телеочерк 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Телеканал «Доброе утро»
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.35 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «СПРОСИТЕ МЕДСЕСТРУ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 «Соломон Волков. Диалоги с Евгением Евтушенко» 12+
00.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
23.55 Премьера. «Иван Зубков. Спаситель Ленинграда» 12+
00.55 Ольга Иванова, Никита Тезин, Алика Смехова, Юрий Батурин, Сергей Селин. «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ. СУДЬБА» 12+
02.40 Александр Бухаров, Елена Полякова, Денис Синявский. «ЖЕНЩИНЫ НА ГРАНИ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.10, 12.35, 14.55, 19.00, 21.45 Новости
06.05, 18.30, 21.00, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.15, 12.40, 02.40 Специальный репортаж 12+
09.35, 00.45 «ФАНТОМ» 12+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00, 15.00 «ПОБЕГ» 16+
15.55, 03.35 Автоспорт. Чемпионат России по дрэг-рейсингу 0+
16.25 Бильярд. Чемпионат мира. Мужчины. Финал. Прямая трансляция из Киргизии
19.05 «НЕКУДА БЕЖАТЬ» 16+
21.50 Футбол. Чемпионат Европы-2022. Женщины. 1/4 финала. Прямая трансляция из Великобритании
03.00 Новости 0+
03.05 «Голевая неделя РФ» 0+
04.00 Бильярд. Чемпионат мира. Женщины. Финал. Трансляция из Киргизии 0+
05.05 «Защита Валерия Васильева». Док. фильм 12+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00 «Сегодня»
08.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» (S) 16+
10.00 «Сегодня»
10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» (S) 16+
13.00 «Сегодня»
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 Сериал «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+
16.00 «Сегодня»
16.50 «За гранью» (S) 16+
17.55 «ДНК» (S) 16+
19.00 «Сегодня»
19.50 «ПЕНСИЛЬВАНИЯ» (S) 16+
21.45 «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ» (S) 16+
23.40 «Сегодня»
00.00 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
01.55 Детективный сериал «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.20 «Давай разведёмся!» 16+
10.20 «Тест на отцовство» 16+
12.30 «Понять. Простить» 16+
13.35 «Порча». «Земляки» 16+
14.05 «Знахарка» 16+
14.40 «Верну любимого» 16+
15.15 «САШИНО ДЕЛО» 16+
19.00 «ПОЧТИ ВСЯ ПРАВДА» 16+
22.45 «Порча» 16+
23.20 «Знахарка» 16+
23.50 «Верну любимого» 16+
00.25 «Понять. Простить» 16+
01.15 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 5-я и 6-я серии 16+
02.55 «Субтитр Тест на отцовство» 16+
04.35 «Давай разведёмся!» 16+
05.25 «6 кадров» 16+
05.30 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.30 «КОГДА РАСТАЯЛ СНЕГ» 16+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
09.55 «ОТРЯД СПЕЦИАЛЬНОГО НАЗНАЧЕНИЯ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 16+
13.25 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
13.40, 14.05 «ГЕТЕРЫ МАЙОРА СОКОЛОВА» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.50 «Битва ставок». Док. сериал. «Бросок на запад» 16+
19.40 «Секретные материалы». Док. сериал. «Европейская Хиросима. Секретный план Черчилля» 16+
22.55 «ГОСУДАРСТВЕННЫЙ ПРЕСТУПНИК» 12+
00.35 «КРОВЬ ЗА КРОВЬ» 16+
02.15 «В ПОЛОСЕ ПРИБОЯ» 12+
03.45 «МИГУДАЧИ» 12+
04.50 «Перелом. Хроника Победы». Док. сериал 16+

21 июль | Пәнҗешәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00 Прямая трансляция литургии из Казанского собора Богородицкого монастыря в честь праздника обретения Казанской иконы Божией Матери 0+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.00 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
14.45 «Каравай» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Казаннан – казанга» 12+
17.00 «БИЛЯР. КЛАДОВАЯ НАСЛЕДИЯ» 12+
19.00, 20.00, 01.05 «Точка опоры» 16+
21.00 «Ватандашлар» 12+
22.50 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ» 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Николай Морозов. Объять необъятное 12+
00.40 «Каравай». Красота национального костюма 6+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Башваткыч» 12+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
09.40 «Кунак БиТ шоу» 12+
11.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05 «Аулак өйгә дәшкән егет». Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов турында телеочерк 6+
15.00 «Яңалыклар» 12+
15.30 «Халкым минем» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Яңалыклар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Аулак өйгә дәшкән егет». Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов турында телеочерк 6+
21.00 «Яңалыклар» 12+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
23.05 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
00.00 «Яңалыклар» 12+
00.40 «Ватандашлар» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
04.15 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Телеканал «Доброе утро»
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.35 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «СПРОСИТЕ МЕДСЕСТРУ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
23.55 «Чёрное и белое торпедовца Стрельцова» 12+
00.55 Ольга Иванова, Никита Тезин, Алика Смехова, Юрий Батурин, Сергей Селин «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ. СУДЬБА» 12+
02.40 Александр Бухаров, Елена Полякова, Денис Синявский. «ЖЕНЩИНЫ НА ГРАНИ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.10, 12.35, 14.55, 16.55, 21.45 Новости
06.05, 17.00, 21.00, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.15, 12.40, 02.40 Специальный репортаж 12+
09.35, 00.45 «ФАНТОМ» 12+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00, 15.00 «ПОБЕГ» 16+
15.55 Смешанные единоборства. One FC. Деметриус Джонсон против Родтанга Джитмуангнона. Трансляция из Сингапура 16+
17.35 Международные соревнования «Игры дружбы-2022». Плавание. Прямая трансляция из Казани
20.30 Матч! Парад 16+
21.50 Футбол. Чемпионат Европы-2022. Женщины. 1/4 финала. Прямая трансляция из Великобритании
03.00 Новости 0+
03.05 «Человек из футбола» 12+
03.35 «Второе дыхание. Валерий Кобелев» 12+
04.00 Международные соревнования «Игры дружбы-2022». Плавание. Трансляция из Казани 0+
05.05 «Якушин. Первый среди первых». Док. фильм 12+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00 «Сегодня»
08.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» (S) 16+
10.00 «Сегодня»
10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» (S) 16+
13.00 «Сегодня»
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+
16.00 «Сегодня»
16.50 «За гранью» (S) 16+
17.55 «ДНК» (S) 16+
19.00 «Сегодня»
19.50 «ПЕНСИЛЬВАНИЯ» (S) 16+
21.45 Премьера. Остросюжетный сериал «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ» (S) 16+
23.40 «Сегодня»
00.00 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
01.50 Детективный сериал «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.15 «Давай разведёмся!» 16+
10.15 «Тест на отцовство» 16+
12.20 «Понять. Простить» 16+
13.25 «Порча». «Денежное дерево» 16+
13.55 «Знахарка» 16+
14.30 «Верну любимого» 16+
15.05 «ЗДРАВСТВУЙ, ПАПА!» 16+
19.00 «НИТИ ЛЮБВИ» 16+
22.40 «Порча» 16+
23.15 «Знахарка» 16+
23.45 «Верну любимого» 16+
00.20 «Понять. Простить» 16+
01.10 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 7-я и 8-я серии 16+
02.50 «Тест на отцовство» 16+
04.30 «Давай разведёмся!» 16+
05.20 «6 кадров» 16+
05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «ГЕТЕРЫ МАЙОРА СОКОЛОВА» 16+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.30 «ОТРЯД СПЕЦИАЛЬНОГО НАЗНАЧЕНИЯ» 12+
11.20 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 16+
13.25 «Сделано в СССР». Документальный сериал 12+
13.40, 14.05 «ГЕТЕРЫ МАЙОРА СОКОЛОВА» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Битва ставок». Документальный сериал. «На Берлин!» 16+
19.40 «Код доступа». «Черная» дыра «зеленой» энергетики 12+
21.15 «Открытый эфир». Премьера! 16+
22.55 «ОДИН ШАНС ИЗ ТЫСЯЧИ» 12+
00.20 «КОРОЛЕВСКАЯ РЕГАТА» 6+
01.50 «ГОСУДАРСТВЕННЫЙ ПРЕСТУПНИК» 12+
03.20 «СМЕРТЬ НЕГОДЯЯ» 16+

22 июль | Җомга

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести-Татарстан»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!»12+
09.00, 17.00 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР» 6+
10.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
11.00 «Нәсыйхәт» 6+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.00 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 6+
14.15 «Классный час» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Аулак өй» 6+
16.30 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Туган җир» 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты 6+
20.00 Телефильм 12+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
21.00 «Юлчы» 6+
23.00 «АМЕРИКАНЕЦ» 16+
00.45 «Каравай». Живописная летопись Татарстана 6+
01.10 «ЕРАКТАГЫ ЙОЛДЫЗЫМ» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.15 «Кәмит Җәвит» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40 «Ком сәгате» 12+
09.40 «Нәсыйхәт» 6+
10.30 «Казаннан – казанга» 12+
11.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Садри Максуди һәм Әхмәт һади турында телеочерк 6+
15.00 «Яңалыклар» 12+
15.30 «Нәсыйхәт» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30 «Калеб» 6+
18.00 «Яңалыклар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10 «Туган җир» 12+
19.35 «Заман көзгесе» 6+
20.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
21.00 «Яңалыклар» 12+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
23.05 «Ком сәгате» 12+
00.00 «Яңалыклар» 12+
00.40 Ю.Әминов. «ӘТИ БАЛАК ГӨЛҮЗӘ». К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
04.15 «Ком сәгате» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Телеканал «Доброе утро»
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.35 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.40 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым 16+
19.45 «Поле чудес» (S) 16+
21.00 «Время»
21.45 «Две звезды. Отцы и дети» (S) 12+
23.25 К 60-летию Романа Мадянова. «С купеческим размахом» 12+
00.25 «Информационный канал» 16+
04.15 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Александр Петров, Виктор Добронравов, Александр Яценко, Стася Милославская. «СТРЕЛЬЦОВ» 6+
23.20 Премии «Ника» и «Золотой Орёл». Оксана Акиньшина, Антон Шагин, Олег Янковский, Сергей Гармаш. «СТИЛЯГИ» 16+
01.55 Премия «Золотой Орёл». Ксения Раппопорт, Иван Янковский, Игорь Миркурбанов, Владимир Симонов. «ДАМА ПИК» 16+
04.05 «Чёрное и белое торпедовца Стрельцова» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.10, 12.35, 14.55, 21.25 Новости
06.05, 17.55, 20.35, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
09.15 Специальный репортаж 12+
09.35, 01.05 «ФАНТОМ» 12+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.40 «Лица страны. Александр Шлеменко» 12+
13.00 «ПОБЕГ» 16+
15.00, 05.05 Автоспорт. G-Drive Российская серия кольцевых гонок. Трансляция из Нижнего Новгорода 0+
15.30 Смешанные единоборства. One FC. Виталий Бигдаш против Ренье де Риддера. Прямая трансляция из Сингапура
18.10 Международные соревнования «Игры дружбы-2022». Плавание. Прямая трансляция из Казани
21.30 Смешанные единоборства. ACA. Алихан Сулейманов против Фелипе Фроеса. Прямая трансляция из Сочи
03.00 Новости 0+
03.05 Художественная гимнастика. Международный турнир «Хрустальная роза». Трансляция из Белоруссии 0+
04.00 Международные соревнования «Игры дружбы-2022». Плавание. Трансляция из Казани 0+
05.30 «РецепТура» 0+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00 «Сегодня»
08.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» (S) 16+
10.00 «Сегодня»
10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» (S) 16+
13.00 «Сегодня»
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 Сериал «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+
16.00 «Сегодня»
16.50 «За гранью» (S) 16+
17.55 «ДНК» (S) 16+
19.00 «Сегодня»
19.50 «ПЕНСИЛЬВАНИЯ» (S) 16+
22.30 Премьера. «ВОЗВРАЩЕНИЕ ЛЕГЕНДЫ». Юбилейный концерт группы «ЗЕМЛЯНЕ» (S) 12+
00.50 «Квартирный вопрос» (S) 0+
01.40 «Их нравы» 0+
02.00 «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.05 «Давай разведёмся!» 16+
10.05 «Тест на отцовство» 16+
12.20 «Понять. Простить» 16+
13.25 «Порча». «Шах и мат» 16+
13.55 «Знахарка» 16+
14.30 «Верну любимого» 16+
15.05 «ПОЧТИ ВСЯ ПРАВДА» 16+
19.00 «ЖИВАЯ ВОДА» 16+
22.45 «ЕЁ СЕРДЦЕ» 16+
00.35 «Порча» 16+
01.00 «Знахарка» 16+
01.25 «Верну любимого» 16+
01.50 «Понять. Простить» 16+
02.40 «Тест на отцовство» 16+
04.20 «Давай разведёмся!» 16+
05.10 «6 кадров» 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «ГЕТЕРЫ МАЙОРА СОКОЛОВА» 16+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20 «ОТРЯД СПЕЦИАЛЬНОГО НАЗНАЧЕНИЯ» 12+
10.50 «Легенды разведки. Николай Кузнецов». Док. фильм 16+
11.35 «ЭКИПАЖ МАШИНЫ БОЕВОЙ» 12+
13.25, 14.05 «МОСКОВСКИЙ ДВОРИК» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.40 «Время героев». Премьера! 16+
19.00 «МОСКОВСКИЙ ДВОРИК» 16+
23.00 «Музыка+». Премьера! 12+
23.55 «ВОЕННЫЙ КОРРЕСПОНДЕНТ» 16+
01.40 «ВОЕННО-ПОЛЕВОЙ РОМАН» 16+
03.10 «ДЕНЬ СЧАСТЬЯ» 12+
04.45 «Последняя миссия «Охотника». Док. фильм 12+
05.30 «Москва фронту» 16+

23 июль | Шимбә

ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам». Музыкаль котлаулар 6+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш…» Лилия Биктимерова 12+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Татар халык җырлары». концерты 0+
11.30 «Казаннан – казанга» 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 12+
13.00 Татарстанның халык артисты Зөфәр Харисовның юбилей кичәсе 6+
15.30 «Үткәннәрне барлап…» Айдар Фәйзрахманов 6+
18.00 «Кәмит Җәвит» 16+
19.00 «Халкым минем…» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу 12+
20.00 «Ватандашлар» 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «Кунак БиТ шоу». Альбина Апанаева 12+
23.00 «ДЕТКИ НАПРОКАТ» 12+
00.35 «ГОЛОГРАММА ДЛЯ КОРОЛЯ» 18+
02.20 «Вехи истории». Вставай, страна огромная 12+
02.45 «Каравай». Краски Сабантуя 6+
03.10 «Татар халык җырлары» 0+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Фоат Әхмәтҗанов турында телеочерк 6+
07.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 6+
09.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Башваткыч» 12+
12.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 Т.Миңнуллин. «НӘЗЕР». М.Фәйзи исемендәге Оренбург Татар дәүләт драма театры спектакле 12+
17.10 «Казаннан – казанга» 12+
17.45 «Халкым минем» 12+
18.15 «Башваткыч» 12+
19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
20.00 «Гомер бик сизгер икән». Ринат Мөслимов җырларыннан концерт 12+
22.45 К.Тинчурин. «ҖИЛКӘНСЕЗЛӘР». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
01.30 «СӨЮ КӨТӘ ЙӨРӘК» 12+
03.00 «Башваткыч» 12+
03.50 «Җырлыйк әле!» 6+
04.40 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
05.05 «Халкым минем» 12+
05.30 «Нәсыйхәт» 6+

1 КАНАЛ

06.00 Телеканал «Доброе утро. Суббота»
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 «Сергий Радонежский. Заступник Руси» 12+
11.20 «Видели видео?» 0+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Видели видео?» 0+
14.25 Фильм «Пираты XX века» 12+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 «Пираты XX века» 12+
16.20 Фильм Юрия Озерова «ОСВОБОЖДЕНИЕ». «ПРОРЫВ» (S) 12+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 «На самом деле» 16+
19.25 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.35 «Сегодня вечером» 16+
23.15 Комедия «КРАСОТКА В УДАРЕ» (S) 16+
01.05 «Наедине со всеми» 16+
03.20 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Местное время. Вести-Татарстан
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
11.30 «Доктор Мясников». Медицинская программа 12+
12.35 Янина Студилина, Анатолий Лобоцкий, Александр Туманов, Александра Назарова, Марина Яковлева и Сергей Губанов в телесериале «ЧУЖАЯ ЖИЗНЬ» 16+
17.00 Вести
18.00 «Привет, Андрей!» Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
20.00 Вести
21.00 Ирина Антоненко, Александр Константинов, Александр Наумов, Станислав Боклан, Виталий Салий, Всеволод Болдин. «КРОВНАЯ МЕСТЬ» 12+
00.50 Екатерина Олькина, Артём Осипов, Максим Житник, Александр Бухаров. «ПОДМЕНА» 12+
04.00 Анна Банщикова, Александр Голубев, Владимир Юматов, Юлия Зимина. «ЧТО СКРЫВАЕТ ЛЮБОВЬ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства. URAL FC. Кирилл Сидельников против Фабио Мальдонадо. Трансляция из Перми 16+
07.00, 09.00, 13.55, 17.00, 21.55 Новости
07.05, 14.00, 17.05, 20.25 Все на Матч! Прямой эфир
09.05 «КРОВАВЫЙ АЛМАЗ» 16+
11.55 «НЕКУДА БЕЖАТЬ» 16+
14.30 Футбол. Российская Премьер-лига. ЦСКА – «Сочи». Прямая трансляция
17.35 Международные соревнования «Игры дружбы-2022». Плавание. Прямая трансляция из Казани
22.00 Смешанные единоборства. UFC. Кёртис Блэйдс против Тома Аспинэлла. Прямая трансляция из Великобритании
01.00 Пляжный волейбол. BetBoom Чемпионат России. Женщины. Финал. Трансляция из Орла 0+
02.00 Пляжный волейбол. BetBoom Чемпионат России. Мужчины. Финал. Трансляция из Орла 0+
03.00 Новости 0+
03.05 Художественная гимнастика. Международный турнир «Хрустальная роза». Трансляция из Белоруссии 0+
04.00 Бокс. Bare Knuckle FC. Джарод Грант против Реджи Барнетта. Прямая трансляция из США

НТВ

05.00 «Кто в доме хозяин?» (S) 12+
05.35 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
08.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» (S) 0+
09.25 «Едим дома» (S) 0+
10.00 «Сегодня»
10.20 «Главная дорога» (S) 16+
11.00 «Живая еда» с Сергеем Малозёмовым (S) 12+
12.00 «Квартирный вопрос» (S) 0+
13.05 «Однажды…» (S) 16+
14.00 «Своя игра» (S) 0+
15.00 «Следствие вели…» (S) 16+
16.00 «Сегодня»
16.20 «Следствие вели…» (S) 16+
19.00 «Сегодня»
19.35 Остросюжетный сериал «ПЕНСИЛЬВАНИЯ» (S) 16+
22.15 «Маска» (S) 12+
01.00 «Дачный ответ» (S) 0+
02.05 Детективный сериал «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
08.05 «КАРНАВАЛ» 16+
11.15 «ОБЪЯТИЯ ЛЖИ». 1-я - 8-я серии 16+
19.00 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК». 109-я и 110-я серии 16+
22.50 «ТРИ ИСТОРИИ ЛЮБВИ» 16+
02.20 «ОБЪЯТИЯ ЛЖИ». 1-я – 4-я серии 16+
05.30 «Лаборатория любви» 16+
06.20 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.55, 03.35 «КАК ИВАНУШКА-ДУРАЧОК ЗА ЧУДОМ ХОДИЛ» 6+
07.20, 08.15 «ВАСИЛИЙ БУСЛАЕВ» 6+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.15 «Легенды кино». Алексей Смирнов 16+
10.00 «Главный день». Климент Ворошилов 16+
10.50 «Война миров». Док. сериал. «Партизаны против полицаев» 16+
11.40 «Не факт!» 12+
12.05 «СССР. Знак качества» с Гариком Сукачевым». «Кем быть? Профессии в СССР» 12+
13.15 «Легенды музыки». Юрий Антонов 12+
13.45, 18.30 «ОТРЯД СПЕЦИАЛЬНОГО НАЗНАЧЕНИЯ» 12+
21.40 «КОНТРУДАР» 12+
23.20 «В КВАДРАТЕ 45» 12+
00.40 «ДВА БОЙЦА» 12+
01.55 «ДЕНЬ СЧАСТЬЯ» 12+
05.00 «Последний штурмовик». Док. фильм 12+

24 июль | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Сагынырлык булсын…» Марат Кабировның иҗат кичәсе 6+
08.30 Мультфильмы 6+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы- шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 12+
10.15 «Ачыктан-ачык». Эльмира Кәлимуллина 12+
11.00 «Без». Илсөя Бәдретдинова 6+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Мәңгелектән исә җил». Ләис Зөлкарнәйнең юбилей кичәсе 6+
14.30 «Сула!» Ришат Төхвәтуллин 6+
16.00 «Ком сәгате» 12+
17.00 «Видеоспорт» 12+
17.30 «Соотечественники» 12+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00 «Каравай» 6+
19.30 «Әдәби хәзинә» 6+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты 6+
21.00 «Республиканский конкурс красоты «Мини Мисс Татарстан». Финал 6+
23.00 «РУД И СЭМ» 12+
00.35 «КРАДЕНОЕ СВИДАНИЕ» 18+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Семь дней +». Эльмира Калимуллина 12+
03.55 «Вехи истории». Все для фронта! Все для победы! 12+
04.20 «Семь дней +». Мансур Гилязов 12+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Татар халык көйләре». Баянда Рамил Курамшин 6+
07.00 «Җыром булсын бүләгем». Гали Ильясов җырлый 6+
07.25 Т.Җүкәнаголу. «ТАШКЫН». С.Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры спектакле 12+
09.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Сәҗидә Сөләйманова турында телеочерк 6+
10.00 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
10.30 «Калеб» 6+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы» 12+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00 «Яшау – мизгел». Татарстанның халык артисты Нафкать Нигъмәтуллин концерты 6+
15.20 Н.Гыйматдинова. «СИХЕРЧЕ». Т.Миңнуллин исемендәге Түбән Кама Татар дәүләт драма театры спектакле 12+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.05 «Ком сәгате» 12+
20.00 «АКЧА КОРТЫ». «Мунча ташы» татар эстрада театры спектакле 12+
22.50 «Йөрәктән – йөрәккә». Фоат Әхмәтҗанов турында телеочерк 6+
23.45 «Ком сәгате» 12+
00.40 «Яшьләр тукталышы» 12+
01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
02.50 «Казан» бию ансамбле концерты 6+
04.50 «Шаян хәлләр» 12+

1 КАНАЛ

05.05 «ОТЧАЯННЫЕ» (S) 16+
06.00 Новости
06.10 «Отчаянные» (S) 16+
07.00 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» (S) 12+
08.15 «Здоровье» 16+
09.20 «Непутевые заметки» 12+
10.00, 12.00 Новости (с субтитрами)
10.15 «Ирина Мирошниченко. «Я ЗНАЮ, ЧТО ТАКОЕ ЛЮБОВЬ» 12+
11.15, 12.15 «Видели видео?» 0+
13.50, 15.15 «Краткое пособие по тому, как устроен мир» 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 «Краткое пособие по тому, как устроен мир» 16+
19.00 «Леонид Кравчук. Повесть о щиром коммунисте» 16+
19.55 Премьера. Специальный репортаж. «Парни «с Квартала» 16+
21.00 «Время»
22.35 «ЭТО СЛАДКОЕ СЛОВО – СВОБОДА!» 12+
01.15 «Владимир Маяковский. Третий лишний» 12+
02.05 «Наедине со всеми» 16+
03.35 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1

05.35 Анна Снаткина, Эмилия Спивак, Андрей Соколов, Екатерина Стриженова. «ЛЕТОМ Я ПРЕДПОЧИТАЮ СВАДЬБУ» 16+
07.15 «Устами младенца»
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
11.30 «Доктор Мясников». Медицинская программа 12+
12.35 Янина Студилина, Анатолий Лобоцкий, Александр Туманов, Александра Назарова, Марина Яковлева, Сергей Губанов. «ЧУЖАЯ ЖИЗНЬ» 16+
17.00 Вести
18.00 «Песни от всей души». Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
20.00 Вести недели
22.00 «Воскресный вечер» 12+
01.00 «НЕКРАСИВАЯ ЛЮБОВЬ» 16+
02.35 «ЛЕТОМ Я ПРЕДПОЧИТАЮ СВАДЬБУ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Бокс. Bare Knuckle FC. Джарод Грант против Реджи Барнетта. Прямая трансляция из США.
07.30, 09.00, 13.55, 17.00 Новости
07.35, 14.00, 19.40, 23.20 Все на Матч! Прямой эфир
09.05 «ВЕЛИКИЙ ГЭТСБИ» 16+
11.55 Регби. Чемпионат России. «Красный Яр» (Красноярск) – «Стрела» (Казань). Прямая трансляция
14.35 Художественная гимнастика. Международный турнир «Хрустальная роза». Прямая трансляция из Белоруссии
16.00 Бокс. Bare Knuckle FC. Джарод Грант против Реджи Барнетта. Трансляция из США 16+
17.05 Международные соревнования «Игры дружбы-2022». Плавание. Прямая трансляция из Казани
19.55 Футбол. Российская Премьер-лига. «Локомотив» (Москва) – «Ростов». (Ростов-на-Дону). Прямая трансляция
22.00 После футбола с Георгием Черданцевым
23.00 «Лица страны. Александр Шлеменко» 12+
00.20 «УБОЙНАЯ КОМАНДА» 16+
02.35 «Всё о главном» 12+
03.00 Новости 0+
03.05 Художественная гимнастика. Международный турнир «Хрустальная роза». Трансляция из Белоруссии 0+
04.00 Смешанные единоборства. UFC. Кёртис Блэйдс против Тома Аспинэлла. Трансляция из Великобритании 16+

НТВ

05.00 «Кто в доме хозяин?» (S) 12+
05.35 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
08.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» Лотерейное шоу (S) 12+
10.00 «Сегодня»
10.20 «Первая передача» (S) 16+
11.00 «Чудо техники» (S) 12+
12.00 «Дачный ответ» (S) 0+
13.00 «НашПотребНадзор» (S) 16+
14.00 «Своя игра» (S) 0+
15.00 «Следствие вели…» (S) 16+
16.00 «Сегодня»
16.20 «Следствие вели…» (S) 16+
19.00 «Сегодня»
19.50 Остросюжетный сериал «ПЕНСИЛЬВАНИЯ» (S) 16+
21.40 «Ты не поверишь!» (S) 16+
22.25 «Маска» (S) 12+
01.05 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» (S) 16+
01.35 «Их нравы» 0+
01.55 «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
09.35 «ЕЁ СЕРДЦЕ» 16+
11.30 «НИТИ ЛЮБВИ» 16+
15.15 «ЖИВАЯ ВОДА» 16+
19.00 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК». 111-я и 112-я серии 16+
22.40 «СПИСОК ЖЕЛАНИЙ» 16+
02.05 «ОБЪЯТИЯ ЛЖИ». 5-я – 8-я серии 16+
05.15 «Лаборатория любви» 16+
06.05 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.45 «ВОЕННЫЙ КОРРЕСПОНДЕНТ» 16+
07.30 «БЕРЕМ ВСЕ НА СЕБЯ» 12+
09.00 «Новости недели» с Юрием Подкопаевым 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.40 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Что не так с нашей погодой?» 16+
11.30 «Код доступа». «Фейки. Ложь как оружие» 12+
12.15 «Легенды армии» с Александром Маршалом. Нельсон Степанян 12+
13.00 «Специальный репортаж» 16+
13.35 «УЧАСТОК ЛЕЙТЕНАНТА КАЧУРЫ» 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
20.00 «Легенды советского сыска». Док. сериал 16+
23.30 «ВОР» 16+
01.10 «ВАСИЛИЙ БУСЛАЕВ» 6+
02.25 «ДВА БОЙЦА» 12+
03.45 «ПОДКИДЫШ» 6+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?

Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 18 июль

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10 Каюм Насыйри. «Әбугалисина». Моноспектакль
13.10 «Татарстан дулкынында»
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 19 июль

6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.20 «Вместе за безопасность»
18.30 Сирәк яңгыраган музыкаль язмалар

Чәршәмбе, 20 июль

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 «Вместе за безопасность»
7.20 Туры элемтә
7.45 «Юллар чатында»
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
11.40 Прокуратура разъясняет
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Туган авылларга багышланган җырлар

Пәнҗешәмбе, 21 июль

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Офыклар»
18.25 Кирам Сатиев концерты

Җомга, 22 июль

6.00-8.00 «Иртәнге нур». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Доброе братство лучше богатства» (на удмуртском языке)
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 «Казан нуры» халык уен кораллары оркестры концерты

Шимбә, 23 июль

8.10 Ф.Яруллин һәм З.Насыйбуллин әсәрләреннән радиокомпозиция
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Гөлбакча»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине өйрәтәм». Радиосериал
11.25 Татар халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 «Әдәбиятыбыз сәхифәләре». С.Гәрәева шигырьләре. Н.Хәсәновның «Күзләреңдә бәби бар» хикәясе.

Якшәмбе, 24 июль

8.10-9.00 «Родники культуры»
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий недели
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10,16.10 Әхәт Гаффар. «Язлар моңы». Минзәлә ТДДТ спектакле

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

РӘДИФ ҖАМАЛЕТДИНОВ:

«УКЫТУЧЫЛАР ҖАГЫЙДӘ ЯТЛАТЫП КЫНА УТЫРМЫЙ»

Быел КФУның татар теле юнәлешенә укырга керергә теләүчеләр күпме? Соңгы елларда ачыла торган күптелле мәктәпләр, шулай ук татар гимназияләре укытучыларга кытлык кичерми-ме? Мөгаллимнәр заман таләбенә туры китереп әзерләнәме? Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Рәдиф ҖАМАЛЕТДИНОВ белән милли кадрлар әзерләү турында сөйләштек.

:: Рәдиф Рифкатович, быел республика мәктәпләрендә 11 нче сыйныф укучылары арасында татар теленнән нибары бер генә укучы республика сынавын бирде. Моңа хафаланырга кирәкме? Бу – вузларда татар теленең кирәге юк, дигән сүзме, әллә яшьләрне башка белгечлекләр кызыксындырамы?

– Дөрес, быел татар теленнән республика имтиханын бер генә укучы тапшырды. Бу – Балтач районының Норма мәктәбе укучысы Әдилә Шәйхетдинова. Ул безнең уку йортында укырга теләгән белдерде. Татар теле сынавын бердәнбер бала гына сайлаганга хафаланыргамы, хафаланмаскамы? Монда мәсьәлә ике яклы. Бер яктан караганда, Әдилә Шәйхетдинова өчен әлеге имтихан күпмедер күләмдә инде кирәк тә түгел. Ул Россия күләмендә безнең университет базасында уздырылган олимпиада призеры булды. Моның үз өстенлекләре бар. Әгәр рус теленнән бердәм дәүләт имтиханын 75 баллдан да ким бирмәгән очракта, татар теленнән автомат рәвештә 100 балл бирелә. Бу очракта Әдилә олимпиада призеры булды һәм татар теленнән абсолют балл алды. Икенче яктан караганда, уйланырга урын бар. Нишләп әле безнең чыгарылыш сыйныф укучылары татар теленнән республика сынавын тапшырмыйлар? Мин инде үземчә шулай аңларга тырышам. Берничә ел элек кызыбыз Диләрә мәктәпне тәмамлады, аңа берничә фәннән имтиханга әзерләнергә туры килде. Бу бер дә җиңел түгел. БДИны традицион тапшырып булмый, татар теленнән имтиханны исә вузда бирергә мөмкин. Шуңа күрә кайбер яшьләр имтиханга әзерләнү мәшәкатен киметү өчен, нәкъ шушы юлны сайлый. Бездә татар теленнән эчке имтихан 16 июльдә узачак. Анда 170 бала сынау үтәчәк. Бу соңгы сан түгел, әле берничә көн вакыт бар. Әгәр БРИны вакытында тапшырып килсәләр, безнең өчен күпмедер күләмдә уңайлырак аныйсы. Ул очракта эчке имтихан тапшырырга кирәкми. Әмма без үзебез кабул иткәндә, әлеге балаларның әзерлеген, ничек язганына кадәр күрәбез. Аның уңай яклары да бар. Кыскасы, республикада имтиханнарны сайлап алу мөмкинлеге тудырылган. Минемчә, моннан фаҗига ясарга кирәкми.

:: Вузларның милли юнәлешләренә кабул иткәндә, туган телдән дәүләт имтиханы билгеләнмәгән. Моңа карата фикерегез ничек?

– Бүген вузларга бердәм республика сынавы нәтиҗәсе буенча кабул итәргә рөхсәт ителми. Әлбәттә, моның белән килешеп булмый. Минемчә, бердәм дәүләт сынавы булырга тиеш. Әйткәнемчә, хәзер бары татар теле һәм әдәбияты буенча татар теленнән эчке имтихан белән генә чикләнәбез. Федераль таләпләр буенча өч фәннән сынау куярга хокукыбыз бар. Татар телен үзебез билгелибез. БРИ гына түгел, туган телләрдән БДИ да булырга тиеш. Бу очракта абитуриент имтихан форматын үзе сайлый ала. БДИмы, әллә традицион сынаумы? Киләчәктә милли юнәлешләргә кабул итүдәге каршылыклар юкка чыгар дип өметләнәбез. Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы, республика парламенты федераль министрлыклар белән бу проблеманы хәл итү буенча эш алып бара.

:: Вузларда абитуриентларны кабул итү дәвам итә. Милли кадрлар әзерли торган сезнең институтта вазгыять нинди?

«Татар-информ»

Белешмә

Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында хәзерге көндә барлыгы 5 мең тирәсе студент укый.

– 20 июньдә кабул итү кампаниясенә старт бирелде. Кабатлап әйтәм: татар теле һәм әдәбияты буенча укырга керүчеләрдән документлар 15 июльгә кадәр генә кабул ителә. Башкаларның исә 25 июльгә кадәр вакыты бар әле.

Татар телен сайлаган балалар уку йортына ике төрле программаны күздә тотып киләләр. Аның берсе – педагогик белем бирү юнәлеше. Без быел «татар теле һәм әдәбияты, рус теле» дигән программага кабул итәбез. Бу – яңа юнәлеш. Моңа кадәр «татар теле һәм инглиз теле» дип атала иде. Ихтыяҗны күздә тотып, профильне үзгәртергә туры килде. Безгә рус телендәге белгечлекләр булдыруны сорап еш мөрәҗәгать итәләр. Шуңа күрә үзгәртергә туры килде. Инглиз теле белән кызыксынучыларны күптелле программаларга чакырабыз. Икенче юнәлеш «филология, татар теле һәм әдәбияты, журналистика» дип атала. Бу программага кабул итүне быел өченче ел «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте белән берлектә оештырабыз. Гомумән алганда, милли кадрлар әзерләү юнәлешендә 244 бюджет урыны бар. Шуларның 79ы – федераль, калганнары республика хисабына бүлеп бирелгән. Бу сан былтыргыдан 15кә артык. Яңа «Реклама һәм PR» белгечлегенә быел шуның кадәр заказ алынды. Яшьләрнең бу программа белән кызыксынуы зур. Бүген реклама юнәлешенә 284 гариза кабул иттек.

«Татар әдәбияты һәм рус теле» буенча бер урынга 3 бала дәгъва кыла. Республика заказы буенча чит телләр юнәлешендәге 25 урынга 87 гариза кергән.

Шөкер, татар әдәбияты юнәлешенә керергә теләүчеләр аз түгел. Югары баллар белән килүчеләр дә шактый. Әйтик, Теләче районыннан Динә Тимербаева җәмгыять белеме имтиханыннан 100 балл җыйган. Рус телен дә яхшы тапшырган. Кыскасы, ике фән буенча 204 баллы бар. Без кабул иткәндә шәхси казанышлар өчен дә баллар өстибез. Әйтик, кызыл аттестат өчен – 5, ГТОга 2 балл бирелә. Эчке имтиханын да яхшы итеп тапшырса (шулай буласына минем шигем юк), Динә иң зур балл җыючыларның берсе булачак.

:: Ике телле мәктәпләргә укытучылар әзерләү эше ничек бара? Әйтик, быел математика, физика, информатика, химия, башка фәннәрдән дәресләрне татарча укытырга теләгән ничә егет-кызны кабул итәргә җыенасыз?

– Ике һәм күптелле мәктәпләр өчен 150 урынга заказ алдык. Бу – математика һәм чит тел, музыка һәм чит тел, рәсем һәм чит тел, инглиз, төрек яки гарәп теле, башлангыч сыйныф һәм чит тел профильләренә кабул итү өчен. Көндезге бүлектә укучы әлеге студентларга ай саен 15 мең сум күләмендә стипендия түләнәчәк. Читтән торып укытуга кагылышлы программага педагогик көллиятләрне тәмамлаган яшьләрне кабул итәбез. Дөресрәге, алар эшләп укый. Югары курсларда физика-математика, математика-информатика профилендә укучылар да бар. Республика Хөкүмәте, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы биргән заказ буенча әзерлибез.

:: Күптән түгел узган Бөтенроссия татар теле укытучылары корылтаенда ике телле белгечләр әзерләүдә сүлпәнлек күрсәткән районнарны атаган идегез... Әллә аларга укытучылар кирәкмиме?

– Кызганычка, барлык җирлекләрдә дә бу белгечлекләргә яшьләрне җибәрүне оештыру эше җитеп бетми әле. Бүген әлеге проект буенча 519 бала белем ала. Шулар арасында иң күп балалар Казан шәһәре, Арча, Саба, Кукмара, Балтач, Теләче, Түбән Кама, Балык Бистәсе, Биектау, Чаллы, Тукай районнарыннан килгән. Шул ук вакытта бер генә яки бер бала да укымаганнары да юк түгел. Бу – Менделеевск, Алабуга, Югары Ослан, Ютазы, Зәй, Тәтеш, Лениногорск, Аксубай районнары. Мин аларга укытучылар кирәкми дип уйламыйм. Әлеге районнарда ихтыяҗ бар. Гомумән, күпчелек районнарда математика, чит телләр, башлангыч сыйныф укытучыларына да кытлык сизелә. Яшь белгечләр өч телдә укыта алачак. Бу – заман таләбе. Без математикларны үзебез генә әзерли алмыйбыз. Кайбер очракта аңлап җиткермичә, ничек инде филология һәм мәдәниятара багланышлар институты математиклар әзерли, дип сорау да бирәләр. Без ике һәм күптелле белгечләрне университеттагы башка институт укытучылары белән бергәләп әзерлибез. Киләсе елда ике тел буенча (татар һәм рус телләре) беренче чыгарылышны чыгарабыз. Аз комплектлы мәктәпләрдә гадәттә сәгатьләр белән проблема туа, ике профильле һәм ике телле белгечләргә эшкә урнашу да җайлырак булачак.

:: Татар теле укытучыларына ихтыяҗ бармы?

– Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматлары буенча, яңа уку елында татар теленнән 90 укытучы кирәк. Без быел шушы күләмдә яшь белгечләр чыгарабыз. Бездән тыш, КФУның Алабуга филиалы, Чаллы педагогика вузлары да укытучылар әзерли. Ихтыяҗ каплана, димәк. Киләсе елларда – ким дигәндә 60–70, кайсыдыр елда 50 укытучы кирәк. Бу яшь белгечләргә эш урыны булачак.

:: Татар теле укытучыларын үпкәләтәсе килми. Әмма моңа кадәр, татар теле укытучылары кагыйдә ятлату белән мавыга, дигән сүзләрне ишетергә туры килгәләде. Соңгы елларда укытучыларны дәресләрен кызык итеп оештырырга өйрәтә алдыкмы?

– Татар теле һәм әдәбияты буенча берничә заманча дәреслек язылды. Аны мәктәпләр әти-әниләр белән бергәләп сайлый ала. Дәреслекләрдә теоретик темалар да, аралашуга корылганнары да, уен-җыры да бар. Без үзебез дә «Адымнар» мәктәпләре өчен дәреслек язабыз. 1 нче сыйныфларныкы буенча укыталар инде, хәзер 2, 3, 4кә әзерлибез. «Сәлам» һәм тагын берничә авторлар коллективы әзерләгән дәреслекләр бар. Бары дөрес итеп файдалана белергә генә кирәк. Кызганыч, кайбер мәктәпләрдә укытучылар ул дәреслекләр белән тиешенчә эшләп бетерми.

Яңа буын укытучылары әзерлибез. Студентлар белән дә эшлибез. Дәүләт имтиханнары комиссия составына эш бирүчеләрне, директорларны да кертәбез, алар белән бергә яшь белгечнең белемен тикшерәбез. Аның белеме, осталыгы хәзерге көн таләпләренә туры киләме – бергәләп ачыклыйбыз. Студентларны төрле типтагы мәктәпләргә алып барабыз, хосусый мәктәпләр белән эшлибез. Аларның тәҗрибәсе безгә булыша. Кыскасы, кагыйдә өйрәтеп кенә утырмыйлар. Дәресне дөрес оештырган укытучы барысына да җитешә. Без чыгарган белгечләр заман таләбенә туры килә.

Сәрия МИФТАХОВА

kazansummit.ru

ХӘЛӘЛ КИЛЕШҮ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Яңа закон

Дәүләт Думасының Финанс базары комитеты рәисе Анатолий Аксаков хәбәр итүенчә, Россиядә ислам банкингын җайга салачак закон проектлары атна ахырына кадәр Думада тәкъдим ителергә мөмкин. «Тиешле документлар тикшерелә, ә законнар көзге сессиядә каралачак», – дигән ул «Коммерсантъ»ка.

Ислам банкингы белән партнерлык финанславы оешмалары (ПФО) шөгыльләнәчәк. Әлеге яңа төр оешмалар Үзәк банк карамагында булачак.

Гомумән алганда, ПФОларның эшчәнлеге клиентлар белән партнерлык мөнәсәбәтләре булдыруны күз уңында тота. Ягъни клиент һәм банк бурычка акча алучы һәм бурычка акча бирүче түгел, партнерлар булып санала. «Көнбатыш финанс базарлары белән элемтәләр өзелү нәтиҗәсендә килеп туган вазгыятьтә, Россия халкының, эре компанияләренең, шулай ук финанс институтларының партнерлык (ислам) нигезендә финанслау инструментларына ихтыяҗы көннән-көн арта», – дип аңлата яңа закон проектлары авторлары.

САН

2020 елда дөньяда ислам банкингы базарының гомуми күләме 1,7 трлн долларны тәшкил иткән. Белгечләр 2024 елга бу сан 3,4 трлн долларга кадәр җитәргә мөмкин дип фаразлый. Хәзерге вакытта шәригать кануннары буенча 72 илдә барлыгы 520 банк эшли. Шунысы кызык: бу өлкәдә гарәп илләре түгел, ә Малайзия лидер булып тора. Анда ислам банкларының активлары 520 млрд долларны тәшкил итә.

Хәләл банкинг турында

Ә хәләл банкинг нидән гыйбарәт соң? Аның үзенчәлекләре нидә? Билгеле булганча, ислам процент капиталын, ягъни рибаны катгый тыя, аны һәлакәткә илтә торган зур җиде гөнаһның берсе дип таный.

– Әлеге система табышны да, зыянны да банк һәм клиентның үзара бүлүенә нигезләнә. Гади банк белән чагыштырып карыйк. Әгәр нинди дә булса эшкуар билгеле бер проекты өчен гади банктан кредит ала икән, табыш алдыма ул, юкмы, кредитын ай саен түләп барырга тиеш. Ә хәләл банкинг башкачарак эшли. Билгеле бер проектны финанслаганчы, банк аны яхшылап өйрәнә. Табыш китерә алачакмы ул, эшләп китә алу ихтималы зурмы? Ләкин банк моны үзе дә табыш алу өчен түгел, ә проект чыннан да уңышлы булсын өчен эшли, – дип аңлатты ана капиталы һәм инвестицияләрне шәригать кануннарына туры китереп гамәлгә ашыру буенча белгеч, «Баракат-сити» җәмгыяте җитәкчесе Ринат Ямалиев.

Аерым алганда, ислам банкингы ссудалы процентлар, спекуляция, азартлы уеннарны тыюны күздә тота. Моннан тыш, ул икътисадның кайбер өлкәләренә (тәмәке, алкоголь, кайбер төр итләр сату, фахишәлек һ.б.) инвестицияләүне тыя.

Хәләл ипотека турында

Шәригать кануннарына нигезләнгән финанс инструментларының иң билгелесе – мурабаха, ягъни ислам ипотекасы. Тәртибе болайрак: күчемсез милек сатып алганда ссудага процент түгел, ә товарның үзкыйммәте һәм аның гамәлгә ашыру бәясе арасында билгеләнә торган өстәмә хак салына.

– Башкача әйткәндә, ислам ипотекасы күчемсез милекне өстәмә түләү белән кичектереп сатудан гыйбарәт. Әйтик, берәү машина сатып алырга җыена. Автосалонда аның хакы – 1 млн. Бу хакны түли алмагач, ул ислам банкына мөрәҗәгать итә. Банк машинаны үз бәясенә сатып ала да, клиентына, әйтик, 300 меңгә арттырып сата. Клиент, үз чиратында, бу хакны бүлеп түли, – дип аңлатты «Амаль» финанс йорты генераль директоры Рөстәм Сәгъдиев.

ИСЛАМ ИПОТЕКАСЫ АЛУЧЫГА ТАЛӘПЛӘР:

✓Россия гражданины булу;
✓18 яшьтән өлкән булу;
✓документлар тапшырган вакытта Россия территориясендә даими яки вакытлыча теркәлгән булу;
✓эш белән даими тәэмин ителеш, соңгы тапкыр эшкә урнашканнан соң 3 ай вакыт узу.

Рөстәм Сәгъдиев хәләл ипотека белән гади ипотека арасындагы төп аермаларны да атады:

– хәләл ипотека буенча килешү төзегәндә, бәя алдан билгеләнә һәм үзгәрми. Үзгәргән очракта да, ул артмаячак, киресенчә, кимергә мөмкин. Ә гади ипотека моны гарантияләми, ягъни икътисади вазгыятькә бәйле рәвештә, бәядә дә үзгәрешләр булырга мөмкин;

– гади банкта вакытында түләмәгән очракта штраф – пеня каралган. Хәләл ипотекада мондый катгыйлык юк. Штраф кайбер очракта гына каралган, һәм ул акчаны банк үзләштерми, тулысынча хәйриячелеккә тота;

– хәләл ипотека әле төзелә генә торган йорт алыр өчен бирелми.

Ислам ипотекасы дип аталса да, аны мөселманнар гына түгел, башка дин вәкилләре дә файдалана ала. «Безнең клиентларның якынча 70 проценты мөселманнар булса, калган өлешкә башка дин вәкилләре туры килә. Гомумән, ислам финансларында дини чикләр юк», – диде Рөстәм Сәгъдиев.

Казаннан Айгөл ханым ипотеканың дин буенча рөхсәт ителгәнен алырга тели.

– Ничек, күпмегә, файдасы һәм зыяны турында белешә башлаганда, чәчләр үрә торырлык иде. Бу теманы яхшылап өйрәнә башлагач кына нәрсәнең ни икәнен төшендем. Билгеле, хәләл ипотека буенча фатирның хакы шактый арттырылган була. Ләкин ипотека бирә торган банк нәрсә хисабына булса да яшәргә тиеш бит инде. Ул фатирны 1 миллион сумга сатып алып, шул ук бәягә сата алмый. Хәләл банкларның төп аермасы – аларда «пычрак» акча юк. Ягъни ул синнән алган акчаны исламда тыелган гамәлләр өчен тотмый, банкның системасы чиста. Һәм, гомумән, ислам диненә кагылышлы һәр нәрсә нияткә барып тоташа, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен эшләнә, – дип сөйләде ул.

Казанда эшләүче риэлтор Илүсә Гыйльманова сүзләренә караганда, ислам ипотекасы буенча фатир алырга теләп мөрәҗәгать итүчеләр алай ук күп түгел.

– Шәхсән миңа бик сирәк мөрәҗәгать итәләр. Гомумән, ипотеканың мондый төре буенча килешү төзегәнем юк. Мөрәҗәгать итүчеләрнең күпчелеге гади ипотеканы кулай күрә, – диде ул.

Ә Чаллыда эшләүче риэлтор Юлия Рыжикова «хәләл килешү»не берничә кеше белән төзергә өлгергән инде.

– Ярты ел эчендә өч килешү төзедем. Күбесенчә яшьләр мөрәҗәгать итә. Билгеле, мондый төр ипотека һәркемгә дә туры килми. Шартлары белән танышкач, кире уйлаучылар да бар. Хәләл ипотека штрафлар булмавы, «кредит тарихы»на йогынты ясалмавы белән отышлы. Ләкин гади ипотекадан аермалы буларак, монда бурычны вакытыннан алда өлешләп түләп булмый. Тизрәк ябам, дисәң, акчаны тулысынча кайтарырга кирәк. Һәм мондый төр килешүләр озаграк төзелә, – дип сөйләде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Ислам банкына ихтыяҗ бармы?

Ансар хәзрәт МИФТЯХОВ, «Әл-Мәрҗани» мәчете имамы:

– Ислам кануннары буенча гомер итәргә тырышучы, мал-мөлкәтләрен дә шәригать кушканча туплау нияте белән яшәүче гаиләләр елдан-ел арта, һәм мөселман гаиләләренең күп булуы сөендерә. Билгеле булганча, динебез процент капиталын, ягъни өстәмә түләүне тыя. Моны белгән, аңлаган дин кардәшләребез киңәш сорап хәзрәтләргә дә мөрәҗәгать итә. Ягъни бу юнәлештә эзләнәбез, киңәш сораучыларны дин буенча рөхсәт ителгән системага таянып эшли торган белгечләр янына җибәрәбез. Миңа калса, әлеге юнәлеш актуаль һәм актуаль булачак та.

Рөстәм СӘГЪДИЕВ, «Амаль» финанс йорты генераль директоры:

– Ислам финанслары мәсьәләсенә дәүләт органнарының да игътибары сизелә. Әйтик, «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit» Халыкара икътисади саммитында бу сорауларга аерым игътибар бирелде. Монда шулай ук геосәяси вазгыятьне дә исәпкә алырга кирәк. Россия өчен бик күп ишекләр ябылды. Якын Көнчыгыш илләре тәҗрибәсенә йөз тоту актуаль дип уйлыйм. Гомумән алганда, хәләл индустрия базары елдан-ел киңәя, мин моны үзебезнең тәҗрибәгә таянып әйтәм. Ислам финанслары гаделлек принципларына нигезләнгән. Ә ул принциплар актуальлеген беркайчан да югалтмаячак.

КОТКАРУЧЫ ЕГЕТ

Шушы көннәрдә Кукмара районының Кенәбаш авылында янгын чыга. 12 яшьлек Ринат Хәлимов сеңелләрен шул янгыннан коткарып кала.

– Бакчада чүп утый идем. Улым, янабыз, дигәч тә, аңламыйча торам. Кемнәр яна икән дип уйладым. Баксаң, ут бездә икән. Ринат улым кечкенә сеңлесен дә күтәреп чыккан иде. Мин йөгереп керсәм, йортыбызны ут камап алган, – ди Әлфия Хәлимова. – Безнең өйдә янгын хакында хәбәр бирүче җайланма тора. Шул тавыш биреп кечкенә балаларым исән калды.

Әлфия сабыйларын үзе генә үстерә. 2019 елда ире кинәт үлеп киткән. Ул чакта Әлфия дүртенче сабыена йөкле була.

– Фаил белән әйбәт яшәдек. Күп итеп мал тота идек, ул үлгәч, терлекләрне бетердем. Әле бит кечкенә балама 3 яшь тә юк. Без туендыручысын югалтканнарга тиешле пенсия акчасына яшибез, – ди Әлфия. – Мин Кенәбашка Лубян авылыннан кияүгә килгән идем. Матур итеп тормыш итәргә хыялландым. Башта ирем китеп барды, инде хәзер йортсыз калдык. Дөрес, авылда буш торучы йортны бирделәр бирүен. Әмма киләчәктә нишләрбез – анысы билгесез әле. Беркайда да эшләмәгәч, мин ниндидер программалар белән фатир да, йорт та төзи алмыйм. Әлегә гаиләбез белән хастаханәдә дәваланабыз. Бар документларыбыз, кирәк-яраклар янып бетсә дә, күңелемне төшермим. Улыма рәхмәт. Ул уяу булмаса, нишләр идек?

Ринат Пучинкә-Кучук урта мәктәбендә укый икән. Янгын чыккан көнне телефонда уйнап утырса да, махсус җиһаз тавышын ишеткән.

– Шуннан, улым йортның янган өлешенә йөгереп бара. Аннары тизрәк ике сеңлесен урамга чыгарып җибәрә. Кечкенәсен йокыдан уятып алып чыга. Балаларым яныма җыелгач кына янгын сүндерүчеләрне чакырдым. Мин бөтенләй каушап калган идем. Ярый Ринат булды, – ди әнисе.

Игълан тактасы

КЕМГӘ КИРӘК?

▸12–14 яшьлек кыз бала өчен җәйге киемнәр бар. Кирәк кешеләр редакциягә мөрәҗәгать итсен иде.

Ләйсән Ш.

***

▸Яхшы хәлдәге, берничә тапкыр гына киелгән 44–46 үлчәмдәге кышкы тун, 36–37 үлчәмдәге язгы-көзге аяк киеме бирәм.

Гөлфирә. Казан

КЕМДӘ БАР?

▸5–6 яшьлек кыз балага яраклы киемнәр кирәк иде.

Рәшидә

***

▸12–14 яшьлек малай өчен киемнәр кирәк иде.

Елена Комарова

Ярдәм итәргә теләүчеләр булса, 222-09-67 телефон номерына шалтыратсыннар иде.

АВЫРУ КЫЗЫН ТЕРЕЛТЕРГӘ ТЕЛӘҮЧЕ АНА:

«ЙӨРӘГЕМНЕ АҢА БИРЕР ИДЕМ»

Роза Дәүләтшина редакциягә үзе килде. «Балама ярдәм кирәк чакта ничек түзеп торыйм...» – ди ул. 38 яшьлек кызы Энҗе Галиуллина турында язып чыгуыбызны, газета укучылар белән бергә ярдәм итүебезне сорап килгән ул. Йөрәгендәге хәсрәт йөзенә дә бәреп чыккан. Күз яшьләрен тыя алмый, алар мөлдерәп ага. Елаган кешене күп күргәнем булса да, җаны-тәне белән үксегән, һәр күзәнәге сулкылдаган кешене беренче очраттым.

– Ничек тә баламны яшәтәсе иде, – ди Роза Дәүләтшина. – Кайчакта аның тилмерүен күреп, Аллаһы Тәгаләдән, хәерлесен бир, дип сорыйм. Бик авырганда инде безне ташлап китәр дә кебек була. Тырыша, тырмаша ул. Тормышның якасына ябышкан. Бетте дигәндә, күзләрен ача, аякка баса. Яшәүне бик ярата шул. Бер генә теләге бар – яшәү!

Энҗе бик тырыш бала була. Мәктәпне бетергәч, укый да укый. Шуңа кияүгә дә соң чыга. Ире Альберт белән матур яшиләр. Бер-бер артлы ике балалары дөньяга килә. Бар да яхшы була. Тик 2020 ел алар гаиләсенә авыр хәбәр алып килә. Аш бүлмәсендә савыт-саба юганда аңын югалтып егылган Энҗенең гемоглобины түбән икәнлеге ачыклана. Аннары ул биле һәм аяклары авыртуга зарлана башлый. Табиблар төрлечә дәвалап карый. Чираттагы кан анализлары Энҗедә яман чир икәнне күрсәтә.

– Кызым химия терапияләре алды. Хәле дә рәтләнеп киткән кебек иде. Тик аннары пандемия башланды. Безне ковид госпиталенә күчерделәр. Анда күчкәч, химия терапиясе туктап торды. Энҗе бик нык авырый башлады. Ковид диагнозы куелган иде. Ул чакта мин дә авырдым. Кызымны коткара алмабыз дисәләр дә, ул терелде. Өч тапкыр кан плазмасы салганнан соң, күзләрен ачты. Аннары аны Казанның 16 нчы хастаханәсенә салдылар, – дип сөйли Роза апа. – Ул аннан терелеп чыкты. Анализлары яхшы иде. Дәвалаган табибы да, лейкоз күзәнәкләре беткән, дип сөендергән иде. Чынлап та, ул чакта кызым матуреп китте, чирне онытып яши башлады.

Тик яман чир быел май аенда тагын үзен сиздерә. Энҗе, түләүле клиникага барып, кан тапшырып карый. Нәтиҗәләре бер дә сөендерми. Кандагы лейкоз күзәнәкләре 88гә җиткән була. Шуннан соң табиблар

Энҗе Галиуллинага ярдәм итәргә теләүчеләр өчен исәп-хисап реквизитлары:

Ире Альберт Ринат улы Галиуллин исемендәге 4276 6200 4435 9309 номерлы Саклык банкы һәм 5536 9139 9710 8119 номерлы Тинкофф банкы карталары 89274141589 телефон номерына беркетелгән.

Энҗегә химия терапиясе бирәләр. Яман чир күзәнәкләрен үтерү өчен күләмен 3 мең тапкыр арттырып, 3300 мл итәләр. Табиблар Энҗене озак яшәмәс диләр. Мондый зур күләмдә химия терапиясе алган кешеләрнең әчке органнарына зыян килә икән. Тик Энҗенең яшәү теләге көчле була, ул бу химияне күтәрә. Әмма ул да булышмый, лейкоз күзәнәкләре кимеми.

– Бер улыма инфаркт булды. Ул кызыма донор була алмый. Мин яшем буенча туры килмим. Кече улымнан җелек алып күчереп куймакчылар иде. Тик дәвалау булышмагач, операция ясамадылар, – ди әнисе. – Бер хастаханәдә дә яшәренә өметләндермәделәр. Әмма мәрхәмәтле кешеләр бар бит ул. Шушындый ук диагноз куелган, әмма чирне җиңгән кеше безгә үзе килеп керде. Кызыма ярдәм итә алырлык хастаханә турында сөйләде. Аннары без чит илдәге шул клиникага чыктык. Андагы табиблар Энҗене коткарып калып була дип ышандырдылар.

Роза апа кызының тереләсенә бик ышана, аның көчле рухлы булуына шакката. Чит ил клиникасына барыр алдыннан ул бернинди дарусыз 6 тешен дәвалата, икесен алдыра. Өенә кайткач, уч төбен күрсәтсә, теш табибы кабинетындагы кәнәфи тотынгычының эзе уелып калган була. Әнисе кызының сабырлыгына әнә шунда тагын бер кат инана.

– Бер тапкыр Энҗенең хәле бик авырайды. Мин аның кулларын тоттым да, кызым, үлмә инде, зинһар, дип ялварып еладым. Шунда ул күзен ачты да, әни, мин үләргә теләмим, яшисем килә бит, диде. Чит ил клиникасыннан терелеп кайтасына ышана ул. Лейкоз күзәнәкләре баш миенә дә китәргә мөмкин, диделәр. Шуңа да без аны тизрәк салдык. Ул анда химия терапиясе ала башлады инде. Хәле яхшырып киткән. Организмы даруларны җиңел кабул итә башлаган, – ди Роза апа.

Энҗе ире Альберт белән ике бала үстерә. Кызы Зәринәгә – 10, улы Маратка 6 гына яшь әле. Алар хәзерге вакытта әниләре янәшәсендә. Балаларны үзе белән алып китәргә уйлый Энҗе. «Күпме яшисемне белгән юк, янымда булсыннар», – ди икән. Әле ярый, хәлләренә кереп, аларга яшәү өчен 1 айга бушлай урын биргәннәр. Ирен клиникага керттәләр, сабыйлар исә әниләрен тәрәзә аша гына күреп тора.

Роза апа гомере буе мәктәптә укытучы булып эшләгән. Ире белән икесенә 80 еллык хезмәт стажлары бар икән.

– Гомеремдә дә кешедән акча сорап йөрермен, дип уйламадым. Бала хакына барысын да эшлисең икән ул. Ана бит мин. Балам ярдәм сорап ятканда, ничекләр түзеп торыйм? Миннән генә торса, йөрәгемне бирер идем үзенә, – ди ул.

Энҗегә бөтен авыллары белән ярдәм итәләр икән. Иске Ибрай халкы, кулдан килгәнчә, ярдәм итәргә тырыша. Роза апа авырлык килгәндә, гап-гади кешеләрнең ярдәм кулы сузуына шаккаткан. Пенсияләреннән бишәр мең сум китерүчеләр, 500 сум бирүчеләр дә бар икән. Роза апа бөтен кешегә чиксез рәхмәтле. Әмма чит ил клиникасы сораган сумманы авыллары гына күтәрә алмаслык шул. Анда дәвалану 8 миллион 300 мең сум тора. Һәм ул сумманы 20 июльгә кадәр җыярга кирәк. Бар да яхшы булса, энесе Илфат донор булырга да риза. Тик апасы гына яшәсен!

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

СӘНИФӘ РАНГУЛОВА:
«ХОЛКЫМА КАЙГЫЛЫ ҖЫР ТУРЫ КИЛМИ»

Көнне елмаеп башларга өйрәткән, егетләрне, кызлар пирчәткә түгел, дип кисәткән үзенчәлекле җырчы – Сәнифә РАНГУЛОВА бүген кайда, нинди эшләр белән шөгыльләнә? Хәзерге эстрадага, җырчыларга нинди бәя бирә? Замананында эстрада юлын сайлавына үкенмиме? Безнең әңгәмә әнә шул хакта.

:: Җыр ул – ...

– яшәргә көч бирүче, яратырга, тормыш авырлыкларын кичерергә, кирәк булганда еларга, кирәк чакта елмаерга ярдәм итүче. Җыр кешене гомер буе озата бара. Тормыш бишек җыры белән башлана һәм ахыргы көнгәчә моңаһәң озата бара. Җырчы өчен җыр – тормышы, яшәү рәвеше, эше. Профессиональ билгеләмәсе белән җавап биргәндә, җыр ул – көй белән шигырьнең синтезы.

:: Җыр юнәлешен сайламаган булсагыз, нинди һөнәр иясе булыр идегез?

– Әтинең мине хисапчылыкка укытасы килде. Ә минем беренче сыйныфтан башлап актриса буласым килде. Хәтерлим: безгә 1 сентябрь көнне укытучы апа, үскәч кем булырга телисез, дигән сорау бирде. Бу хакта уйлап килергә кушты. Иртәгәсен мин, артистка буласым килә, дип әйттем. Ул сүзне каян ишеткәнмендер, үземә дә кызык. Һәрхәлдә, ул сүз минем авызымнан чыкты. Ә 4–5 сыйныфларда «Яшь ленинчы» газетасына, Казанда артистлыкка кайда укыталар, дип хат язып җибәргән идем. Дөрес, җавап килмәде. Әмма бу Казанга бару теләген сүрелдермәде, киресенчә арттырды гына бугай әле. Уйлап карасаң, Пермьдә дә музыка училищесы бар, ә минем Казанга киләсем килде. Әле ул вакытта артистка буласым килә дип әйтсәң, кеше көлкесенә калуың да ихтимал иде. Казан бит Барда районыннан ерак, татар телевидениесе дә күрсәтми, радиодан да татар концертларын бик сирәк тыңлый идек. Ничек булса да, мин җырларга, биергә яраттым һәм төрле смотр-бәйгеләрдә катнаша идем. Шулай итеп, артист булу хыялы мине Казанга алып килде.

Казанга килгәч тә кызык булды, мин беренче имтиханга соңга калдым. Миңа ярдәм иттеләр, музыка кафедрасы җитәкчесенең өй адресын бирделәр. Шул йортны эзләп киттем. Ул мине өендә тыңлап карады да, билге куеп, алга таба имтиханнарны бир дип, кайтарып җибәрде. Шулай итеп училищеның җыр бүлегенә укырга кердем. Ул вакытта татар факультеты да юк иде әле, рус бүлегендә күбрәк русча җырлап укыдык.

:: Сезнең исемегез дә, фамилиягез дә үзенчәлекле. Нәселегез гади түгел бугай, тарихын өйрәнмәдегезме?

– Чынлап та, Сәнифә – сирәк исемнәрнең берсе. Ул Барда якларында да сирәк очрый. Иң кызыгы: әти-әнием миңа Санифә исемен биргән һәм өйдә шулай дип эндәшәләр иде. Мәктәптә математика укытучысы Фоат абый гына Сәнифә дип әйтә иде. Казанга килгәч Сәнифәгә әйләндем. Авылда исә миңа хәзер дә Санифә диләр. Рангулов фамилиясе исә безнең якларда бик күп очрый, безнең авылда бигрәк тә. Татарстанда гына андый фамилияне очратканым булмады. Нәселгә килгәндә, карт бабабыз Вәлиәхмәт Латыйпов кырыктартмачы булып, Казан ягыннан килеп, Күчтәнти авылы тирәсендә урнаша. Аның балалары күп була. Латыйпов фамилиясе безнең якларга Казан ягыннан килгәндер дип уйлыйм. Чөнки Латыйповлар безнең авылда бик күп.

:: Сез – бик үзенчәлекле чорда үзенчәлекле җырчы булып танылган кеше. Образыгыз да, җырларыгыз да аерылып тора. Сәхнә киеме, репертуар туплауда ярдәмчеләр булдымы, әллә барысын да үзегез уйлап таптыгызмы?

– Ул – үзем уйлап тапкан образ. Нәтиҗәдә килеш-килбәтем, сәхнә киемнәрем, җырларым үз вакытында татар эстрадасы сәхнәсенә яңалык булып килеп керде. Соңрак модельерлар белән эшләдем, «Лик» мода театры белән дә хезмәттәшлек иттем. Рәссам эскиз ясаганда, барыбер үзеңнең теләкләреңне әйтәсең, бергә иҗат итәсең инде. Ул вакытта бит әле имиджмейкерлар да юк кебек иде, соңга табарак кына чыкты.

:: Бер юлын тапкан кеше югалмый, диләр. Сез дә – сәхнәдә, ләкин тансыкка гына күренәсез. Хәзерге эстрада ул нинди? Яңалыкларга ияләшү авыр булмадымы?

– Татар эстрадасы үсә, җырчылар күп. Матур тавышлы җырчылар да аз түгел. Минем дә яшьләр арасында яраткан җырчыларым бар. Эстрада үзгәрә, яңа алымнар барлыкка килә. Аннан курыкмаска кирәк, чөнки яңалык булу – алга бару дигән сүз. Шәхсән үзем яңалыкларны рәхәтләнеп кабул итәм. Төрле стильләрдә эшләп карауларын да кызыксынып күзәтәм. Әмма җыр, халыкка ошаса, ул кабул итсә генә, озын гомерле булачак. Монда стиль беренче урында түгел.

:: «Кызлар пирчәткә түгел», «Елмай» – хатын-кызны яклый һәм позитив бирә торган җырлар. Хәер, сезнең бөтен җырлар да позитив бугай. Махсус шулай сайлыйсызмы?

– Шулай шул. «Татарстан» радиосына яздырган беренче җырым да «Акбүз атлы егеткә» (Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Илгиз Мәҗитов көе) дип атала иде. «Елмай» (Ренат Харис сүзләре, Резедә Әхиярова көе), «Әй егетләр, егетләр» (Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Рәшит Кәлимуллин көе) – алар барысы да образыма да, яшемә дә туры килде. Уйланып эшләнгән эш тә түгел инде ул, ләкин репертуарымда кайгылы, елата торган җырларым чыннан да юк. Җиңел лирика миндә. Композитор Мәсгудә Шәмсетдинова: «Елмай, елмай дип җырлыйсың, бу сиңа әйбәт кенә. Ләкин кайгылы, кешене елата торган җыр да кирәк. Шундыйны җырласаң, халык яратыр», – дип әйткән иде. Миңа андый җырлар насыйп булмады. Җырга заказ биргәндә, шагыйрь белән эшләгәндә дә, андый теләкне җиткергән булды, әмма җыр барыбер минем стильдә килеп чыга иде. Бәлки ул холыкка бәйледер. Мин – тормышка позитив карашлы, оптимист кеше.

:: «Нишләп сәхнә юлын сайладым икән?» – дип үкенгән чаклар буламы?

– Үкенгән чаклар да булгандыр инде. Нишләп авылда калып, рәхәтләнеп яшәмәдем икән, дигән уйлар да булгалады. Барыбер сөенгән чаклар күбрәк иде. Ярый әле Казанга килгәнмен, зур шәхесләр белән очрашканмын, дип шөкер итәм. Мәктәптә әдәбият дәресләрендә әсәрләрен укыган шагыйрьләр белән күрешү, алар белән эшләү насыйп булды. Мин үземне бик бәхетле кеше дип саныйм.

:: Сәхнәнең тышкы ягы гына матур, эчке ягында исә төрле хәлләр була. Сездән көнләшәләр идеме? Сәхнәдәш дусларыгыз бармы?

– Миннән көнләшкән кеше юктыр дип уйлыйм. Үземнең холыкта кешедән көнләшү сыйфаты юк, башкалар да шундый дип кабул итәсе килә. Үзем белән эшләгән, аралашкан кешеләрнең барысына да хөрмәт белән карыйм. Артистлар арасында дусларым да бар дип әйтә алам.

:: Хәзер җырчылар интернетта бик актив. Анда җырларын да куялар, челтәрле бизнес белән дә шөгыльләнәләр. Моңа ничек карыйсыз?

– Соңгы елларда үзем дә интернетта актив. Ул инде – замана таләбе. Интернет аралашу даирәсен киңәйтә, яңалыклар белән җәһәт танышу мөмкинлеген бирә. Әгәр инде кеше аралашудан кала, финанс хәлен яхшырту җаен да таба икән, рәхәтләнеп эшләсен. Шуңа челтәрле бизнеска да уңай фикердәмен.

:: Ялгызлык яратасызмы, әллә сез компания кешесеме?

– Бу сорауга бертөрле генә җавап биреп булмый. Компанияләрдә булганда, үземне күңелле кеше дип әйтә алам. Читтә генә утырып торырга яратмыйм. Шул ук вакытта ялгызлыкны да яратам.

:: Әнине, әтине иртә югалту киләчәк тормышыгызга тәэсир итми калмагандыр...

– Әти-әни булмаса, бала нинди яшьтә булуына карамастан, ятим кала. Аларны югалту бик авыр. Син вакытыннан алда олыгаясың, тормышта ышыкланыр урының калмавына төшенәсең. Минем әни, мәсәлән, Казанга килүемне, тормышта кем булуымны да белми калды. Бу бик авыр...

:: Җәй чорын туган ягыгызда үткәрергә яратасыз бугай.

– Минем туган ягым – Барда районы Күчтәнти авылы табигатьнең бик матур урынына, Тол елгасы буенда урнашкан. Кешеләре дә бик ачык, кунакчыл безнең якта. Казаннан кунакка килгән артистлар, язучылар да бу якларны бик ошатып китәләр. Үзем Пермь шәһәрендә еш булам. Җәй көне генә түгел, монда эшлим, яшим дигәндәй.

:: Күңел төшенкелегеннән, стресстан ничек котыласыз?

– Тормыш булгач, төрле хәлләр була. Ләкин мин күңел төшенкелегенә әллә ни бирелә торган кеше түгел. Стрессны исә начар яктан гына кабул итмәскә кирәк, аның да организмга файдасы бар. Мин күп еллардан бирле йога белән шөгыльләнәм, җәяү йөрергә яратам. Кәеф төшеп китсә, классик музыка тыңлыйм.

:: Тормышыгыздагы һәм иҗатыгыздагы матур яңалыклар белән дә бүлешсәгез иде.

– Шәхси тормышта зур яңалыкларым юк. Профессиягә килгәндә, мин һаман да күңелгә ошаган җыр көтәм. Җырлар күп килә, күңелгә ятышлысы сирәк була. Халык талантларга бай, булыр, Алла боерса.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Блиц-сораштыру

– Тормышта нәрсәнедер үзгәртергә мөмкинлек бирелсә, үзгәртер идегезме?

– Андый мөмкинлек бирелсә, музыка училищесын тәмамлаганнан соңгы тормышымда кайбер нәрсәләрне үзгәртер идем. Шәхси тормышта да, профессиягә бәйле өлештә дә. Ләкин андый мөмкинлек юк, тормыш берәү генә.

– Иң зур үкенеч.

– Әти, әни вафатыннан соң, шактый еллар ялгыз яшәде. Әти исән чакта авылга ешрак кайтылмады дип үкенәм.

– Иң зур сөенеч кичергән көнне дә искә төшерик әле.

– Һәр көн ул – кечкенә тормыш. Иртән исән-сау уяну да – зур сөенеч. Шуңа гомернең бер генә көнен дә аерып әйтәсем килми.

НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВА

ҖИР ЙОТМАГАН

(ХИКӘЯ)

-1-

Казан тирәсендәге әллә ничә бистәне урадылар. Ташпулат сатучылар күп, әмма аларның берсе дә күңелгә ятмый иде. «Әни, киләсе елга үзем төзеттерәм», – диде Илдар. Киләсе ел бик ерак шул, ерак... Аңа бүген кирәк, бүген! Ул шулай карар кылды, һәм бу чигенмәслек карар иде. Тугыз катлы йортның подъезды, алар яшәгән өч бүлмәле фатир, ишегалды теге шомлы иртә белән бәйләп йөрәгенә кан саудырды. Аның бит кеше кебек таралып-җәелеп көлгәне дә юк! Көлү генә түгел, иркенләп сулаганы да юк! Нәрсәдер тынын кыса. «Нәрсәдер» түгел лә. Газиз иренең җанын кыйган бәндә җәзасын алмады. Шуны уйласа, тамагына таш бөялгәндәй авырайта иде. Бәлки яңа җиргә күченгәч, зәхмәтле ташлар эрер дә хатын рәхәтләнеп сулый башлар! Мондый киеренке халәттә күпме яшәргә була!

Ниһаять, морадына иреште. Сыерчык оясы кебек җыйнак кына ике катлы йорт иде ул. Элеккеге хуҗасы аны салган да кесәсе такырайгач котылырга уйлаган. Өр-яңа куыш! Диварга ябыштырган обойлары кибеп тә өлгермәгән.

Улы документлар рәсмиләштергән арада хатын тартмаларга әйберләрен тутырды. Вак-төяк кенә дисәң дә, җыела икән. Бу фатирга танышлары кызыга. Ишле гаилә, шуңа күрә Гөлсем комсызланып, зур бәя куймады. Өй җиһазларыгызны безгә калдырыгыз, зинһар, диләр. Калдыра! Беренчедән, алар инде таушалган, икенчедән... Кайсына гына кагылма, бәгырь җепселләре шартлап өзелә. Әнә яшел тукыма белән тышланган диван... Мөдәррис: «Күзләрең төсендәгесен сайладым», – дигән иде. Әнә йокы бүлмәсендә имән карават. Мәрхүм ире монысын Мәскәүдән үк кайтартты. «Минем Гөлсем-ханбикәм затлы ятакларда йокласын», янәсе. Әнә Илдарның бүлмәсендәге шкаф... «Абау, бигрәк зур», – дигәч, иренең җавабы кыска иде: «Улыбызның киемнәре сыйсын!»

Бәлки ул Мөдәрриснең кул җылысы тигән әйберләрен таратып дөрес тә эшләмидер. Ә нишләргә соң? Гомер буе шулай хатирәләр богавына чолганып яшәргәме? Шушы каргыштан һич кенә дә араланмасмы икәнни? «Йә Галәмнәр хуҗасы, Дамин дигән бәндәне гөнаһ тузаны кунган аягы белән җирдән атлатма! Ризыкландырыр өчен канга буялган кулына кашык тоттырма! Бастыр минем әрнүләремне!»

Болай каргау, билгеле, үзе үк гөнаһ иде. Югыйсә Аллаһка гына тапшыр, Аллаһ – хөкемдар. Тапшыра Гөлсем, тапшыра. Яңа нигездә барысын да оныта, боерса.

Беренче атналарда өенә бикләнгәндәй урамга чыкмады ул. Түтәлләр казып укроп чәчте, яшел кыякка дип, төбен кисеп, суган утыртты. Улы – Кырымда командировкада, үзенең дә чираттагы ялы иде. Бакчада күңеллерәк тә, чүт-чүт яз җырчысы – сыерчык сайрый, куакка сарылган чыпчык малайлары чыркылдаша, йомшак май җиле иркәләп битеннән сыйпый. Әйе, яңа урында барысын да оныта-а!

Әмма урамдагы хәлләрдән дә хәбәрдар булырга кирәк иде. Күпкатлы йортта ул күршеләре белән туганлашып бетте. Егерме сигез елда кемнең кем икәнлеге беленгән: шөкер, ни өске, ни аскы каттагылар белән әчелешле булмады. Олылар үрнәгендә балалар да дус-тату иде, ә монда күрше-күлән ниндирәк икән? Тәрәзәдән генә күзәткәләп нәтиҗә ясавы кыен. Уң канатындагы ызандашлар белән аны челтәрле койма бүлә. Ишегалдына кызыл таш түшәлгән биек йортның ишеге дә аның ягына карый икән. Өй җәмәгате күренми, мөгаен, таң зәрәсеннән эшкә китәләр дә төнлә генә кайталар.

Сул канаттагы күршеләр ике арадагы калай «ныгытма» эчендәге тормышын кеше күзеннән яшергән дисәң, хуҗасы – баш чүлмәгенә сай гына чүпрәк түбәтәй чәпәгән карт, скандинав таякларын алга-артка очыртып, көненә өчәр мәртәбә турдан үтә. Яшәү дәрте көчле бабайда! Ә карчыгы мондый «кросс»ларны өнәми, ахрысы, гадәттә картын капка төбендә көтә! Каршыдагы йортта «эт анасы» яши. Җирән чәчен кабартып, чүмәлә төсле, түбәсенә өйгән ханым прогулкада ике әнчеген сагалый. Әгәр тегеләр ераккарак чапса:

– Улымчик, машина таптатмасын! Кызымчик, аягыңа ылыс инәсе кадалмасын. Мамочкагызны тыңлагыз, балалар! – дип утка баса.

Кайчандыр бер күршеләр белән танышасы бит дип, Гөлсем иң әүвәл «эт анасы»на сүз катты:

– Саумысыз?!

– Сау гына, кызкай!

– Минем исемем Гөлсем.

– Безнеке Минкия Марсовна! Карале, кызкай, кызыл кием белән урамда йөрмәле, яме? Балаларымның кызыл төстән нервысы кузгала.

«Ана»ларының сүзен раслагандай, көчекләр ярсып-ярсып өрергә тотынды. Бәласеннән башаяк, хатын тизрәк капкасын япты. Кызыл кимә, имеш. Анысы күрәләтә этләр котыртмас, шкаф тулы төрледән-төрле күлмәк. Мондый сәер кешеләр белән аралашмас идең, күршеләрне сайламыйлар шул, яхшымы, яманмы, алар – өстән юлланган «бүләк».

Беркөнне Минкия Марсовна үзе капка шакыды:

– Әй син! Әйдә, аякларны язабыз!

Ханым эредән алдыртып сөйләшә, йөзендә дә, тавышында да тиңсенмәү сизелә иде. Тиңсенмәс тә шул! Аның хан сарайлары белән ярышырлык өч катлы йорты болытларга ук тоташкан, ә Гөлсемнеке нибары озын таякка беркетелгән сыерчык оясы гына иде. Һөнәр мәсьәләсендә дә өстенлек Минкиядә икән: ул – Мәскәү заводының Казан филиалында баш хисапчы, кыскасы, «акча капчыгы». Ә Гөлсем – гап-гади хастаханәдә гап-гади шәфкать туташы. Ул төрле холыктагы авыруларның көен көйләргә өйрәнгән, бәлки бу һавалы күршесенә дә хастага караган кебек караргадыр, чөнки Марсовнаның мәгънәсез киңәшләрен акыл кабул итәрлек түгел иде.

– Син, кызкай, эт ал. Ике-өчне. Алар – иптәш тә, юаныч та. Нәселлеләрен ал. Балалар баккан кебек тәрбиялә. Атна саен ваннада коендыр, җылымса суда. Тәннәрен корытканда синтетик тукыма кулланма, табигый сөлге белән сөрт. Көндәлек меню төзе! Фирменный кибетләрдән заказ белән азык китерт! Йомшак җәймәләрдә генә йоклат!

«Эт асраган өйдән фәрештәләр качар», – дияр иде мәрхүмә әбисе. Ишегалдындагы оясында җәйләсә-кышласа, бер хәер. Шулай дип әйтеп кара бу «авыру»га, Аллам сакласын, чире тагын да көчәер. Тик һаман-һаман «дүртаяклы»лар турында гына тыңлавы туйдыра иде, хатын сүз агымын кирегә борды:

– Йортыгыз әкәмәт зур, Минкия апа.

– Минкия Марсовна, кызкай. Без рәхәтләнеп, аяк сузып иркендә яшәргә күнеккән. Кызымчик Кира белән улымчик Арчиның икешәр уен, икешәр йокы бүлмәсе, өчесе – минеке. Берсендә – гардероб, берсендә – бизәнү әйберләре, берсендә – дәү карават. Иң аскы катта сауна, спортзал һәм няня Маша бүлмәсе. Бассейн да шунда. Балалар үлеп йөзәргә ярата. – «Балалар», әлбәттә, әнчекләр иде. – Кечтеки генә йомышымны үтә әле, кызкай. Минем һәр почмакта күзәтү камерасы, кич шуны әйләндереп өйдәге хәлләрне тикшерәм. Урамда да көйләдем, түлке аның радиусы бәләкәйрәк. Маша бәбкәчләремне аулакка апкитеп җәберләмиме, өсләренә матур камзуллар кигезәме? Шыпырт кына караштыр әле син.

Дәвамы бар >

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 14 июль, 2022 ел, № 175/1553 карарына кушымта

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Яңа Савин районы, Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районы территориясендә оештырылган участок сайлау комиссияләре, Татарстан Республикасы Минзәлә районы территориясендә оештырылган № 1977 сайлау участогының участок сайлау комиссиясе, Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре территориясендә оештырылган № 2227 сайлау участогының участок сайлау комиссиясе составлары резервына өстәмә кертү өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр җыю турында хәбәр

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе 2022 елның 15 июленнән 19 июльгә кадәр 09.00–18.00 сәгатькәчә (төшке аш вакыты – 12.00–13.00 сәгатькәчә) Татарстан Республикасы Казан шәһәре Яңа Савин районы, Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районы территориясендә оештырылган участок сайлау комиссияләре, Татарстан Республикасы Минзәлә районы территориясендә оештырылган № 1977 сайлау участогының участок сайлау комиссиясе, Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре территориясендә оештырылган № 2227 сайлау участогының участок сайлау комиссиясе составлары резервына өстәмә кертү өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр җыюны белдерә.

Түбәндәге адрес буенча:

Территориаль сайлау комиссиясе (ТИК) атамасы	Территориаль сайлау комиссиясе адресы
ТР Казан ш. Яңа Савин районы ТИК	420044, Казан ш., Волгоград ур., 32 й., тел.: (843) 223-22-33 (өстәмә 1832)
ТР Казан ш. Совет районы ТИК	420081, Казан ш., Шуртыгин ур., 1 й. тел.: (843) 223-20-00 (өстәмә 4831, 4832)
ТР Түбән Кама ш. ТИК	423570, Түбән Кама ш., Төзүчеләр пр., 12 й., тел.: (8555) 42-14-81
ТР Минзәлә районы ТИК	423700, Минзәлә ш., Ленин ур., 80А й., тел.: (85555) 3-25-50

Участок сайлау комиссияләре составлары резервына «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» Федераль законның 29 статьясындагы 1 пунктындагы таләпләргә туры килмәүче затлар, тәгаенләп әйткәндә:

– Россия Федерациясе гражданлыгына ия булмаган затлар, шулай ук чит ил гражданлыгына ия булучы яки Россия Федерациясе гражданинының чит дәүләт территориясендә даими яшәүгә хокукын раслаган башка документка ия булучы Россия Федерациясе гражданнары;

– законлы көченә кергән суд карары нигезенә эшкә сәләтсез, эшкә сәләте чикләнгән дип танылган Россия Федерациясе гражданнары;

– 18 яшькә җитмәгән Россия Федерациясе гражданнары;

– дәүләт хакимияте законнар чыгару (вәкиллекле) органнары, җирле үзидарә органнары депутатлары;

– сайланылулы вазыйфаи затлар, шулай ук җирле хакимиятләр башлыклары;

– судьялар (отставкадагы судьялардан тыш), прокурорлар;

– суд карары нигезендә комиссияләр составыннан чыгарылган затлар, шулай ук комиссияне таркату нәтиҗәсендә хәлиткеч тавыш хокукы белән комиссияләр әгъзалары вәкаләтләрен җуйган затлар (комиссия тарафыннан закон бозулар өчен суд тарафыннан үзләренә карата гаепләрнең юклыгы билгеләнгән затлардан тыш) – тиешле суд карары законлы көченә кергәннән соң биш ел эчендә;

– үзләреннән хөкем җәзасы алынмаган затлар, шулай ук сайлаулар һәм референдумнар турында законны бозган өчен суд тәртибендә административ җәзага тартылган затлар – административ җәза билгеләү турында суд карары законлы көченә кергәннән соң бер ел эчендә, кандидатуралары кертелми.

Участок сайлау комиссияләре составлары резервына кертү өчен кирәкле документлары булмаган кандидатуралар участок сайлау комиссияләре составлары резервына кертелми.

Участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кертү өчен кирәкле документлар исемлеге

Сәяси партияләр, аларның төбәк бүлекләре, башка структур подразделениеләре өчен:

1. Сәяси партиянең яки төбәк бүлегенең, сәяси партиянең башка структур подразделениесенең участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү хакында сәяси партия уставы таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән карары.

2. Кандидатуралар турында тәкъдим сәяси партиянең төбәк бүлеге, башка структур подразделениесе тарафыннан кертелеп, сәяси партия уставында мондый тәкъдим кертү мөмкинлеге күздә тотылмаганда – сәяси партиянең төбәк бүлегенә, башка структур подразделениесенә участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертүгә вәкаләтләр бирүгә вәкаләтле сәяси партия органының әлеге вәкаләтләрне бирү турында устав таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән карары.

Башка иҗтимагый берләшмәләр өчен:

1. Иҗтимагый берләшмәнең гамәлдәге уставының нотариуста расланган яки иҗтимагый берләшмәнең вәкаләтле органы раслаган күчермәсе.

2. Иҗтимагый берләшмәнең вәкаләтле (җитәкче яки башка) органының участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү хакында устав таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән карары яисә төбәк бүлегенең вәкаләтле (җитәкче яки башка) органының яисә иҗтимагый берләшмә уставы нигезендә иҗтимагый берләшмә исеменнән мондый карар кабул итүгә хокук бирелгән иҗтимагый берләшмәнең башка структур подразделениесе карары.

3. Кандидатуралар турында тәкъдимне иҗтимагый берләшмәнең төбәк бүлеге, башка структур подразделениесе кертеп, иҗтимагый берләшмә уставында 2 пунктта күрсәтелгән мәсьәлә җайга салынмаганда – иҗтимагый берләшмә уставы нигезендә участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү буенча вәкаләтләр бирүгә вәкаләтле иҗтимагый берләшмә органының мондый вәкаләтләрне бирү турында карары һәм әлеге вәкаләтләр бирелгән органның участок сайлау комиссияләре составлары резервына тәкъдимнәр кертү турында карары.

Участок комиссияләре составлары резервына кандидатуралар кертү хокукының башка субъектлары өчен

Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары, яшәү, эшләү, хезмәт итү, уку урыны буенча сайлаучылар җыелышының беркетмәсе. Сайлаучылар җыелышы беркетмәсенең формасы Россия Үзәк сайлау комиссиясенең 5 декабрь, 2012 ел, № 152/1137-6 карары (Россия Үзәк сайлау комиссиясенең 1 ноябрь, 2017 ел, № 108/903-7 карары редакциясендә) белән расланган Участок комиссияләре составлары резервын формалаштыру һәм участок комиссияләре составлары резервыннан участок комиссиясенең яңа әгъзасын билгеләү тәртибенә № 3 кушымтада китерелгән.

Моннан тыш кандидатуралар кертү хокукының барлык субъектлары тарафыннан түбәндәге документлар тапшырылырга тиеш:

1. Россия Федерациясе гражданинының хәлиткеч тавыш хокукы белән участок сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләнүенә, участок комиссияләре составлары резервына кертүгә язмача ризалыгы (Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенең 5 декабрь, 2012 ел, № 152/1137-6 карары (Россия Үзәк сайлау комиссиясенең 1 ноябрь, 2017 ел, № 108/903-7 карары редакциясендә) белән расланган Участок комиссияләре составлары резервын формалаштыру һәм участок комиссияләре составлары резервыннан участок комиссиясенең яңа әгъзасын билгеләү тәртибенә № 1 кушымта).

2. Россия Федерациясе гражданины паспорты яки кандидатурасы участок комиссияләре составлары резервына кертү өчен тәкъдим ителгән затның гражданлыгы һәм яшәү урыны турында мәгълүматлардан торган Россия Федерациясе гражданины паспортын алыштыручы документы күчермәсе.

Искәрмә. Документлар үрнәкләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына «Сайлау комиссияләре» бүлегендәге «Участок комиссияләре составлары резервы» «2022 елда участок сайлау комиссияләре составлары резервына өстәмә кертү» бүлекчәсенә урнаштырылган.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе

ҖИР ҖИЛӘГЕН ТИЗ ҖЫЮНЫҢ 10 СЕРЕ

1 Эре җиләк җыегыз, вагына кызыкмагыз. Савытны күп җиләк түгел, эре җиләк тутыра.

2 Килеп туктаган җирдә үк юк-бар җиләккә алданмагыз. Башта урынын, «утравы»н табыгыз, шунда гына җыегыз.

3 Җиләк көтү йөргән җирдә күп була. Сыер тизәге – җиләккә иң яхшы ашлама һәм үрчер өчен иң яхшы «транспорт».

4 Печән биек җирдә җиләк эрерәк була. Печәнсез җирдә – вак һәм тиз кибүчән. Печәнне кул белән аерып карарга иренмәгез. Башын асылындырган җиләк печән арасына оста кача.

5 Җиләкне тауга каршы җыеп менегез, тауга түбән түгел. Шул очракта җиләге дә яхшырак күренә, савытны тотарга да уңайлырак.

6 Киң савыт кулланыгыз. Мәсәлән, кәстрүл чиләккә караганда яхшырак. Беренчедән, җиләге изелми. Икенчедән, таулы җирдә чиләк гел кулны тота.

7 Җиләкнең берсен дә авызыгызга капмагыз. Кайткач ашарсыз. Җыйганда берсен капсагыз, автоматик рәвештә иң эреләрен авызга салып барачаксыз.

8 Киемегез җиңел булсын, әмма ачык булмасын. Черки-кигәвеннән селтәнү җиләк җыюның тизлеген бермә-бер киметә.

9 Мөмкинлек булса, җиләкне берәмләп түгел, сыдырып җыегыз. Чүпләрен өйдә араларсыз.

10 Кесәгездә телефон, машина ачкычы кебек әйбер булмасын. Болында югалтсагыз, җиләк җыюыгыз би-ик озакка сузылырга мөмкин.

Әз-мәз мәзәк

* * *

Бухгалтер Вәлиева яңа паспортын алганда үзенең имзасы урынына ялгыш генераль директор кулын куйган.

* * *

– Үзеңне бер җөмлә белән макта.
– Миннән дә начаррак кешеләр бар.

* * *

Быел көнбагышлар фонында фотога төшмәгез, симәнке маена бәя артуны сезнең кыр таптап йөрүегезгә сылтап калдырулары бар.

* * *

Әгәр дөмбер-шатыр килгән тавыш ишетсәгез, курыкмагыз. Мин ул. Бәхетемне төзим.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: балыкчы, имән, им, АН, Дәрдмәнд, Риваять, Тәтеш, самавыр, гидрид, ток, пот, Модест, Галиәсгар, Ока, рус, уй, ватанпәрвәр, Рио, Аякс, алабута, ангина, тир, Шукшин, ланч, Ра, ар, Альбина, табагач, зат.

Вертикаль: Ямбулат, Ли, Руанда, шар, Миасс, Апуш, Әбри, тот, Тура, мантый, каракалпак, Әлмәндәр, Гани, та, поши, буаз, яка, крезол, га, иш, Кипр, Ансат, Кыямов, Венера, Афипс, дог, Раил, тартар, Яна, Ручкан, Ода.

Беләсең килсә...

1 Ни сәбәпле фехтованиедә элеккедән ак киемнән ярышалар?
а) элек һәрвакыт караңгыда ярышканнар;
б) тәндә кан яхшы күренсен өчен;
в) элек коралның очына кара тидереп ярышканнар.

2 Әлеге шәхес Хәсән Туфан белән бер үк елны (1966) Тукай премиясенә лаек булган.
а) Бакый Урманче;
б) Җәүдәт Фәйзи;
в) Айрат Арсланов.

3 Кактусның бу төре дөньяда иң кечкенә санала. Аның зурлыгы нибары 1–1,5 см.
а) пейотль;
б) блоссфельдия;
в) нанокактус.

4 Екатеринбургта бик тә тәрбияви һәйкәл бар.
а) урам себерүче;
б) җирдән төпчек күтәрүче янгын сүндерүче;
в) үз кәкәен үзе җыючы эт.

Җаваплар: 1. в); 2. б); 3. б); 4. в);

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 16052 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 300

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+